# ШУРА

№ 40

2023

رمضان مبارك



## Рамазан ае мөбарәк булсын!

2000999960666

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

# ЭЧТӘЛЕК

Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . 4
Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . 13
Рамазан аеның соңгы көннәре . . . . . . . . . . 14
Ураза гаете вәгазе . . . . . . . . . . 18
Ураза гаете хотбәсенең татарча укылышы . . . . . . . . . . 24
Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе . . . . . . . . . . 26
Шәүвәл аеның фазыйләте . . . . . . . . . . 29
Милләттәшләргә бер нәсыйхәт . . . . . . . . . . 33
Кем Ул Раббыбыз? . . . . . . . . . . 38
Йосыф галәйһиссәләм – гадел җитәкче . . . . . . . . . . 44
«Мине Аллаһы кичермәс» дип әйтү – гөнаһмы . . . . . . . . . . 50
Лут галәйһиссәлам кавеменең һәлакәте . . . . . . . . . . 54
Байлык та сынау, фәкыйрьлек тә... . . . . . . . . . . 62
Мөселманнарның олы кимчелекләре . . . . . . . . . . 68
Кеше ни әйтер? . . . . . . . . . . 72
Зөлхиҗҗә ае фазыйләтләре . . . . . . . . . . 76
Корбан гаете вәгазе . . . . . . . . . . 82
Исраф кылмаучы фәкыйрьләнмәс . . . . . . . . . . 99
Милли тәрбиянең мөһимлеге . . . . . . . . . . 103

«НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН?» . . . . . . . . . . 111

**«ШУРА» дини альманах, №40**

*апрель – июнь 2023*
*Рамазан-зөлхиҗҗә 1444*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Ленар Хамматов
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Айсылу Юлдашева

**ДИЗАЙНЕР:**
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Гөлназ Ситдикова

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Илшат Хәйретдинов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*

*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 24.03.2023
Чыгу көне: 10.04.2023

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аятьсүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللَّهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ! ۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللَّهِ:

________________________ ۞

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

________________________ ۞

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِيَن وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِيَن وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللّٰهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللّٰهِ أَكْبَرُ وَاللّٰهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләәән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләәән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләәһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү'миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ______________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ______________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмуллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә кааләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и

минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфирииинә вәл мүкыыймииинә вәл хәәдыйрииинә вәл гаа-ибииинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлииинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәрүун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әәмин» дип әйтә.

[2] 3 тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы – [гөнаһлардан] курыккан һәм [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ____________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: ______________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез [Аллаһы тарафыннан] рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында [хакыйкый һәм кабул ителгән] дин – Ислам [дине генә]».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгеләү.

**Иң соңыннан, «Әгуузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

> **«Һичшиксез, Аллаһы [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] гадел булырга, изгелек кылырга һәм [бигрәк тә] якын туганнарга [мохтаҗ булган нәрсәләрен] бирергә [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] әмер итә. [Зина кебек] Фәхешлектән, [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] тыелганнан һәм [кешеләргә] җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*14 нче апрель вәгазе,*

*Рамазан аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Рамазан аеның соңгы көннәре

Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин, вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Мөхтәрәм җәмәгать, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Аллаһының рәхмәте белән бөтен айларның солтаны булган Рамазан ае килеп җитте. Рамазан ае – изге вә шәриф айдыр һәм ошбу айның һәр көне, һәр кичәсе мөэмин-мөселманнар өчен бик тә кадерле. Рамазан ае якынлашса, «Әл-Бәкара» сүрәсенең 183 нче аятен искә алабыз.

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

> **«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Шушы аятьнең мәгънәсенә төшенергә тырышабызмы? Яисә «ураза тотарга мәҗбүри» дип кенә аңлыйбыз да, кайсыларыбыз шуны үти, кайсыларыбыз колакка да элмиме? Раббыбыз: «Бәлки тәкъва булырсыз», – ди. Безнең тәкъдиребезгә язылган дәвергә кадәр Җир йөзенә миллиардлаган кеше килде. Алар төрле кавем булып яшәде. Һәм аларга да тәкъвалыкларын арттыру, бу фани дөньяга килүләренең мәгънәсен күңелләренә сеңдерү өчен гыйбадәтләр йөкләнелде. Алар тәкъва булдылармы, әллә үзләре өчен җәһәннәмгә юл салдылармы? Һәм безнең өчен иң мөһиме: алдан килгән халыкларның мисалын гыйбрәт итеп алдыкмы, әллә саташу юлына аяк бастыкмы?

Әлхәмдүлилләһ, Рамазан аенда мәчетләрдә җыелу мөмкинлеге бар, тәравихларга йөрибез, ифтарларга киләбез. Башка илләрнең Рамазан аенда болар юк иде. Аллаһы Тәгалә безнең өчен мәчетләрне япты. Шул вакытта күңелләребез сыкрады, күзләребезгә яшь тулды. Шул чакта тәкъва булдыкмы? Мәчетләрне ихластан сагындыкмы? Раббыбызның кунагы булудан мәхрүм калганнан еладыкмы, әллә нәфесебез тәкәбберлеген канәгатьләндерер өчен генәме?

Сораулар бихисап, мөхтәрәм җәмәгать. Шуларны үз-үзебезгә бирик әле. Рамазан аеның бер төнендә уйланып карыйк әле. Хакыйкатьтә, «Ураза тотарга, намаз укырга, гыйлем алырга, садака бирергә вакытым юк, әле лаеклы ялга чыкмаган, әле банктагы акчам миллионга тулмаган» ише меңләгән сәбәп табарга була.

Бик кызганыч, җәмәгать. Мөселман кешесенең ураза тотуына аптырыйлар. «Авыр түгелме, эчәсең, ашыйсың килмиме, хәлең китмиме?» – дип сорыйлар. Ураза тотмаучыдан: «Ахырзаманда авыр булмасмы?» – дип сорамыйлар. «Минем җиде буын бабам мулла булган», – диләр. Һәм: «Мин әле дин тотарга өлгереп бетмәдем», – дип өстиләр. Татар баласының татарча сөйләшүенә аптырыйбыз. Татар бабасының оныгы татарча белмәвенә гаҗәпләнмибез. Раббыбыз халкыбызны динле, әхлаклы, тәрбияле, тәкъва итсен иде.

Җәмәгать, шушы Рамазан аенда нур өстенә нур, Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән иң зур бүләге – Кадер кичәсе бар. «Кадер кичәсе» гыйбарәсен күпчелек «Кодрәт киче» дип тәрҗемә итә яисә «кадер» сүзен «тәкъдир» төшенчәсе белән бәйли. Шушы изге кичтә барлык Адәм балаларының алдагы елда булачак язмышлары каралачак.

Пәйгамбәребез хәзрәтләре үзенең мөбарәк хәдисендә: «Рамазан аеның беренче ункөнлеге – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте көннәре, икенче ункөнлеге – гөнаһлардан пакьләнү көннәре һәм соңгы ункөнлеге – җәһәннәм утыннан котылу көннәре»[1], – дигән.

---

[1] Ибне Хөзәймә хәдисләр җыентыгыннан.

Раббыбыз Коръәни Кәримдә Кадер кичәсе турында аерым бер сүрә иңдергән, аның өченче аятендә болай диелә:

لَيْلَةُ الْقَدْرِ خَيْرٌ مِّنْ أَلْفِ شَهْرٍ ﴿٣﴾

**«Кадер кичәсе [Кадер кичәсе булмаган] мең айдан да хәерлерәк».**

«Әл-Кадр / Кадер киче», 97:3

Ягъни бер кичәдә 83 ел гыйбадәт кылгандай фазыйләтен, дәрәҗәсен, савабын ала алабыз.

Сүрәнең соңгы аятьләрендә фәрештәләр һәм аларның иң бөекләренең берсе Җәбраил галәйһиссәламнең төнлә җиргә төшүе хакында әйтелә. Җир йөзенә килгән фәрештәләр күбрәк гыйбадәт кылучылар белән бергә булыр, аларга бәхет-изгелек теләп, гөнаһлары кичерелүен үтенеп, догалар кылыр, «мөэмин-мөселманга сәлам!» дип дәшәр һәм бу хәл таң атканчыга кадәр дәвам итәр. Хәтта ул кичәдә шайтан да үзенең мәкерлеген кыла алмас.

Бездән бик еш: «Хәзрәт, Кадер кичәсе кайчан?» – дип сорыйсыз. Без аны белмибез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Рамазан аенда гыйбадәт вә догаларын тагын да арттыра торган булган, бигрәк тә Рамазанның соңгы ун көнендә. Бәлки, мөселманнар да бу ун көнне, изгелекләрен вә гыйбадәтләрен мөмкин кадәр арттырсыннар дип, Кадер кичәсенең төгәл вакыты сер булып саклангандыр. Әлбәттә, галимнәребез бер санны әйтсәләр дә, Расүлебез «эзләгез» ди, шуңа күрә безгә шушы ун төнне изгелектә, гыйбадәттә узырырга кирәк. Кадер кичәсенең шундый билгеләре бар: ул кичә аяз була, артык суык та, эссе дә булмый, кар-яңгыр яумый, җил исми. Кадер кичәсе тын һәм нурлы була. Бу кичәдә йолдызлар да атылмый. Кадер кичәсеннән соң килгән көннең кояшы артык якты булмый.

Гайшә анабыз Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Йә, Расүлебез, әгәр мин Кадер кичәсенә ирешсәм, миңа ничек дога кылырга?» – дип сораган. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллааһүммә иннәкә гафуун түхиббүл гафвә фәгъфу ганнии. («Әй, Аллаһы,

Син гафу итүче, Син гафу итәргә яратасың. Мине гафу ит, гөнаһларымны ярлыка»), – дип дога кыл».

Ошбу догалар һәм башка шундый сорау-үтенечләребез белән Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, изге Рамазан аенда, Кадер кичәсендә генә түгел – ел әйләнәсендә, тормышыбыз дәвамында – һәрдаим гыйбадәт әһеле булуыбызны белдереп, Раббыбызны олылап, шөкер итеп һәм мәхәббәтебезне баглап яшәсәк – Яратучы вәгъдә иткән олуг дәрәҗәгә ирешүчеләрдән булырбыз. Ошбу олуг дәрәҗәне Аллаһы Тәгалә һәммәбезгә дә насыйп кылсын.

Җәмәгать, ул төнне бөтен догалар кабул ителә, нинди дога өмет итсәгез, аны Аллаһы Тәгаләдән сорагыз. Раббыбыз Сөбеханәһу вә Тәгалә шушы Рамазанда изгелек кылып, ураза тотып, ифтар ашларын уздырып, зәкятләрен чыгарып, мескен-ятимнәргә булышып, фитра садакаларын биреп яшәүне язсын иде. Аллаһы Тәгаләгә тәкъва булып яшәү насыйп булса иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*«Гаилә» мәчетенең имам хатыйбы*

*21 нче апрель вәгазе,*

*шәүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Ураза гаете вәгазе

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз булсын. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез ирешсен.

Тәннәребезне, киемнәребезне пакьләп, Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхмәтен, бәрәкәтен өмет итеп гает намазына җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Газиз дин кардәшләрем! Бүген ай буе ураза тотканнан, гамәл-гыйбадәтләр кылганнан соң көтеп алган ике олуг бәйрәмебезнең берсе – Ураза гаете. Барчаларыгызны да әлеге мөбарәк бәйрәмебез белән тәбрик итәм. Шушы көннең вәгазе, хотбәсе, үгет-нәсыйхәтләре күңелебезнең сафлануына, ихласлыгыбызның көчәюенә, Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә, динебез Исламга карата ярату хисләребез артуга сәбәпче булса иде.

Хөрмәтле кардәшләрем, без Рамазан ае дәвамында Раббыбызның рәхмәтенә, мәгъфирәтенә, әҗер-савапларына, ризалыгына өмет итеп Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә тыйганнардан тыелып тордык. Әмма бу тырышлыгыбыз, әлбәттә, беренче чиратта, Раббыбызның безгә булган рәхмәте иде, чөнки һәрбер гамәлебез Аның ярдәме белән кылына. Шуңа да бүген, беренче эш итеп, Раббыбызның фарыз гамәлен башкарып чыга алуыбыз өчен, Аңа хәмед-сәналәребезне, мактауларыбызны, шөкерләребезне җиткерик. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә алдагы елларда Үзенең рәхмәте белән Рамазан айларын каршы алу, ураза тоту бәхетен насыйп итсә иде.

Рамазан ае гамәл-гыйбадәтләргә бай булган ай ул. Әгәр мөселман кешесе көндез ураза тотса, төннәрен Коръән укыса, Кыямәт көнендә аның ике яклаучысы булачак. Хәдистә болай дип әйтелгән: «Ураза һәм Коръән Кыямәт

көнендә Аллаһының колын яклаячак. Ураза: «Йә, Раббым, мин көндез аны сусыз вә ризыксыз тилмерттем, шуңа күрә мин аның өчен Синнән ярдәм сорыйм», – дип әйтер. Коръән: «Йә, Раббым, мин аны төнге йокысыннан калдырдым, шуңа күрә аңа Үзеңнең рәхмәтеңне ирештерсәң иде», – дияр. Һәм аларның үтенечләре кабул ителер»[1].

Рамазан аенда ураза тотуның Ислам дине баганасының берсе булуын ассызыклап, Коръәни Кәримдә болай диелгән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә [фарыз булып] язылган кебек, сезгә дә [Рамазан аендагы] ураза [фарыз буларак] язылды. Бәлки, [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:283

Кадерле дин кардәшләрем! Мөбарәк Рамазан ае безгә ризыкның, суның кадерен белергә, начар гадәтләрдән арынып, нәфесләребезне тыеп, изгелекләр кылырга өйрәтте, бездә сабырлык, миһербанлылык, шәфкатьлелек сыйфатларын тәрбияләде. Әгәр үзебезне мөселман дип саныйбыз икән, Рамазан аенда башланган игелекле гамәлләребезне, Аллаһы Раббыбызга шөкер итүләребезне, гамәл-гыйбадәтләребезне изге ай тәмамлангач та дәвам итсәк иде, гөнаһлы гамәлләрдән, яман гадәтләрдән саклансак иде! Рамазан ае бетте дә, инде элеккеге гадәти тормышыбызга кайтырга, гамәл-гыйбадәтләребезне кылуны киметергә дә була дип ялгышмыйк. Аз булса да, даими гамәлдә булыйк. Пәйгамбәребез саллəллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы каршында иң сөекле гамәл – зур булмаса да,

[1] Әхмәд бине Хәнбәлнең «Мөснәд» җыентыгыннан.

даими кылынган гамәл»[1], – дип әйткән.

Бүген Рамазан ае тәмамлануын белдергән изге бәйрәм – Ураза гаете җитте. Бу – Рамазан аеның нәтиҗәләрен чыгару көне. Һәркем үзенә шундый сорау бирсен: «Мин үткән Рамазанга караганда яхшырак, әхлаклырак, камилрәк булдыммы?» Әгәр бу сорауларга, әйе, дип җавап бирә алабыз икән, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәналәр белдерик, чөнки бары Аның рәхмәте белән генә без хәерле гамәлләр кылабыз, Аның рәхмәте белән генә бу көнгә ирештек. Әгәр яхшырак, камилрәк булмасак, яңа баскычка, рухи дәрәҗәгә күтәрелмәсәк – нәтиҗә ясыйк һәм тормышыбызны, динебез таләпләренә һәм кагыйдәләренә туры китереп, үзгәртә башлыйк. Бу фани тормыш һәркем өчен тәгәлләнәчәк һәм без гамәлләребез белән икәүдән-икәү генә калачакбыз.

Ураза тотучылар, ризыктан һәм судан гына түгел, ә гөнаһлы сүзләрдән, бәхәсләрдән һәм талашлардан тыелып торучылар бүген Аллаһыга шөкер сүзләре әйтсен һәм шатлансын. Бары Аллаһы гына ураза тотуның әҗер-савапларын белә. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Берәү Рамазан аенда Аллаһының әҗер-саваплар бирүенә ышанып һәм Аның ризалыгын өмет итеп ураза тотса, аның элеккеге гөнаһлары гафу ителер»[2], – дигән.

Бүген Рамазан аенда Коръәни Кәримне укучылар, шулай ук аны мәчетләрдә тыңлаучылар шатлансын! Рамазан – Коръән ае ул. Раббыбыз:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۚ

**«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән [ай]»,** – дип әйтә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

[1] Имам Әл-Бохариның хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имамнар Әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Шуңда да Рамазан аенда Коръәни Кәримне хәтем кылырга, аның аятьләре хакында фикерләргә, тормышыбызга кертеп җибәрергә тырышабыз.

Кәгъб бине Гоҗра радыяллаһу ганһе исемле сәхабә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер мәшһүр хәдисен сөйләгән: «Бер көнне Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләренә: «Мөнбәр янына килегез», – диде. Без килдек. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөнбәрнең беренче баскычына менгәч, «Әәмин», – дип әйтте. Мөнбәрнең икенче баскычына менгәч тә: «Әәмин», – дип әйтте һәм өченче баскычка менгәч янә: «Әәмин», – диде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хотбәне сөйләп бетергәннән соң аска төште, без аңа, бүген сездән элек ишетмәгән нәрсәләрне ишеттек, дип әйттек. Ул салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә болай диде: «Минем яныма Җәбраил галәйһиссәлам килде һәм мин мөнбәрнең беренче баскычына менгәч, ул: «Рамазан аен каршы алып, гөнаһлардан котылмаган кеше хәсрәттә булыр», – диде. Шул вакытта мин: «Әәмин», – дидем. Мин мөнбәрнең икенче баскычына менгәч, Җәбраил галәйһиссәлам: «Синең мөбарәк исемеңне ишетеп тә, салават әйтмәгән кеше хәсрәттә булыр», – диде. Мин янә: «Әәмин», – дидем. Мөнбәрнең өченче баскычына менгәч, ул: «Ата-ананың картлыкларын күреп тә, алар аша җәннәткә кермәгән кеше хәсрәттә булыр», – диде. Һәм мин янә: «Әәмин», – дидем»[1].

Бу хәдистән аңлашылганча, Рамазан аеның көннәрен зая үткәрү безне хәсрәткә сала. Рамазан ае үтеп тә, күңелләребездә берничди үзгәреш, калебләребездә ихласлык хасил булмаса, ни үкенечтер! Бу күркәм хәдистә тагын ике мөһим мәсьәлә бар: беренчесе – Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исемен ишеткәч, аңа хөрмәт, ярату йөзеннән салават сүзләрен әйтү. Икенчесе – сөекле әти-әниләребезне хөрмәт итү, аларга йомшак, күркәм мөгамәләдә булу. Бу мөһим төшенчәләрне аңламаучы, үтәмәүчеләрне Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм, хәсрәттә булыр, ди.

[1] Имам Әл-Бохариның хәдисләр җыентыгыннан.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, үзенең бәрәкәте, рәхмәте, гамәл-гыйбадәтләре белән Рамазан ае үтеп тә китте. Киләсе елларда да Рамазан айларын каршы алып, аның рәхмәтендә яшәүләребез насыйп булса иде. Рамазан аенда илебез, көнебез, тынычлыгыбыз өчен Раббыбызга һәрдаим догада булдык. Раббыбыз ихлас күңелләребездән кылган догаларыбызны кабул итеп, ил-көннәребезгә тынычлык, иминлек, татулык насыйп әйләсә иде. Бүгенге көндә чит җирләрдә йөрүче, Ватаныбызны саклаучы ир-атларыбызга саулык, рух ныклыгы бирсә иде. Дөньяларыбызда булган төрле бәла-казаларның, хәвеф-хәтәрләрнең артлары хәерле булып, зыян күргән кешеләребезгә Раббыбыз Аллаһы күркәм сабырлыклар, иминлекләр, саулык сәламәтлекләр насыйп итсен. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безләрне рәхмәтеннән аермыйча, ике дөнья бәхете, иман ныклыгы, гаиләләр тынычлыгы, саулык, хәерле, сәгадәтле тормышлар насыйп әйләсен.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безнең уразаларыбызны, намазларыбызны һәм укыган Коръәннәребезне, гамәл-гыйбадәтләребезне һәм изге гамәлләребезне кабул кылса иде. Безнең халәтләребезне һәм барлык мөселман өммәтенең халәтен хәерле кылса иде. Әәмин!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

# Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы

خطبة عيد رمضان

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ نَوَّرَ قُلُوبَ الْعَارِفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَالْإِيمَانِ وَشَرَحَ صُدُورَ الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ واَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ الرَّحْمَةِ وَالْغُفْرَانِ وَزَيَّنَ قُلُوبَ الْمُحِبِّينَ بِتِلاَوَةِ الْقُرْآنِ وَغَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ بَابٍ مِنْ أَبْوَابِ الْجِنَانِ كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ الزَّمَانِ: إِنَّ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ إِلَّا الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ، شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۞ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ وَأَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ ذُوالْعَفْوِ وَالْغُفْرَانِ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَهَادَةً نَاطِقَةً بِالْحُجَّةِ وَالْبُرْهَانِ صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى آلِهِ وَأَصْحَابِهِ صَلاَةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى أَبِي بَكْرٍ الصِّدِّيقِ وَ عُمَرَ الْفَارُوقِ وَ عُثْمَانَ ذِي النُّورَيْنِ وَ عَلِيٍّ الْمُرْتَضَى الأَئِمَّةِ رِضْوَانَ اللهِ عَلَيْهِم أَجْمَعِينَ ۞

أَمَّا بَعْدُ: أَيُّهَا النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَنَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى اللهِ ۞ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَّالَّذِينَ هُم مُّحْسِنُونَ ۞ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرآنِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَإِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ السَّمِيعُ الدُّعَاءِ

خطبة ثانية

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذَ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ ۞ إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا اَللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلاَئِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَعَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرَضِينَ ۞ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ وَارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَاحِمِينَ ۞

## Хотбәнең татарча укылышы

**Беренче хотбә** Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәввәра кулүүбәл-

гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти вәл-иимәән, вә шәрахә судүүрас-саадикыйнә би шәрхил-һидәәйәти вәл-гыйрфәән, вә әкрамә гыйбәәдәһүл-мү’миниинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вәлилләәһил-хәмд. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-саа’имиинә әбүәәбәр-рахмәти вәл-гуфраан, вә зәййәнә кулүүбәл мүхиббәйни битиләәвәтил Куръәни, вә галләка галәс-саа’имиинә әбүәәбән-нииραани фи шәһри рамәдаан. Вәгадә лис-саа’имиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лил-җәннәти бәәбән йүкаалү ләһүр-раййәән. Ләә йәдхулүүһү илләс-саа’имүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләҙии үнзилә фииһил-Куръәәнү һүдәл-линнәәси вә бәййинәәтин минәл һүдәә вәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһуу ҙүл-гафьүи вәл-гуфраан, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһуу. Шәһәәдәтән нәәтыйкатән билхүҗҗәти вәл бүрһәәни. Салләллааһу Тәгаалә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән. Хусуусан минһүм галәә Әби Бәкринис-Сыйддикый вә Гумәрал-Фәәрукый вә Гусҫмәәнәз-ҙиннүрайни вә Галийинил-Мүртәдал ә-иммәти, ридъвәәналлааһи галәйһим әҗмәгыийнә.

Әммә бәгъде: әййүһәннәәс, үсыйкүм гыйбәәдәллааһи вә нәфсии әүвәлән-битәкъүәллааһ. Әгууҙу билләәһи минәш шәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгалләҙиинәт-тәкау вәлләҙиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә вә ләкүм фил-куръәәнил-гаҙыйим, вә нәфәганәә вә иййәәкүм бил-әәйәәти үәҙҙикрил-хәкиим, иннәһуу һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галиййүл-гаҙыйимү сәмиигуд-дүгаа’.

### Икенче хотбә

Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһуу вә нәстәгыйнүһу вә нәстәгъфируһу вә ну’минү биһии вә нәтәүәккәлү галәйһи вә нәгуузү билләәһи мин шүруури әнфүсинәә вә мин сәййиәәти әгъмәәлинәә мән йәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү вә мән йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Вә әшһәдүән ләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһ, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһ. Иннәллааһә вә мәләә-икәтүһү йүсаллүүнә галәннәбиййи. Йәә әййүһәл-ләзиинә әәмәнүү саллү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли вә сәллим галәйһи вә галәә җәмигыйль-әнбийәә’и вәл-мүрсәлиин, вә галәә мәләә’икәтикәл-мукаррабиин. Вә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйн, вә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйн, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-арадыйн. Аллаһуммә-гъфир лилмү’миниинә вәл-мү’минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм вәл-әмъүәәт, вәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәәмәр-раахимиин.

## Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе

### Беренче хотбә

Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһы Тәгалә исеме белән.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыга гына мактау. Аллаһы Тәгаләгә якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгъфирәт (ярлыкау) һәм иман нуры белән нурландырган, тугрыларның (садыйкларның) күңелләрен һидаять һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына Рамазан ае уразасын бүләк иткән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен

бикләгән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһы Тәгалә) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә Пәйгамбәребез, ахырзаман пәйгамбәре хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр, аңа «Раййән» диелә. Ул ишектән Рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Рамазан ае кешеләргә туры юл күрсәтә, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу Итүче һәм мәгъфирәт Иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм расүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сәхабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһы Тәгаләнең коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм.

Ташлар белән кыйналып, Аллаһының рәхмәтеннән сөрелгән шәйтаннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә тәкъвалылар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы Тәгалә безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта, Ул (Аллаһы Тәгалә) гафу Итүче, Рәхимле, юмартлык Иясе, олуглык Иясе, бөек Зат һәм догаларны Ишетүче, кабул Итүче.

## Икенче хотбә

Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһы Тәгаләгә, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһы Тәгаләгә үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы

Тәгалә һидаять бирсә – аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса – аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә – күк әһелләреннән һәм җир әһелләреннән булганнарының барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит. Йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

*21 нче апрель вәгазе,*

*шәүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Шәүвәл аеның фазыйләте

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Рамазан аеның бетүе белән шәүвәл ае башлана. Бу айда алты көн ураза тоткан кеше бер ел ураза тоткандай булыр. Аны дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көнне дә, шулай ук Рамазан бәйрәме узганнан соң да тотып була. Бу ураза казага калган ураза булып саналмый. Ураза гаетенең беренче көнендә бәйрәм итеп, соңыннан икенче көнендә уразага керергә мөмкин.

Сахих булган бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Берәү Рамазан ае уразасын тотып, соңрак шәүвәл аенда да алты көн ураза тотса, бер ел ураза тоткан кебек булыр», – дип әйткән.

Бу сүз Рамазан ае уразаларын тотып, шәүвәл ае кергәннән соң, аның көннәрендә ураза тотучыга күпләп әҗер-саваплар биреләчәк, дигәнне аңлата, ягъни бу алты көн алдыннан Рамазан ае уразаларын тоту кирәк.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә: «Бер изгелек кылучыга ун савап язылыр», – дигән. Рамазан аеның 30 көн уразасын унга тапкырлаганнан соң чыккан санга шәүвәл аеның алты көн уразасын унга тапкырлаганнан соң чыккан санны кушсак, 360 көн килеп чыга. Бу санга игътибар итсәк, Рамазан ае һәм шәүвәл аеның алты көн уразаларын тоткан очракта, тулы бер ел ураза тоткандай булабыз икән. Шуңа да Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм «бер ел ураза тоткан кебек булыр» дигән.

Шәүвәл ае уразасы фарыз да, вәҗиб тә түгел, ул сөннәт гамәл. Әхмәд бине Хәнбәл рахимәһуллаһи: «Шәүвәл аеның алты көненең беренче көнендә тотылган уразаның савабы бик зур, кешенең 40 еллык гөнаһы булса да, Аллаһы Тәгалә аны гафу итәр. Һәм аңа 40 пәйгамбәрнең савабы язылыр», – ди. Бу да шәүвәл уразасына карата гына махсус шулай әйтелә.

Шәүвәл аеның икенче көнендә тотылган уразаның савабы өчен, 70 мәртәбә тырышлык күрсәтүгә чыккан кебек савап язылыр, бу кешегә кабер газабы булмас, диелә.

Кеше шәүвәл аеның өченче көнендә ураза тотса, йөз мең шәһитнең әҗер-савабы бирелер, аңа Кыямәт көненең авырлыгы җиңеләйтелер.

Дүртенче көнне ураза тотса, Аллаһы Тәгалә дөнья һәм Ахирәт теләкләреннән җитмеш теләген үтәр. Ифтар яисә сәхәр вакытында дога кылса, Аллаһы Тәгалә морадларын кабул итәр.

Бишенче көнне ураза тотучыга Аллаһы җәннәт киемнәрен кидерер һәм аның кылган догасын кабул кылыр.

Алтынчы көнне ураза тотучыга өммәтенең йөз мең кешесенә шәфәгать кылу хакы бирелер. Һәм аңа алтмыш мең ел гыйбадәт кылу савабын язар. Үлгәч, каберенә һәркөнне йөз мең фәрештә зиярат кылырга киләр. Һәм Кыямәт көненә кадәр гамәл дәфтәрләре ябылмас. Шул алты көн шәүвәл уразасын тотып, ул елны вафат булса, шәһит дәрәҗәсенә ирешер.

Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый сүзләрен риваять иткән: «Шәүвәл ае уразасының алты көнен тотучыны Аллаһы Тәгалә җәһәннәм чылбырларыннан азат итәр».

Әбү Һөрайрадан килгән риваятьтә болай диелгән: «Берәү шәүвәл аеның алты көн уразасын рәттән тотса, алты йөз мең ел гыйбадәт кылып уздырса да, шулкадәр әҗер-саваплар ала алмас иде. Бу аңа алты йөз мең дөя чалудан да фазыйләтлерәк булыр иде. Ул алты йөз мең колны азат иткән кебек әҗер-савапларга ирешер иде».

Алты көн шәүвәл ае уразасын тотучыга Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтенең бөтенесе кадәр савап язылыр һәм ул хәзрәти Габбас, хәзрәти Хәсән һәм хәзрәти Хөсәенгә күрше булыр, диелә. Ләкин шунысы мөһим: бу гамәлләр ихлас күңелдән башкарылырга тиеш.

Рамазан аеннан соң килә торган шәүвәл ае безнең өчен үзенә күрә бер җиңеллек булып тора, чөнки Рамазан ае уразаларыннан соң шәүвәл аенда да ураза тоту һәм аның өчен күпләп әҗер-саваплар бирелү – Аллаһының рәхмәте ул. Әмма без Рамазан ае үтте дә, димәк, гамәл-гыйбадәтләребезгә карата җиңел карарга тиеш дип, фикер йөртмик. Аллаһы Тәгалә биргән һәр ай, һәр көн безнең өчен мөмкинлек ул.

Рамазанда кылган изге гамәлләребез, биргән садакаларыбыз, төнге намазларыбыз, озаклап кылган догаларыбыз, динебез Исламны өйрәнү, китаплар уку, вәгазьләр, нәсыйхәтләр тыңлау, Коръәни Кәримне уку Рамазаннан соң да, шәүвәл аеннан соң да дәвам итәргә тиеш. Әйе, кемгәдер һәр көнне көненә 20 бит Коръән уку авыр булырга мөмкин. Әмма икенче берәүгә көненә 20 бит Коръән уку кыен түгел һәм шул рәвешле ул ай саен Аллаһының Китабын хәтем кыла ала. Башка берәү өчен көненә 10 бит яки 5 бит укырга җиңел булырга мөмкин, әмма без һич булмаса, көненә 2-3 бит булса да укысак та – бу да хәерле гамәл булыр. Вакыт үткән саен Коръән уку тизлегебез артып, Аллаһының рәхмәте белән, битләр санын тагы да үстерербез.

Гамәл-гыйбадәтләребезне күпләп, даими рәвештә кылу гадәтен Рамазан, шәүвәл аенда гына башкарып калмыйк, ә калган айларда да гыйбадәттә булыйк, чөнки гыйбадәттә булу – Аллаһы Тәгаләнең безгә биргән вазифасы ул. Аллаһы безне гыйбадәт кылыр өчен яратты. Ул болай дип әйтә:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

**«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Ә инде бу гамәлләрне кылуны Рамазаннан соң да дәвам итүгә килгәндә, моның мөһимлеге хакында фикерләгәндә, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Гайшә радыяллаһу ганһәдән китерелгән күркәм хәдисен искә төшерик. Ул болай дип яңгырый: «Изге гамәлләрне тиешле дәрәҗәдә, ихластан башкарыгыз. Һәм истә тотыгыз: сез җәннәткә Аллаһының рәхмәте белән генә керәчәксез. Шуны белегез: Аллаһы каршында иң сөекле гамәл – зур булмаса да, даими кылынган гамәл»[1].

Раббыбыз кылган изге гамәлләребездән риза булып, тоткан уразаларыбызны, укыган Коръәннәребезне кабул кылса иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ирек хәзрәт Җиһаншин,*
*Габдрәхим Утыз Имәни исемендәге*
*«Ал Таң» мәчете имам-хатыйбы*

[1]Имам Әл-Бохариның хәдисләр җыентыгыннан.

*28 нче апрель вәгазе,*

*шәүвәл аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Милләттәшләргә бер нәсыйхәт

Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин, вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Мөхтәрәм җәмәгать, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Бүгенге вәгазебез мөселман кешесенең башка дин вәкилләренә булган мөнәсәбәтенә багышланыр, иншәАллаһ. Бу вәгазебезне шартлы рәвештә ике өлешкә бүлербез, чөнки безнең берникадәр охшашлыгыбыз булса да, аларга да, безгә дә Аллаһы Тәгаләдән китаплар иңгән, пәйгамбәрләр килгән, дип бер-берләребездән охшашлык эзләсәк тә, дин ягыннан үзенчәлегебез булуын онытмыйк.

Раббыбыз Коръәни Кәримдә:

وَلَا تَنكِحُوا الْمُشْرِكَاتِ حَتَّىٰ يُؤْمِنَّ ۚ وَلَأَمَةٌ مُّؤْمِنَةٌ خَيْرٌ مِّن مُّشْرِكَةٍ وَلَوْ
أَعْجَبَتْكُمْ ۗ وَلَا تُنكِحُوا الْمُشْرِكِينَ حَتَّىٰ يُؤْمِنُوا ۚ وَلَعَبْدٌ مُّؤْمِنٌ خَيْرٌ مِّن
مُّشْرِكٍ وَلَوْ أَعْجَبَكُمْ ۗ أُولَٰئِكَ يَدْعُونَ إِلَى النَّارِ ۖ وَاللَّهُ يَدْعُو إِلَى الْجَنَّةِ
وَالْمَغْفِرَةِ بِإِذْنِهِ ۖ وَيُبَيِّنُ آيَاتِهِ لِلنَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَتَذَكَّرُونَ ﴿٢٢١﴾

**«[Ий иман китерүчеләр!] Мөшрик хатыннар иман китерми торып, алар белән никахланышмагыз: мөшрик хатын [чибәрлеге белән] сезне хәйран калдырса да, иманлы җария [сезнең өчен], әлбәттә, хәерлерәк. Мөшрик ирләр иман китерми торып, [мөселман хатын-кызларны] аларга кияүгә бирмәгез: мөшрик ир [күркәмлеге һәм байлыгы белән] сезне хәйран калдырса да, иманлы бер кол, әлбәттә, хәерлерәк. Алар [мөшрик ирләр һәм хатыннар] Утка чакыра. Аллаһы исә [мөэминнәр белән туганлашкан кешеләрне] Үз**

**теләге белән җәннәткә һәм мәгъфирәткә чакыра һәм кешеләргә [әмер-тыюларын белдергән дәлил вә] аятьләрен бәян итә, бәлки, алар үгетләнерләр», –** дип әйтә.

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:221

Әлеге аятьтә әйтелгәнчә, мөселманнар беренче чиратта үзара өйләнешергә тиеш. Кызганычка, безнең яшьләребез бу мәсьәләгә нык игътибар бирми. Бу хакта һәр имам вәгазьләрендә, нәсыйхәтләрендә ирештерергә тиеш.

Безнең татар халкы җирле халык булса да, соңгы гасырларда үзенең динен, телен, кыйбласын, мәсләген оныта башлады. Кызганыч ки, татар балалары арасында катнаш никахка керүчеләр артты. Кечкенә балалар, бигрәк тә шәһәр җирлегендә, туган телендә сөйләшә белми, аны өйрәнми. Әтиәниләр дә балалары белән рус телендә аралаша.

Без үзебезнең сәрмаяны, милли мәдәниятебезне, әдәп-әхлагыбызны алтын-көмешкә алыштырып, дәрәҗәле кешеләр булдык дип куанып, ялтыраган нәрсәгә алданып йөрибез. Кызганыч ки, күп кенә татар гаиләләре бу хакта бер дә уйланмый.

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе тарафыннан риваять кылынган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Йә, Раббым, Ислам динен Сиңа якынрак булган кеше белән зурласаң иде», – дип дога кылуын һәм Әбү Җәһел белән Гомәр бине Әл-Хаттабның исемнәрен атавын әйтелә.

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһе, Аллаһыга Гомәр бине Әл-Хәттаб якынрак булды, дип әйтә.

Шуннан чыгып галимнәребез башка диндә булган кешеләргә Аллаһы Тәгалә каршында һидаять сорап дога кылу динебезгә каршы килмәве хакында әйтә. Күршеләр, туганнар арасында һидаятьтә булмаучы кешеләр бар икән, без алар өчен Аллаһы Тәгаләдән туры юлга басуларын сорап, дога кылып яшәвебез хәерле була, иншәАллаһ.

Шулай ук кайбер галимнәребез мөселман булмаганнарга Аллаһы Тәгаләдән шифа, дәва сорап дога кылу мөмкин дип әйттеләр. Имам Ән-Нәвәви хәзрәтләре: «Мөселман булмаганнар өчен җеназа уку, алар өчен гафу-мәгърифәт сорау Коръән һәм иҗмагъ белән тыелды», – дип әйтте.

Инде вәгазебезнең икенче өлешенә күчик. Табигый ки, катнаш җәмгыятьтә яшәгәнлектән, күршеләребез, туганнарыбыз, хезмәттәшләребез, сабакташларыбыз арасында башка милләт, дин кешеләре күп.

Безнең халык элек-электән күршеләр белән дустанә мөнәсәбәттә яшәргә тырышкан. Әйе, шәһәр җирләрендә, күпкатлы йортларда күршеләр белән аралашып яшәү киң таралмаган. Ләкин мөмкинлек булганда күршеләргә ярдәм итү, аларның хәлләрен белү, аларга хәерхаһлы булырга тырышу әҗер-саваплы итә торган гамәлләрдәндер. Һәм, киресенчә, күршеләргә зыян китерү – күрше булмаучыларга зарар китерүгә караганда гөнаһлырактыр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Күрше хатыны белән зина кылу – башка ун хатын белән зина кылуга караганда гөнаһлырак. Күрше йортына карак булып керү – башка ун йортка карап булып керүгә караганда гөнаһлырак»[1], – дип әйткән.

Шуңа да безнең халык элек-электән күршеләргә карата аеруча да әманәтле булырга тырышкан, күршеләр белән ничек тә бозылышмаска, тату яшәргә омтылган. Бу гадәт буыннан-буынга күчеп килгән. Билгеле, күршеләребез арасында башка дин вәкилләре яки динсезләр, дәһриләр яшәсә дә, халкыбыз күрше хакының нинди кыйммәткә ия булуын онытмаска тиешле. ИншәАллаһ, кылган изгелекләребезне күреп, күршеләребезнең дә динебезгә карата хөрмәтләре артыр.

Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Мәккә мөшрикләренең потларын сүгүдән тыйды. Коръәни Кәримдә:

وَلَا تَسُبُّوا الَّذِينَ يَدْعُونَ مِن دُونِ اللَّهِ فَيَسُبُّوا اللَّهَ عَدْوًا بِغَيْرِ عِلْمٍ ۗ

[1] Имам Әхмәднең хәдисләр җыентыгыннан.

**«Сез аларны, Аллаһыны калдырып, табынган нәрсәләрен сүкмәгез [башка юл белән игелеккә чакырыгыз], юкса алар да белмичә чиктән ашып, Аллаһыны сүгәчәкләр...»** – диелгән.

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:108

Бу аятьтә әйтелгәнчә, әгәр без башка халыкларның гыйбадәт кыла торган потларын яманлыйбыз икән, аларның җавап йөзеннән Аллаһы Тәгаләне яманлаулары мөмкин. Шул нисбәттән башка диннәргә көлке белән карау, аларны мыскыл итү, дини хисләренә кагылу яхшы нәрсә түгел. Шуңа да мөселман кешесе һәр халык өчен изге булып тоелган дини хисләргә кагылмас, мондый гамәлләрдән ерак булыр.

Борынгыдан ук мөселманнар башка халыкларга чисталык, пакьлек, гаделлек, мәрхәмәтле, шәфкатьле булуы белән үрнәк булган. Безнең халык та әлеге сыйфталарга ия дип уйлыйбыз. Гасырлар дәвамында безнең халык күрше авылларда яшәгән рус, чуаш, удмурт, мордва, мари милләтеннән булган халыкларга ихтирам хисләре белән караган, аларның гадәтләрен хөрмәт иткән, алар белән ызгышмаган, талашмаган, тату булган. Бүгенге көндә оешмаларда башка милләт, дин кешеләре эшли икән, хуҗа булган кеше милләткә, дингә карап аларны аерырга тиеш түгел. Ул гадел булсын, хезмәт хакын барысына да вакытында түләсен, эшләгәненә, файда, табыш китерә алганлыгына карап, исәп-хисабы да гаделлек белән барырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә милләтебезгә, өммәтебезгә олуглык биреп, милләтебезнең төсен, динебезне югалтмыйча, саклап, балаларыбызга, оныкларыбызга тапшыра алсак иде. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының

саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Ясәвиев,*

*«Рәхмәтулла» мәчете имам-хатыйбы*

*5 нче май вәгазе,*
*шәүвәл аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Кем Ул Раббыбыз?

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Без Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә хакында ниләр беләбез? Аның исем-сыйфатларын өйрәнәбезме? Кем Ул Раббыбыз? Ул Үзен Коръәндә кем дип атый? Вәгазебез шушы сорауларга җавап бирүгә багышланыр.

Бер бәдәви Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килә дә: «Йә, Расүлуллаһ, миңа кешеләр белмәгән гыйлемнәр хакында хәбәр бир әле», – ди (ягъни яшерен гыйлемнәр хакында сорый). Расүлуллаһ аннан: «Син Миннән яшерен гыйлем хакында сорыйсың, иң мөһим булган гыйлем белән нинди гамәлләр кылдың соң?» – дип әйтә.

Бу кеше: «Гыйлемнең иң мөһиме кайсы соң, йә Расүлуллаһ?» – дип сорагач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул Аллаһы Тәгаләне хак тану белән тану», – дип әйтә.

Әлеге бәдәви: «Аллаһы Тәгаләне хак тану белән тану ничек була соң?» – дип сорый. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгаләне мисалсыз, шөбһәсез, тиңдәшсез, Бар, Бер итеп тану, Ул Заһир (Билгеле, Танылa, Беленә) һәм Яшерен (Аны тулысынча аңлап булмый) булуын, әүвәле (бөтен нәрсәгә хәтле Бар булуын) һәм ахыргысы (бөтен нәрсә дә үз барлыгында Аңа мохтаҗ) булуына, Аңа охшаган зат юклыгын, Аның уртагы юк икәнен чын мәгънәсендә аңлау», – дип җавап кайтара.

Аллаһы Тәгалә һәрвакытта да булган, Аңа кадәр берәү дә булмаган. Раббыбыз Бар, Бер һәм Ул барлык мәхлукатларны халык кылган, әмма Үзе берәүгә дә мохтаҗ түгел. Аның әти-әнисе дә, зөррияте, ягъни бала-чагасы да юк.

Раббыбыз Үзе хакында кайбер күркәм исем-сыйфатлары аша хәбәр бирде. Без Аның барлыгына, берлегенә, Галәмнәрнең Тәрбиячесе булганына иман китердек. Аңа күңелебезне, җаныбызны, тәнебезне тулысынча тапшырдык, итагать иттек. Һәм бөтен мәхлүкълар Аллаһының барлыгына, берлегенә дәлилле торган аятьләрнең галәмәтләре булып тора. Димәк, Үзенең сыйфатлары, исемнәре, гаделлеге белән Аллаһы Тәгалә тулысынча камил Зат.

Аллаһы Тәгалә шушы күркәм исемнәре белән Үзенә дога кылырга куша. Бу хакта Раббыбыз Коръәни Кәримдә әмер рәвешендә әйтә:

وَلِلَّهِ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَىٰ فَادْعُوهُ بِهَا ۖ

**«Аллаһыда – [иң матур һәм иң шәрәфле мәгънәләрне белдергән] күркәм исемнәр. Аңа шулар белән ялварыгыз»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:180

قُلِ ادْعُوا اللَّهَ أَوِ ادْعُوا الرَّحْمَٰنَ ۖ أَيًّا مَّا تَدْعُوا فَلَهُ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَىٰ ۚ

**«[Расүлем!] Әйт: «[Раббыгызга] Аллаһы исеме белән дәшегез яки [Аңа] Рахман исеме белән дәшегез. Аңа нинди исем генә бирелсә дә, иң күркәм исемнәр – Аныкы».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:110

Җәмәгать, Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме бар. Һәм без Аңа әлеге 99 исеме аркылы мөрәҗәгать итә алабыз. Бу исемнәр Коръәни Кәримдә бәян кылынганы гына, әмма Раббыбызның әле без белеп бетермәгән йөзләгән, меңләгән исеме бар. Аларны Аллаһы Тәгалә Үзе генә беләдер. Аллаһы

Тәгаләгә нинди генә исем белән мөрәҗәгать итсәк тә, ул дөрес була. Шушы исемнәргә карап, без Яратучыбызның кем икәнлеген аңлый алабыз. Аллаһы Тәгалә Ул Рәхмәт иясе, Ул Шәфкать иясе, Ул Мөкатдәс иясе, Ул Иминлек бирүче, Ул – Патша.

Әбү Һөрайрадан килгән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әлеге сүзләре риваять ителә: «Хакыйкатьтә, Аллаһы Тәгаләгә 99 исем тиешле. Берәү аларны атаса (икенче бер риваятьтә берәү аларны ятласа, өйрәнсә, диелә), җәннәткә керер»[1]. Ягъни бу исемнәрне өйрәнеп, алар белән гамәл кылу, бу исемнәрнең серенә төшенү, Аллаһы Тәгаләгә якынаю, Аңа күп итеп догалар кылу булса, иншәАллаһ, Аллаһы Тәгалә, һичшиксез, бу кешене җәннәткә кертер. Аллаһы Тәгаләне танып, Аның исемнәре белән яшәү, шул исемнәр белән Аңа мөрәҗәгать итү җәннәткә керүебезгә сәбәп булып тора. Дөреслектә, изге гамәлләр Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә якынайта.

Моннан тыш, Аллаһы Тәгаләнең исемнәрен өйрәнгән вакытта рухи көч барлыкка килә һәм кешенең калебендә Аллаһы Тәгаләгә карата ярату арта, ул ике дөньяның бәхет-сәгадәтенә ирешә. Кеше Аллаһы Тәгаләнең исемнәрен өйрәнгәннән, Раббыбызны тулысынча белгәннән соң, Аңа җаны-тәне белән омтылыр икән. Әгәр ул көферлектә булып, тәүбә кылган булса, беркайчан да көферлеккә кайтырга теләмәс, бөтен җаны-тәне Ислам дине өчен хезмәт итәргә теләр, гөнаһлы гамәлләрдән качып, Аллаһы Тәгалә риза була торган гамәлләрне генә кылырга тырышыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә килгәнчә, болай дип әйтер: «Йә, Раббым, мин Синең ачуыңнан Синең ризалыгыңа, Синең газабыңнан Синең рәхмәтләреңә сыгынамын. Сиңа күпме генә хәмед-сәналәр әйтсәм дә, болар җитмәс. Син шулхәтле мактаулы, бу мактауларны Синнән башка берәү дә белдерә алмас».

---

[1] Имамнар Әл-Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

Аллаһыдан башка бернинди дә илаһ юк. Аңа охшаш һичбер нәрсә юк һәм Аннан өстен чыга торган, ягъни Аны җиңеп чыга торган бернәрсә дә юк. Аның башлангычы, ахыры юк. Ул юкка чыкмый һәм Аның барлыгы беркайчан да бетми. Ул теләгән нәрсә генә була, Ул теләмәгән нәрсә булмаячак. Аны күз алдына китерү һич мөмкин түгел. Аны аң, акыл белән генә колачлап булмый. Ул мәхлүкъларга охшаш түгел. Ул Тере – беркайчан да үлми. Ул үзеннән-үзе бар һәм бар булуында берәүгә дә мохтаҗ түгел. Ул беркайчан да йокламый. Ул барча нәрсәләрне аңа ихтыяҗы булмыйча барлыкка китерүче һәм бернинди көч сарыф итмичә аларны ризыкландыручы. Курыкмыйча җаннарны алучы, бернинди мәшәкатьсез аларны Терелтүче. Раббыбыз бар нәрсәне халык кылганчы барлык сыйфатлары белән сыйфатланган иде. Аларны барлыкка китергәннән соң Раббыбызга бернинди сыйфат та өстәлмәде, ягъни Аллаһы Тәгалә мәхлүкъларын халык кылганнан соң гына шул сыйфатка ия булды дип санарга ярамый, ул сыйфаты Раббыбызның һәрвакытта да бар иде. Һәм ул сыйфатлар ничек бар иде, шулай үзгәрешсез калачак. Аллаһының Халикъ – Яратучы исеме Раббыбыз мәхлүкъларны яратканнан соң гына барлыкка килмәде, ул исем гел бар иде. Әл-Бәәри – Бар итүче исеме дә шулай ук, мәхлүкъларны бар иткәннән соң барлыкка килмәде, ә һәрвакыт бар иде. Тәрбияләүче исеме дә, тәрбияләнүчесе булганчы ук бар иде.

Аллаһы Тәгаләнең бөтен нәрсәгә дә көче җитә һәм бөтен нәрсә Аңа мохтаҗ. Бар нәрсә дә Аллаһы Тәгалә өчен җиңел һәм Ул бер нәрсәгә дә мохтаҗ түгел. Раббыбыз болай дип әйтә:

لَيْسَ كَمِثْلِهِ شَيْءٌ ۖ وَهُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١١﴾

**«Аңа [Аллаһы Тәгаләгә] охшаш бернәрсә дә юк [Аның хатыны яки баласы бар дип уйлап та булмый]. Ул – [һәрнәрсәне] Ишетүче, [һәрнәрсәне] Күрүче».**

«Әш-Шура / Киңәш», 42:11

Аллаһы Тәгалә Үзенең гыйлеме белән барча нәрсәне халык кылды, аларның тәкъдирләрен, әҗәлләрен билгеләде. Аларны бар иткәнче алар хакында барча нәрсәне дә белә иде. Болар аңа яшерен булып калмады. Аларны бар иткәнче үк нәрсә эшләгәннәрен төгәл белә иде. Ул Үзенә итагать итүне әмер итте, буйсынмаудан тыйды. Бөтен нәрсә Аллаһы Тәгаләнең тәкъдире, Аның теләге белән хәрәкәт итә, Аның теләге һәрвакытта да үтәлә. Аның теләгәненнән башка колларының бер теләге дә юк, ягъни аларның берсе дә үзе теләгәнчә генә эшли алмый, дигән сүз. Аллаһы Тәгалә теләгән нәрсә барлыкка килә, ә теләмәгән нәрсә барлыкка килми. Барча мәхлүкатлар Аның гаделлеге, рәхмәте, фазыйләте астында була. Раббыбыз Үзенә капма-каршы булган нәрсәләрдән өстен. Аның хөкемен беркем дә бетерә, кичектерә яисә үзгәртә алмый.

Боларның барчасына да иман китердек, барча нәрсәләр дә Раббыбыздан булуына инандык. Чын мөэминнең ышанычы шундый булырга тиеш: Ул Аллаһының кемлеген таныргa тиеш.

Аллаһы Тәгалә Үзен барлык мәхлүкатларына алар әле дөньяга килгәнче, Бәрзахи тормышта ук, таныткан. Раббыбыз бөтен җаннарны җыеп, «Мин сезнең Раббыгыз түгелме?» – дип сораган.

Димәк, җаннар җир йөзенә җибәрелгәнче үк, итагать итү, гыйбадәт кылу бары Аллаһы Тәгаләгә генә тиешле икәнен белгән һәм бу дөньяга фитри иман белән килгән. Ягъни адәм балалары кечкенәдән үк Аллаһы Тәгаләнең кем икәнлеген таный, чөнки моны аларга җаннар яратылуга ук Аллаһы Тәгалә таныткан.

Мөшрикләр Расүлебездән: «Синең Раббың кем? Ул нинди? Көмештәнме ул? Таштанмы? Без аны белмибез. Безгә Раббыңны күрсәт әле», – дип килеп сорагач, Раббыбыз «Ихлас» сүрәсен иңдерә.

Аллаһы Тәгаләне якыннан белер, Аны тояр өчен, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кылган гамәлләрне, ягъни аның Сөннәтен үтәргә тырышырга кирәк.

Иң беренче чиратта, хәләл булган ризыклар белән туклану, Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәү, тыйганнарыннан тыелу һәм Ислам динендә тәрбияләүче рухи остаз булдыру мөһим. Һәм иртәләрен, кичләрен Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм укыган зикерләрне, Коръән аятьләрен, нәфел намазларын уку да бик фазыйләтле гамәл.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгаләгә Аны күргән кебек гыйбадәт кыл. Син Аны күрмәсәң дә, Ул сине күрә», – дип әйткән. Ягъни кеше гыйбадәтләрен Аллаһы Тәгаләне күргән кебек кылырга теләсә, шушы нәсыйхәтләрне үтәргә тиеш. Шуннан соң галимнәр кешене чын гариф, ягъни Аллаһыны танучы дип атый.

Әйе, Аллаһының исем-сыйфатларын өйрәнү, гыйлем алу да мөһим, әмма Аллаһыны бар күңелебез белән тоярга телибез икән, югарыда искә алынган киңәшләргә колак салырга кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кеше Аллаһы Тәгаләгә нәфел намазлары, зикерләре белән якынаер», – дип әйткән. Аллаһы Тәгалә безгә шул дәрәҗәләргә ирешергә насыйп итсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*
*«Саләх» мәчетенең имам-хатыйбы*

*12 нче май вәгазе,*

*шәүвәл аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буена 1444 ел*

# Йосыф галәйһиссәләм – гадел җитәкче

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, динне аңлаткан, өйрәткән, үрнәк булып яшәп күрсәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен. Аллаһы Тәгалә изге җомга көнендә мәчеткә килеп кылган гыйбадәтләребезне кабул кылсын. Атлап килгән һәрбер адымнарыбыз өчен әҗер-савапларын насыйп итсен. Ниндидер бик җитди сәбәпләр белән килеп җитә алмаган мөселман кардәшләребезгә күңелләрендәге булган ниятләренә, омтылышларына карап, Аллаһы Тәгалә савапларын насыйп кылсын. Вәгазьләнеп иманнарыбызны куәтләргә, дөнья өчен, Ахирәт өчен файдалы сүз, файдалы фикер аңларга һәрбарчабызга насыйп булсын.

Аллаһы Тәгалә кешеләргә туры юл күрсәтер өчен, Коръән китабын иңдерде. Аллаһы Тәгалә Коръәндә төрле гыйбрәтле кыйссалар китерә. Ни өчен? Кешеләр шуны укып, үзләренә файдалы дәресләр алып, тормышта яшәгәндә куллана алсын өчен.

Коръәндә шулай ук пәйгамбәрләр белән бәйле кыйссалар бар. Йосыф сүрәсендә Йосыф галәйһиссәламнең тормышы бик җентекләп сөйләнә. Коръәндә Йосыф галәйһиссәламнең берүзен иң якын кешеләре коеда ташлап калдырулары, аның кол итеп сатылуы, гаепсезгә зинданга ташлануы тасвирланган. Ул шул авырлыкларны Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзмичә, лаеклы итеп үтеп чыга, чөнки иманлы кешенең бер вакытта да ташламаучы Раббысы, таянычы бар икәнен ул бик яхшы аңлый. Шуның

өчен дә, бик авыр хәлгә калган вакытта да, тормыш авырлыклары алдында сынмый, чөнки дөньяда нинди генә җиңел яки авыр хәлләр булмасын, иманлы кеше һәрвакыт отышта булачак. Бу турыда Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә болай дип әйтә: «Иманлы кешенең хәле гаҗәеп, һәрнәрсә аның өчен хәерле. Бу иманлы кешегә генә бирелә. Әгәр аңа бер яхшылык, нигъмәт килсә, ул Аллаһыга рәхмәтен белдерә. Бу аның өчен хәерле була. Моның өчен аңа савап языла. Әгәр аңа бәла-каза, авырлык килсә, ул сабыр итә. Бу аның өчен хәерле була. Моның өчен аңа савап языла». Ягъни иманлы кеше гел отышта була. Шул ук вакытта моңа ирешү өчен, нык иманлы булу кирәк.

Мөселман кешесе дистәләрчә еллар күп көч түгеп, тырышып эшли. Шуның нәтиҗәсендә дөньяда нинди генә зур дәрәҗәгә, зур байлыкка ирешсә дә, Карун кебек, «Мин моңа үз белемем, үз тырышлыгым белән ирештем», дип уйламый, мактанмый, тәкәбберләнми. Киресенчә, бу Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән булды дип, нәтиҗәне Раббысы белән бәйли. Ә инде тормышта авырлыклар килсә, бөтен дөньяны сүгеп, кешеләрне гаепләп йөрми. Бигрәк тә куркыныч булган гамәлне кылмый: Аллаһы Тәгаләне гаепләми, ә күркәм сабырлык күрсәтә, шуның аркасында зур савапларга ирешә. Менә бу иманлы кеше юлы.

Пәйгамбәрләрнең тормыш юлында моңа мисаллар бик күп. Бу дөнья җәннәт бакчасы түгел, шуңа бу дөньяда бер кайгысыз, авырлыксыз яшәргә өметләнгән кеше ялгыша. Шулай ук, кемгәдер ниндидер авырлык килгәч, аңа гөнаһы өчен бирелде, дип хөкем итәргә ашыкмаска кирәк. Кайчакта мөселманнар арасында да шундый сүзләр ишетергә туры килә, кемгәдер бер авырлык, бәла-каза килсә, «Аңа бу авырлык гөнаһы өчен бирелде», диләр. Каян беләсең, бәлки Аллаһы Тәгалә аңа бу авырлыкны җәннәттә дәрәҗәсен тагын да югарырак күтәрер өчен биргәндер?!

Үзеңә килгәндә, әлбәттә, бераз уйлап, фикерләп алу комачауламас. Бу сынау миңа ни өчен килде икән? Намазларымны үз вакытында укып

бараммы? Әти-әниемне рәнҗетмәдемме? Туганнар хакын үтимме? Кеше хакына кермәдемме? Белгәнебезчә, пәйгамбәрләргә дә шактый сынаулар, авырлыклар килгән. Ни өчен? Гөнаһ кылганнары өченме? Әлбәттә, юк, чөнки Аллаһы Тәгалә аларны гөнаһлардан пакь, ерак кылды. Пәйгамбәрләр гөнаһсыз һәм Аллаһыга иң якын кешеләр.

Йосыф галәйһиссәлам дә зур, авыр сынауларны уза. Берсенең нәфесенә охшаган гөнаһны эшләмәгәнгә, аңа каршы килгәнгә күрә, аны ачу белән, үч итеп зинданга ябалар. Ләкин ул Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзми. Шуңа Аллаһы Тәгалә дә аңа гел ярдәмен күрсәтеп тора, аңа төшләр юрау гыйлемен бирә. Тоткында вакытта да, андагы кешеләргә файда гына китерүче, хикмәтле кеше булуын күрсәтә ул. Йосыф галәйһиссәлам башкаларга Аллаһы Тәгаләгә иман китерүнең кирәклеген, Кыямәт көнендә дөньяда кылган бөтен гамәлләр өчен җавап бирәсе булачагын аңлата.

Аллаһы Тәгалә Йосыф пәйгамбәрне зинданнан чыгара. Аны һәм аның гыйлемен кешеләргә кирәкле итә. Килеп туган мәшәкатьнең чишү юлын аның белән бәйли.

Бер көнне Мисыр патшасы төш күрә. Аның төшен берәү дә юрый алмый. Йосыф галәйһиссәләм зинданда вакытта бер кешенең төшен юраган була. Зинданнан чыгып, хәзер патша янында хезмәт итүче бу кеше тиз генә Йосыф галәйһиссәлам янына барып, төшне юрата. Төшне юраганда җиде ел гадәттәгечә иген игәргә, аның аз өлешен генә ашап, калганын башакларда сакларга куша, чөнки аннан соң җиде ел корылык киләчәген, шул вакытта саклаганнарны кулланып булачагын аңлата. Йосыф пәйгамбәр патшаның төшен юрап кына калмый, ә шуның чишелешен дә өйрәтә, корылык елларында илне, халыкны ачлыктан коткару юлларын да күрсәтә. Моны ул: «Җиде ел уңышлы ел булыр, аннан җиде ел корылык булачак. Болардан соң унбишенче елда яңгырлар күп явып, игеннәр бик күп уңыш бирәчәк. Җимеш агачлары да күп җимеш бирер», – дип аңлатып бирә. Бу төш 14 ел дәвамында азык-төлекне, ризыкны саклап тотарга кирәклеген аңлата тор-

ган төш була. Шулай итеп, Йосыф галәйһиссәлам зур дәүләтнең 15 еллык икътисади азык-төлек программасын планлаштырып, төзеп бирә. Патшага төшнең ничек юралуын сөйләгәч, патша Йосыфны үзе янына алып килергә дип, ярдәмчесен җибәрә. Ул аны зинданнан чыгарырга килүен әйткәч, Йосыф алдан уйлап эшләүче, хикмәтле кеше буларак, тизрәк чыгарга ашыкмый. Ни өчен? Аның өчен үзенең гаепле булмавын дәлилләү бик мөһим була, чөнки әгәр ул акланмыйча иреккә чыкса, аннан соң гаепле булмаганын раслый алмаска мөмкин иде. Алга таба иреккә чаккач, патша аның белемле икәнен күреп, дәрәҗәле урынга куйса, шулвакыт берәр хөсетле кеше табылып, элекеге «гаебен» искә төшерергә, аны пычратырга мөмкин. Шуңа күрә ул, гадел хөкем булмыйча, төрмәдән чыгарга омтылмый.

Нахакка гаеп ташланганда авыр булса да, барыбер вакытлар узгач, гадел кеше һәм гаделлек өскә чыгачак. Бу Гадел булучы Аллаһының үзгәрмәс кагыйдәсе. Кемдер башкаларны алдап, золымлык кылып, өстен чыккан кебек күренсә дә, ул чынлыкта оттырышта, түбән төшүче, дөньяда һәм Ахирәттә үзенә генә зыян салучы булачак, чөнки бөтен нәрсәне күреп торучы Аллаһыны алдалап булмый һәм кылган начарлык өчен бу дөньяда да, Ахирәттә дә җавап бирәсе булачак.

Йосыф галәйһиссәламне аклыйлар, начарлык кылу аның уенда да булмаганы ачыклана. Халыкка файдалы хезмәт кыла алачагын уйлап, үзе патшадан илдәге байлыкның саклаучысы, ягъни финанс министры вазифасына билгеләвен сорый. Акыллы патша аның чын, оста белгеч икәнен күрә һәм шул вазифага билгели.

Вакытлар уза, Йосыф галәйһиссәлам үз вазифасын яхшы итеп, камил рәвештә башкара, Аллаһының рәхмәте белән, шул җирлекне ачлыктан коткара. Аның иленә хәтта күрше дәүләтләрдән дә ашлык алырга киләләр, ул гадел итеп бөтен кешегә өлеш чыгара. Акыллы патша аның ил белән яхшы идарә итәчәген күреп ала да, үз патшалыгын патша булырга лаеклырак булган Йосыф галәйһиссәламгә тапшыра. Шулай итеп Йосыф галәйһиссәлам

зур Мисыр дәүләтенең патшасы була.

Уйлап карасак, җәмәгать, бу Аллаһының кодрәтенә һәм хикмәтенә гаҗәеп мисал булып тора. Йосыф галәйһиссәлам башта коеда үлем көтүче кеше иде, аннан кол итеп сатылды, озак еллар зинданда утырды. Әмма ул бервакытта да Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзмәде. Үзеннән торганның бөтенесен эшләп, югары дәрәҗәгә күтәрелде. Шул вакыттагы зур дәүләтнең финанс министры булып билгеләнде. Еллар узгач зур дәүләтнең патшасы булу дәрәҗәсенә иреште. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә:

قُلِ ٱللَّهُمَّ مَٰلِكَ ٱلْمُلْكِ تُؤْتِي ٱلْمُلْكَ مَن تَشَآءُ وَتَنزِعُ ٱلْمُلْكَ مِمَّن تَشَآءُ وَتُعِزُّ مَن تَشَآءُ وَتُذِلُّ مَن تَشَآءُ ۖ بِيَدِكَ ٱلْخَيْرُ ۖ إِنَّكَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ ﴿٢٦﴾

**«[Расүлем!] Әйт: «Ий падишаһлыкның хуҗасы Аллаһы! Син хакимлекне теләгәнеңә бирәсең, теләгәнеңнән тартып аласың; теләгәнеңне [дөньяда яки Ахирәттә, яки икесендә дә] олылыйсың, теләгәнеңне [ике җиһанда рисвай итеп] хур итәсең [һәм дәрәҗәсен төшерәсең]. Бөтен яхшылык [һәм яманлык] – Синең генә хакимлегеңдә. Һичшиксез, Син – һәрнәрсәгә Кодрәтле»,** – дип әйтә.

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:26

Һәрбер кеше дә тормыш дәверендә шуңа охшаш авыр хәлләрдә калырга мөмкин. Якын кешеләрнең ташлап китүләре, үлем көтеп яту, тормыш кыенлыклары арасында «кол» дәрәҗәсенә төшү, иректән мәхрүм булу кебек хәлләр килеп чыга ала. Менә шул авырлыкларны җиңеп чыгарга мөселман кешесенә аның иманы ярдәм итә. Мөселман кешесе бервакытта да Аллаһының рәхмәтеннән өметен өзми. Үзеннән торганның бөтенесен дә эшли. Һәм дөньяда яхшы нәтиҗәләргә, ә Ахирәттә мәңгелек җәннәт нигъмәтләренә ирешә. Шундый караш белән яши торган мөселман кешесе

тормышта һәрвакыт кәнагать булачак, үзен һәрвакыт бәхетле хис итәчәк.

Аллаһы Тәгалә кылган изгелекләребезне кабул кылсын. Изгелекләребезнең файдаларын дөньяда һәм Ахирәттә күреп сөенергә, җәннәтләрдә күрешергә насыйп итсен.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рифат хәзрәт Ибраһимов,*
*Кукмара районы Зур Сәрдек авылы имам-хатыйбы,*
*Кукмара мәдрәсәсе мөгаллиме*

*19 нчы май вәгазе,*

*шәүвәл аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# «Мине Аллаһы кичермәс» дип әйтү – гөнаһмы?

Мәрхәмәтле һәм Рәхимле галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләгә хәмедләребезне, олуглауларыбызны һәм шөкраналарыбызны җиткерәбез. Аллаһы Тәгаләнең Расүле, хаклыкны җиткерүче, Раббыбызның мостафасы Пәйгамбәребезгә салават-сәламнәр әйтәбез.

Әссәләмү галәйкүм, хөрмәтле җәмәгать, мәхәллә халкы, мөселман дин кардәшләрем! Көннәрнең иң хәерлесе булган җомга көне һәрбарчабызга мөбарәк булсын. Җомга көненең фазыйләтләренә, вәгъдә ителгән әҗер-савапларына ирешергә насыйп итсен. Аллаһы Тәгалә һәрбарчабыздан разый булсын, ике дөнья бәхете насыйп итсен.

Хөрмәтле җәмәгать, безнең яшәешебез Аллаһының рәхмәте белән бара. Һәрбер сулышыбыз Аллаһы әмере белән, Аның безгә карата рәхимле, рәхмәтле булуы белән бәйле. Дөньяның гаять матурлыгы, барлык нигъмәтләрнең булуы Аллаһының рәхмәтедер. Шулай ук динебез дә безгә карата Аллаһының рәхмәте ул. Аллаһы Тәгалә безне хаклыкны аңлап, иман китереп, изге гамәлләр кылып, югары әхлаклы булып яшәүгә, дөнья һәм Ахирәттә бәхетле булуга чакыра. Коръән укый башлаганда да Аллаһының Рәхимле һәм Шәфкатьле дигән бөек исемнәре белән башлыйбыз.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләре белән сөйләшеп утырганда алар яныннан баласын күтәреп бер хатын үтеп китә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләреннән: «Бу хатын үз баласын утка ташлый алыр идеме?» – дип сорый. Алар: «Юк, Аллаһы Тәгалә белән ант итәбез, бу хатын мондый эшне эшли алмас иде», – дип җавап бирә. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу

галәйһи вә сәлләм: «Ә Аллаһы Тәгалә Үз колларына карата, бу хатын үз баласын кызгануга караганда да, рәхимлерәк», – дип әйтә.

Һичшиксез, бу бик күркәм аңлату! Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, Аңа гына хас рәвештә, чиксез һәм киңдер.

Кайвакытта: «Мин күп гөнаһлар кылдым, Аллаһы кичермәс инде», яки билгеле бер кеше турында: «Ул кеше бик гөнаһлы, Аллаһы аны ничек кичерсен инде, нәрсә эшләсә дә, файдасы булмас», – дигән сүзләр ишетергә туры килә. Җәмәгать! Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән, кичерүеннән өмет өзү – шайтаннан, чөнки шайтанның гына өмете юк, ә безгә, җаныбыз тәнебездә вакытта, Аллаһының рәхмәтен өмет итеп, гафу итүен сорауда, тәүбәдә булу кирәк.

Шунысы да бик мөһим: башкаларга да Аллаһының рәхмәт ишекләрен ябарга хакыбыз юк. Нинди генә гөнаһ кылган булсалар да, иң беренче, Раббыбызның рәхмәтенә этәрү, аларга рәхимле булу сорала. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә, бик катгый итеп: «Бәндәләргә рәхимле булмаучыга рәхимлелек булмас», – дигән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хакында шундый бер риваять бар: көннәрдән бер көнне ул сәхабәләр белән утырганда кисәк кенә сүзен бүлеп: «Борылып карагыз әле, хәзер артыгыздан җәннәт кешесе үтеп китәр», – дигән. Сәхабәләр борылып карса, Мәдинәдә яшәүче берәү узып бара икән. Икенче көнне бу хәл тагын кабатланган. Өч көн шулай дәвам иткән. Бер сәхабә бу хәлгә бик аптыраган. Хикмәтне белү өчен, хәйлә табып, өч көнгә шул кешенең өенә кергән. Ул шул кешенең гаиләсе белән көн дә иртән торган, ашаган, эчкән, йоклаган. Өченче төнне хуҗага хәйләсен чишкән: «Расүлебез өч көн рәттән синең хакта «җәннәт кешесе» дип әйтте. Нинди изгелегең бар икән дип, хәйлә табып, синең өеңә кердем. Моның өчен мине кичер, гафу ит. Бездән артык намаз укымыйсың, бездән артык изгелегең дә юк шикелле. Нинди гамәлең өчен Аллаһы сине исән чакта ук җәннәт белән куандыра?» – дип сораган. Йорт хуҗасы: «Бел-

мим. Син күргәнчә, намаз укыйм, нәфел уразалары тотам, калганы миңа мәгълүм түгел», – дигән. Теге кеше саубуллашып чыгуга таба кузгалгач, йорт хуҗасы аны туктатып, чакырып керткән һәм: «Намаз уку, ураза тотудан тыш, тагын бер гадәтем бар: һәр кичне йокларга ятар алдыннан, башны мендәргә куйганчы, Аллаһы Тәгаләгә ялварам: «Бүген яки, гомумән, мине рәнҗеткән, миңа карата хаксызлык кылган кеше булса, барысын да гафу итәм. Минем аркамда аларны җәһәннәм белән газаплама», – дип әйтәм», – дигән. Бу сүзне Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә җиткергәннәр. Ул: «Бу кеше киң күңелле булып, кешеләрне гафу итә белгән өчен, Кыямәт көнендә Аллаһы аның гөнаһларын кичерер», – дигән.

Димәк, кешеләрне кичерә, гафу итә белү киң күңелле, юмарт булуны күрсәтә. Икенчедән, башкаларны гафу итү – үзебезнең хатакимчелекләрнең Аллаһы Тәгалә каршында кичерелүенә бер сәбәп булып тора. Без шуны белергә тиеш: нинди генә хаталарыбыз, гөнаһларыбыз булса да, Аллаһы Тәгалә кичерә.

Шайтанның максаты – безне Аллаһының рәхмәтеннән ваз кичтерү, өметебезне өзү. Шуңа күрә шайтанга ярдәмче булмыйк, Аллаһының яраткан бәндәсе булыйк. Якыныбыз, кардәшебез безгә карата ниндидер бер авырлык китерсә дә, гөнаһ эшләсә дә – кичерә белик. Тормышта туганнар, кардәшләр арасында, гаиләдә кичерә алмау сәбәпле туганлык җепләре өзелүен, гаиләләр таркалуын, кардәшлек беткәнен күрергә туры килә. Асылда боларга җиткергән сәбәпләр бик гади яки кечкенә булып, үзебезнең кичерә алмавыбыздан киләдер. Кичерү Аллаһы Тәгаләнең олуг сыйфаты булып, бездә дә бу сыйфатның чагылышы булырга тиеш.

Әй, кардәшләрем, уйланыйк. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре чиксез. Аллаһы Тәгалә безнең онытылучан булуыбызга, гөнаһлар кылуыбызга карамастан, безгә Үзенең рәхмәтен вәгъдә итә.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

قُلْ يَا عِبَادِيَ الَّذِينَ أَسْرَفُوا عَلَىٰ أَنفُسِهِمْ لَا تَقْنَطُوا مِن رَّحْمَةِ اللَّهِ ۚ إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا ۚ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ ﴿٥٣﴾

**«Әйт: «Ий үз-үзләренә каршы зарарда булган колларым! Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки Аллаһы [ширектән тыш] барлык гөнаһларны да ярлыкый!» Һичшиксез, Ул – [гөнаһларны күпләп] Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:53

Без – Адәм балалары, хаталанабыз, ялгышабыз, әмма вакытында хатабызны аңлап, Аллаһыга кайтып гафу сорасак, Аллаһы Кичерүче, Ярлыкаучы, Рәхимле, Шәфкатьле Зат. Аллаһының рәхмәтеннән өметебезне өзмик.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Инсаф хәзрәт Ибатуллин,*

*«Динислам» мәчете имам-хатыйбы*

*26 нчы май вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 6 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Лут галәйһиссәлам кавеменең һәлакәте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин, вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн, әмма бәгъде. Ошбу дөньяларны юктан бар кылып, безләрне иң хәерле рәвештә яраткан, безләргә Үзенең иксез-чиксез нигъмәтләрен биреп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, шөкерләребез булса иде.

Галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелмеш, һәрдаим «өммәтем, өммәтем» дип, безнең өчен дога кылып торган Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең түреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, яңадан Аллаһының рәхмәте белән, иң хәерле көннәрдә – җомга көннәрендә, иң хәерле җирләрдә – мәчетләребездә җыелыштык. Аллаһы шушында килүебез сәбәпле, һәрбер адымнарыбыз саен гөнаһ, хата-кимчелекләребездән арынырга насыйп итсен. Һәм шул адымнарыбыз саен изгелекләребезне арттырып, һәммәбезгә дә хаҗ һәм гомрә кылган савапларга ирешергә насыйп вә мәяссәр әйләсен.

Еш кына бүгенге көндә: «Без Аурупадан, Америкадан артта калдык», – дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Моның хакмы, юкмы икәнлеген аңлар өчен, бу сүзләргә акыл белән карыйк. Бүгенге көндә Аурупада әти-әниләрен картлар йортына, балаларын балалар йортына озаталар, әфьюн куллану, фәхишәлек рәсми рәвештә рөхсәт ителгән. Моннан тыш, мәҗбүри рәвештә алга сөрелеп бара торган мәсьәләләрнең берсе – хатыннар белән

хатыннар, ир-атлар белән ир-атларны өйләнештерү. Шушы пычраклыкка, фәхишәлеккә баткан Аурупадан артта калдыкмы соң без?! Юк, хакыйкатьтә, без бүген үзебезнең пакь булган динебездән артта калып киләбез. Безнең милләтебезне чисталыкка, бер-береңә карата хөрмәт күрсәтергә өйрәткән, әти-әни, күрше хакын югары дәрәҗәгә күтәргән пакь динебездән артта калуыбыз сәбәпле, гөнаһка батабыз. Без үзебезне кабатланмас кешеләр итеп санасак та, безгә кадәр дә бездән акыллырак, көчлерәк булган кавемнәр яшәгән, әмма аларның юк ителү сәбәбе күп очракта кылган гөнаһлары белән бәйле иде.

Шундый халыкларның берсе – Лут галәйһиссәлам кавеме. Алар нинди гөнаһ кылды? Ни өчен Аллаһы Тәгалә аларны юк итте? Һәм ни рәвешле юк иткәне хакында без, иншәАллаһ, әлеге вәгазебездә сөйләшербез.

Лут галәйһиссәлам Ибраһим галәйһиссәламгә беренче булып иярүчеләрдән булды. Лут галәйһиссәлам, Аллаһының рәхмәте белән, берничә шәһәрдән гыйбарәт булган бер өлкәнең халкына пәйгамбәр буларак җибәрелә.

Галимнәр: «Бу дөньяда Лут галәйһиссәлам кавеменнән дә түбән дәрәҗәдә әхлаксыз булган берәр халык бармы икән, белмибез», – диләр. Аларның әхлаксызлыклары шундый чиккә җиткән иде, хәтта ки дөньяда аларга кадәр һичбер халык эшләмәгән гөнаһны кыла башладылар.

Коръәни Кәримдә Раббыбыз бу хәлләр хакында болай дип әйтә:

إِذْ قَالَ لَهُمْ أَخُوهُمْ لُوطٌ أَلَا تَتَّقُونَ ﴿١٦١﴾ إِنِّي لَكُمْ رَسُولٌ أَمِينٌ ﴿١٦٢﴾
فَاتَّقُوا اللَّهَ وَأَطِيعُونِ ﴿١٦٣﴾وَمَا أَسْأَلُكُمْ عَلَيْهِ مِنْ أَجْرٍ ۖ إِنْ أَجْرِيَ إِلَّا عَلَىٰ
رَبِّ الْعَالَمِينَ ﴿١٦٤﴾

**«[Нәсел ягыннан] Кардәшләре Лут аларга әйтте: «[Аллаһыга ширек кылудан] Һич курыкмыйсызмы? Һичшиксез, мин – сезгә [Аллаһыдан] ышанычлы бер илчемен. Аллаһыдан куркыгыз һәм**

**миңа итагать итегез. Мин бит сездән моның өчен түләү сорамыйм. Минем әҗерем – Аллаһыда гына»;**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:161-164;

وَلُوطًا إِذْ قَالَ لِقَوْمِهِ أَتَأْتُونَ الْفَاحِشَةَ مَا سَبَقَكُم بِهَا مِنْ أَحَدٍ مِّنَ الْعَالَمِينَ ﴿٨٠﴾ إِنَّكُمْ لَتَأْتُونَ الرِّجَالَ شَهْوَةً مِّن دُونِ النِّسَاءِ ۚ بَلْ أَنتُمْ قَوْمٌ مُّسْرِفُونَ ﴿٨١﴾

**«Лут [галәйһиссәламне] дә өммәтенә пәйгамбәр итеп Без җибәргән идек]. Менә ул кавеменә әйтте: «Галәмнәрдән һичбере сезгә кадәр [мондый бернәрсә] кылмаган шул кабахәт эшне кыласызмы әллә?» Сез, хатыннарыгызны калдырып, шәһвәт белән ирләргә якынаясыз [җенестәшләрегез белән мөнәсәбәттә буласыз]. Һичшиксез, сез – [һәр эштә] чиктән ашучы кавем».**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:80-81

Хакыйкатьтә, Лут галәйһиссәлам олы дошман белән очрашты. Халкын йомшаклык, хикмәт белән дингә, нурга чакырса да, күбесе аңа иярмәде. Лут галәйһиссәлам: «Йә, кавемем, Аллаһы Тәгаләдән куркыгыз, миңа итагать итегез», – дисә дә, мөшрик булган халкы аны инкяр итте. Һәм үзара, Лут галәйһиссәләмне һәм аңа иярүчеләрне куып чыгарыйк, чөнки алар безнең кылган гамәлебезне сөймиләр, дип сөйләштеләр.

Җәмәгать, алар кылган гамәл, чыннан да, бик пычрак гамәл иде. Алар пәйгамбәрләренең үгет-нәсыйхәтләренә болай дип җавап бирде:

لَئِن لَّمْ تَنتَهِ يَا لُوطُ لَتَكُونَنَّ مِنَ الْمُخْرَجِينَ ﴿١٦٧﴾

**«Ий Лут! Әгәр дә [сүзләреңнән] ваз кичмәсәң, [арабыздан] чыгарылганнардан булачаксың».**

«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:167

Әмма Лут галәйһиссәлам, әлбәттә, бу янаулардан курыкмый. Ул халкына алар күпме генә карышса да, бу дәгъватны дәвам итәчәген, кылган гамәлләренең олы гөнаһ икәнлеген кешеләргә җиткерәчәген, аларны дингә, хакыйкатьтә чакыруны дәвам итәчәген әйтә. Ләкин мөшрикләр аны куркытмакчы була һәм Лут галәйһиссәлам Раббыбыздан ярдәм сорап дога кыла.

Аллаһы Тәгалә Лут галәйһиссәламнең догасын кабул итә һәм шушы җирлеккә Җәбраил галәйһиссәлам җитәкчелегендә фәрештәләр җибәрә. Алар өйлә вакытында күркәм йөзле, нурлар балкып торган яшь егетләр кыяфәтендә Лут галәйһиссәлам янына килә. Ул алардан: «Мин сезне моңа кадәр күргәнем юк иде. Сез кемнәр?» – дип сорый. Алар: «Ий Лут! Без мосафирлар», – дип җавап кайтара. Лут галәйһиссәлам алар өчен куркып кала. Бу хакта Коръәндә болай диелгән:

وَلَمَّا جَاءَتْ رُسُلُنَا لُوطًا سِيءَ بِهِمْ وَضَاقَ بِهِمْ ذَرْعًا وَقَالَ هَٰذَا يَوْمٌ عَصِيبٌ ﴿٧٧﴾

**«Илчеләребез Лут [галәйһиссәламгә] килгәч, ул [ливатага бирелгән бозык кавеменнән] алар өчен борчуга төште һәм көче [азлыгы] аркасында кыенлык кичерде дә: «Бу – бик читен бер көн», – диде».**

«Һуд», 11:77

Лут галәйһиссәлам мосафирларны кире кага алмый иде, әмма шул ук вакытта халкы аларга зыян китерер дип, бик нык куркуга кала, чөнки ул бу яшь егетләрнең фәрештәләр булуын белми. Ул алардан: «Сез бу халыкны һәм аларның нинди пычрак гамәл кылуларын беләсезме?» – дип сорый. Мосафирлар: «Юк, белмибез. Безгә хәбәр ит», – дип әйтә. Лут галәйһиссәлам халкына каршы шаһитлек китереп, аларның нинди гамәл кылганнарын сөйли. Җәбраил галәйһиссәлам шул вакытта янында булучы фәрештәләргә: «Аның сүзләренә шаһит булыгыз», – дип әйтә. Ни өчен дигәндә, чөнки Раббыбыз: «Лут галәйһиссәлам үз халкына каршы дүрт тапкыр шаһитлык китермичә,

халкын газап кылмагыз», – дип әйткән була. Моннан соң Лут галәйһиссәлам тагын өч тапкыр халкына каршы сөйләп, шаһитлек китерә. Һәм шушы дүрт шаһитлыгы белән халкына Аллаһы Тәгаләнең газабы тиешле була.

Лут галәйһиссәлам берәүгә дә күрсәтмичә, мосафирларны өенә алып килә. Өендә иман нурыннан мәхрүм булган хатыны бу хәлне күреп, халкына җиткерер өчен, өйдән чыгып китә һәм бозык халкына барып: «Лут өендә йөзләре нур белән балкып торган ярь-яшь егетләрне сездән яшереп тота», – ди. Күп тә үтми, Лут галәйһиссәламнең акылдан язган халкы пәйгамбәр галәйһиссәламнең өе тирәсендә җыелып: «Әй, Лут, безнең янга чык, мосафирларыңны безгә тапшыр», – ди. Лут галәйһиссәлам халкын нәсыйхәтләү нияте белән түбәндәге сүзләрне әйтә:

هَٰؤُلَاءِ بَنَاتِي هُنَّ أَطْهَرُ لَكُمْ ۖ فَاتَّقُوا اللَّهَ وَلَا تُخْزُونِ فِي ضَيْفِي ۖ أَلَيْسَ مِنكُمْ رَجُلٌ رَّشِيدٌ ﴿٧٨﴾

**«Менә минем [өммәтемнең хатыннары; бер пәйгамбәр үз өммәтенең атасы урынында булганлыктан, болар минем] кызларым, алар сезнең өчен тагын да пакь. Аллаһыдан куркыгыз да, мосафирларым каршында мине хур итмәгез. Арагызда дөрес фикерле бер генә кеше дә юкмыни?»**

«Һуд», 11:78

Тәфсир галимнәренең әйтүенчә, Лут галәйһиссәламнең «минем кызларым» дигән сүзләре аның үз кызлары хакында түгел, ә аның халкыннан булган хатын-кызлар турында бара, чөнки һәрбер пәйгамбәр үзенең халкында әти кеше урынына, ә өммәтенең хатын-кызлары аның кызлары урынына кабул ителә. Кяфер булган халкы аңа җавап буларак болай ди:

لَقَدْ عَلِمْتَ مَا لَنَا فِي بَنَاتِكَ مِنْ حَقٍّ وَإِنَّكَ لَتَعْلَمُ مَا نُرِيدُ ﴿٧٩﴾

**«Син безнең өчен кызларыңа бернинди [кызыксыну юклыгын, өйләнүгә] хаҗәтебез булмаганны беләсең бит. Син безнең ни теләгәнебезне дә беләсең».**

«Һуд», 11:79

Бу сүзләргә каршы әйтерлеге калмаган Лут галәйһиссәлам:

لَوْ أَنَّ لِي بِكُمْ قُوَّةً أَوْ آوِي إِلَىٰ رُكْنٍ شَدِيدٍ ﴿٨٠﴾

**«Минем сезгә каршы көчем булса иде яки мин көчле бер таянычка сыена алсам иде»,** – ди.

«Һуд», 11:80

Бу сүзләрне ишеткән фәрештәләр бозык халык пәйгамбәрләрен артык җәфаламасыннар дип, Лут галәйһиссәламгә үзләренең кем икәнлекләрен белдерәләр һәм аңа халкын калдырып чыгып китәргә кушалар.

Лут галәйһиссәлам юлга кузгалганнан соң, аның халкы йортына кереп тула. Җәбраил галәйһиссәлам аларның йөзенә канатлары белән суккannan соң, шушы бозык кешеләр сукырая. Һәм барысы да беррәттән: «Лут галәйһиссәлам бөек бер сихерче, безгә сихер кылды, аңа иярмәгез, качыгыз», – дип кычкырыша башлый.

Җәбраил галәйһиссәлам Лут галәйһиссәламгә чыгып китәргә кушканда әлеге әмерләрне бирә: аңа һәм иман китерүчеләргә төнлә китергә куша, бирегә Аллаһының газабы киләчәген әйтә. Шулай ук: «Халкыгызның сезгә зыяны булмасын өчен, чыгып киткәндә иман китерүчеләр артларына борылып карамасыннар», – ди. Җәбраил галәйһиссәлам бу халык гомер буе шушы җирлектә яшәгәнлектән, сагынып туган җирләрен, якыннарын искә төшермәсеннәр, аларны жәлләп, йөрәкләрендә бу гөнаһларга карата мәрхәмәт хисләре тумасын, Аллаһының әмеренә бер гыйсъян килмәсен, дип шулай әйтә.

Аллаһының шушы кавемгә җибәргән газабы хакында Коръәндә:

فَلَمَّا جَاءَ أَمْرُنَا جَعَلْنَا عَالِيَهَا سَافِلَهَا وَأَمْطَرْنَا عَلَيْهَا حِجَارَةً مِّن سِجِّيلٍ مَّنضُودٍ ﴿٨٢﴾ مُّسَوَّمَةً عِندَ رَبِّكَ ۖ وَمَا هِيَ مِنَ الظَّالِمِينَ بِبَعِيدٍ ﴿٨٣﴾

**«Безнең [Лут [галәйһиссәлам] кавеменең һәлак ителүе хакындагы газап] әмеребез килгәч, [алар яшәгән җиде шәһәрне Җәбраилнең канаты белән астын өскә китереп] өстен аска әйләндердек һәм аларга бер-бер артлы каткан балчыктан ташлар яудырдык. Раббың хозурында [булган яшерен урыннарда ак-кызыл билгеләр, галәмәтләр һәм атылачак кешенең исеме белән] тамгаланган [ташларны яудырдык]. Алар – [ширек кушкан] залимнәрдән [бер-кайчан да] ерак түгел. [Залимнәр башларына таш явуга лаеклы]»,** – диелә.

«Һуд», 11:82-83

Фикерле белгән кешеләр өчен тарих гыйбрәт белән тулыдыр. Пәйгамбәрләрнең кыйссалары да безнең өчен хикмәт һәм гыйбрәттер. Күрүебезчә, бүгенге көндә Аурупада һәм Америкада актив рәвештә таралып килә торган гөнаһ Лут галәйһиссәмнең кавемендә чагылды. Аның халкы белән ни булганын, Аллаһы Тәгалә аларга нинди газап биргәнен онытмаска кирәк.

Аурупада һәм Америкада шушы гөнаһ рәсми рәвештә рөхсәт ителгән. Ирләр белән ирләр, хатын-кызлар белән хатын-кызлар бергә яши. Шушы хәл балалар бакчасыннан башлап, мәктәптә дә өйрәтелә. Әгәр әти-әниләр балаларына бу хәлләрнең дөрес түгеллеген аңлатып, тәрбия бирә башласа, аларның балаларын гаиләдән тартып алып, балалар йортларына, хәтта «ике әтиле», «ике әниле» башка «гаилә»гә тапшыралар. Хакыйкатьтә, бу бөек бер бәла. Шушы бәла безгә дә ирешмәсен дип, бүген сезнең белән Лут галәйһиссәлам кыйссасын искә төшереп үттек. Бу кыйссаны балаларыбызга, гаиләбезгә җиткерүебез һәрберебезнең бурычы булып тора.

Вәгазебезнең башында әйтеп киткәнчә, без Аурупадан артта калмадык, без үзебезнең пакь, күркәм, нурлы булган динебездән артта калдык. Безнең өстебезгә шундый бәлалар килмәсен өчен, без Коръәндәге һәм риваятьләрдәге кыйссалар белән вәгазьләнергә тиеш. Безгә кадәр килгән өммәтләрнең хатасын эшләмик, алардан гыйбрәт алыйк. Аллаһы сакласын, Раббыбызның газабы һәрберебезгә килергә мөмкин.

Раббыбыз безне Үзенең рәхмәтеннән калдырмасын, безне харам гамәлләр кылудан тыйсын, Үзенең Фирдәвес җәннәтләренә ирешергә насыйп вә мәяссәр әйләсен. Вәлхәмдү лилләәһи раббил гааләмин.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Тимур хәзрәт Камаев,*

*«Ирек» мәчетенең имам-хатыйбы*

*2 нче июнь вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 13 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Байлык та сынау, фәкыйрьлек тә…

Барча мактаулар һәм сәналәр безне юктан бар кылып, безләрне нигъмәтләндереп торучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Һәм дә Аның хак Расүле, безгә тугры юлны өйрәтеп калдырган, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелләребезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде!

Көчле һәм көчсез, сәламәт һәм авыру, акыллы һәм ахмак, бай һәм ярлылар арасында аерманың булуы җәмгыятьтә төзеклек һәм тәртип сакларга ярдәм итә. Байлык һәм ярлылык та бер-берсенә капма-каршы булган ике икътисади баскыч булып тора. Хакыйкатьтә, кеше тормышына сынау максатыннан бирелгән байлык һәм ярлылык халәтендә тирән хикмәт бар. Мәсәлән, байлык – мактану, ә ярлылык кимсенү өчен сәбәп түгел. Бу сыйфатлар кешенең ихтыяры һәм эш-гамәлләре белән бәйләнгән. Кешенең бай яки ярлы булуы аның тәкъдирендә, Аллаһы Тәгаләнең хикмәте белән, ул туганчы үк билгеләп куелган.

أَهُمْ يَقْسِمُونَ رَحْمَةَ رَبِّكَ نَحْنُ قَسَمْنَا بَيْنَهُم مَّعِيشَتَهُمْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَرَفَعْنَا بَعْضَهُمْ فَوْقَ بَعْضٍ دَرَجَاتٍ لِّيَتَّخِذَ بَعْضُهُم بَعْضًا سُخْرِيًّا وَرَحْمَتُ رَبِّكَ خَيْرٌ مِّمَّا يَجْمَعُونَ ﴿٣٢﴾

**«Раббыңның рәхмәтен әллә алар бүләләрме? Дөнья тормышында ризыкларын араларында Без бүлгәләдек һәм берәүләре икенчеләрен хезмәтче итеп алсыннар дип, Без аларның кайберләрен [байлык ягыннан] кайберләреннән дәрәҗәләрдә күтәрдек. Раббыңның [пәйгамбәрлек, һидаять, иман һәм җәннәт кебек]**

**рәхмәте исә аларның җыйган нәрсәләреннән яхшырак»,** – ди Аллаһы Тәгалә Коръәндә.

«Әз-Зухруф / Зиннәтләнү», 43:32

Бу аятьтә әйтелгәнчә, ризыкны Аллаһы Тәгалә кешеләргә төрле дәрәҗәдә бирә. Шуңа күрә һәр кешенең җаваплылыгы аңа бирелгән нигъмәтләр өлеше нисбәтендә. Менә шундый камил рәвештә иҗтимагый тигезлек һәм илаһи гаделлек билгеләнә.

Иң мөһиме: матди яктан хәлле кешегә зәкят түләү бурычы йөкләнә. Гарәп теленнән, зәкят – «чистарыну», чисталык» дигәнне аңлата. Ягъни, зәкят – ул милекне чистарта торган гамәл. Бирелергә тиешле булган зәкятне бирмәү – башкаларның малын алуга тиң. Аллаһы зәкят итеп бирелергә тиешле мөлкәтнең һәр төрендә билгеле бер өлеш куйды. Шуңа күрә билгеләнгән дәрәҗәдән (нисабтан) артып киткән мөлкәттән зәкят түләве таләп ителә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَاللَّهُ فَضَّلَ بَعْضَكُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ فِي الرِّزْقِ ۚ فَمَا الَّذِينَ فُضِّلُوا بِرَادِّي رِزْقِهِمْ عَلَىٰ مَا مَلَكَتْ أَيْمَانُهُمْ فَهُمْ فِيهِ سَوَاءٌ ۚ أَفَبِنِعْمَةِ اللَّهِ يَجْحَدُونَ ﴿٧١﴾

**«Аллаһы ризык аша берәүләрегезне икенчеләрегездән өстен кылды [бай һәм фәкыйрь итте]. Өстен булган [бай һәм җитәкче урыннардагы] ул кешеләр, [кул астындагылар] үзләренә тигез булмасыннар дип, уң куллары ия булган [коллар һәм эшчеләр урынындагы] кешеләргә ризыкларын бирмиләр. Әллә алар Аллаһының [үзләренә бирелгән моның кадәр] нигъмәтен инкяр итәләрме?»**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:71

Аллаһы Тәгалә бер генә кешене дә башкаларга тиңдәш итеп куймаган, барысына да тигез итеп ризык та бирмәгән. Киресенчә, Ул берәүләргә өстенлек биргән һәм аларга төрле дәрәҗәләр билгеләгән. Кешеләрне матди яктан тигезләү дөнья тәртибен бозуга китерер иде.

Моннан тыш, Аллаһы кешеләрне физик һәм акыл сәләтләре ягыннан төрлечә итеп яратты. Шулай ук, шәхси сәләтләре сәбәпле бай була алган кешеләр бар. Барысы да кешенең үзенә насыйп булган өлешенә ни рәвешле мөгамәлә итүенә бәйле булачак – ул байлыгы белән юмартлык күрсәтерме яки ярлы булса, сабыр булырмы. Фәкыйрьлек тә бозыклык түгел һәм байлык та гөнаһ түгел, әмма бөтен эш, чын мәгънәсендә, нияте белән бәяләнә.

Бүгенге көн кешесе байлыкка омтылып, үзендәге барлык кешелек сыйфатларын югалта бара. Гадилеген генә түгел, мөлкәт җыям дип, намусын да сата, золымлык кылып, үзенә тиеш булмаганын көчсезләрдән тартып та ала. Гади халыкны алдалап, соңгы тиеннәренә хәтле «суырып» алучылар аз түгел. Аларның баеган саен нәфесләре котыра, чөнки кыйммәтле тормышка бер ияләшкәч, аннан аерыласылары килми. Шуңа да андыйлар акча эшләү ысулының ниндие дә кулай дип уйлый. Иң мөһиме: акча гына килеп торсын, башка кешеләрне рәнҗетәләрме, авыр хәлдә калдыралармы, балалары ачмы-тукмы – анда һич эшләре юк. Байлыктан башны югалтмыйча кеше булып кала алу бик зур түземлек сорый. Моны, кызганыч, барыбыз да булдыра алмый.

Риваятьләрдә килгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вакытында Сәгъләбә исемле бер кеше яшәгән. Бу кеше акча ярата иде һәм бик бай булырга теләде. Шуңа күрә ул Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән Аллаһыга бу хакта дога кылуын сорады. Ләкин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны кисәтеп: «Синең өчен кечкенә байлык зур байлыкка караганда яхшырак», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу сүзләреннән соң Сәгъләбә үз фикерен үзгәртте, ләкин тиздән аның теләге яңадан көч алды һәм ул кабат Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп, дога кылуын үтенде.

Аңа Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин сиңа үрнәк буларак җитмимме? Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, әгәр теләсәм, бу таулар алтын-көмешкә әйләнеп, миңа иярерләр иде, ләкин мин тыелам», – диде.

Бу юлы Сәгъләбә үз фикерен үзгәртте, ләкин күңелендәге теләкләрен җиңә алмыйча: «Әгәр мин бай булсам, ярлыларга булышырмын, тагын да күбрәк изгелек кылырмын!» – дип уйлап, өченче тапкыр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына китте. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп җитеп: «Сине чын хәбәрче итеп җибәрүче белән ант итәм, бай булсам, мин ярлылар турында кайгыртып, һәркемгә тиешлесен бирермен!» – диде.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу юлы аның үтенечен тыңлады һәм дога кылып, Аллаһы Тәгаләгә: «Әй, Аллаһым, Сәгъләбәгә дөньяда теләгәнен бир!» – дип мөрәҗәгать итте.

Озакламый Аллаһы Тәгалә Сәгъләбәгә зур байлык җибәрде. Аның көтүләре барлык тауларны, үзәннәрне тутырды. Ләкин элек «мәчет кошы» кушаматы булган Сәгъләбә бөтен намазларны җәмәгать белән укыса, хәзер җәмәгать намазларына килүдән туктады, бары тик җомга көннәрендә генә күренә башлады. Аннары җомга намазларын да калдыра башлады.

Көннәрдән бер көнне Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сәгъләбә турында сорады, аңа: «Сәгъләбә юкка чыкты!» – дип җавап бирделәр.

Сәгъләбәнең ваемсызлыгы моның белән генә чикләнмәде. Зәкят җыючылар аның янына килгәч, ул ачуы белән: «Хакыйкатьтә, бу салым түләү!» – диде, үзенең вәгъдәләрен генә түгел, ә мөлкәтендә булган мохтаҗларның өлешен дә онытты. Шуңа күрә ул Коръән аятьләрендә ачылган икейөзлеләрнең берсе булды. Коръәндә бу хакта болай диелә:

وَمِنْهُم مَّنْ عَاهَدَ اللَّهَ لَئِنْ آتَانَا مِن فَضْلِهِ لَنَصَّدَّقَنَّ وَلَنَكُونَنَّ مِنَ الصَّالِحِينَ ﴿٧٥﴾ فَلَمَّا آتَاهُم مِّن فَضْلِهِ بَخِلُوا بِهِ وَتَوَلَّوا وَّهُم مُّعْرِضُونَ ﴿٧٦﴾ فَأَعْقَبَهُمْ نِفَاقًا فِي قُلُوبِهِمْ إِلَىٰ يَوْمِ يَلْقَوْنَهُ بِمَا أَخْلَفُوا اللَّهَ مَا وَعَدُوهُ وَبِمَا كَانُوا يَكْذِبُونَ ﴿٧٧﴾

**«Алар арасында: «Әгәр Аллаһы Үзенең фазылыннан безгә [күп мал] бирсә, әлбәттә, садака [вә зәкят] бирербез һәм, һичшиксез, [туганлык җепләрен саклап, хаҗга барып һәм Аллаһы юлында ярдәм итеп] игелек ияләреннән булачакбыз», – дип Аллаһыга вәгъдә бирүчеләр бар. Ләкин Ул аларга Үз фазылыннан [байлык] биргәч, алар [сүзләрендә тормыйча] саранландылар [һәм Аллаһының хакын бирмәделәр], [Аллаһының әмерен] кире каккан хәлдә йөз чөерделәр. Ниһаять, Аллаһыга биргән вәгъдәләрендә тормаганнары һәм ялган сөйләгәннәре өчен, Ул [аларның үлеп] Үзе белән очрашачак көнгә кадәр [кылган бу саранлыкларының авыр нәтиҗәсе итеп] аларның күңелләренә [начар ышану һәм яшерен көферлектән гыйбарәт] икейөзлелек салды».**

«Әт-Тәүбә», 9:75-77

Вакытлы дөнья байлыгы белән алданган Сәгъләбә мәңгелек дөньяда хәерче булып калды. Үлем мизгеле килеп җиткәндә, ул үкенү хисе белән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Син Аллаһыга шөкер итә алырлык кечкенә байлык, син Аллаһыга шөкер итә алмаган зур байлыкка караганда яхшырак», – дигән сүзләрен искә төшерде.[1] Сәгъләбә ахырга кадәр үзенең бәхетсезлеккә төшүен бәхет дип санады. Ул мәңгелек бәхетне байлыкка һәм вакытлыча дөнья тормышындагы уңышка алыштырды.

Сәгъләбә кыйссасы безне Аллаһының ризалыгына каршы килмәүгә генә түгел, ә Аңа дога белән ни рәвешле мөрәҗәгать итәргә кирәклеген дә өйрәтә. Кеше Раббысыннан алырга теләгән әйбернең аның өчен яхшымы-юкмы булуы хакында күбрәк сорарга, яхшы булуына инанганнан соң гына догасында нык торырга тиеш. Югыйсә, сораган әйберендә мәшәкатьләр һәм бәла-казалар куркынычы булуы бар.

Шуны да белергә кирәк: Аллаһыга мөрәҗәгать ителгән һәр дога, бәхетсезлекләрне ерагайта ала. Ләкин дога кылганда акылга артык таянырга

[1] Табари, Җәмигъ Әл-Бәйан, XIV, 370-372.

ярамый. Дога – Раббыбызга таяну ысулы ул. Әгәр дә без бөтен акылыбызны һәм хисләребезне догада куллансак, сораганнарыбызның хәерле булуына тулысынча ышанып булмый. Шуңа күрә: «Ий Раббым! Бу эш яки әйбер минем өчен хәерле булса, моны башкарырга яки шуңа ирешергә ярдәм ит!» – дип сорау хәерле.

Югарыда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, милек файдалы, ә иң мөһиме рөхсәт ителгән хәлгә китерелсен өчен, аны Аллаһы кушканча кулланырга кирәк. Бу кешенең дөнья һәм иң мөһиме – Ахирәт тормышы иминлеге өчен кирәк.

Аллаһы Тәгалә безгә мал-мөлкәтебездә ярлыларның өлеше булуы, мохтаҗлар һәм ихтыяҗларын яшерүчеләр барлыгы хакында оныттырмаса иде. Безгә мал белән бәйле булган гыйбадәтләрне тиешле рәвештә үтәп, Аллаһының ризалыгын алырга насыйп булса иде!

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Әхмәт хәзрәт Фәйзуллин,*

*«Иман Нуры» мәчетенең икенче имамы*

*9 нчы июнь вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Мөселманнарның олы кимчелекләре

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын. Мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Ислам диненең асылы – әдәп-әхлак. Әхлагы күркәм булган мөселман кешесе башкалар алдында үзенең матур мөгамәләсе белән хөрмәт хисләре генә уята. Башкача булган очракта ул башка кешеләрне дә үзеннән читкә этәрә. Кызганычка, мөселман кешесе әдәпсез, әхлаксыз булса, Ислам динендә булмаган кешеләрнең динебез хакында яхшы булмаган фикерләр туурына сәбәпче була. Әйе, мөселман кешесе һәрьяклап камил була алмый. Әмма динебез пакь, камил, кимчелексез. Һәркем шуны аңласа иде. Шулай да, мөэмин-мөселман кешесенә Ислам диненең бер олуг вәкиле булып яшәү бәхете насыйп булган икән, ул үзенең әйләнә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәте белән Ислам диненең күркәмлеген, сафлыгын күрсәтә алырга тиеш.

Галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хакыйкатьтә, мин холыкларны күркәм итәр өчен җибәрелдем», – дип әйткән. Бу сүзләр безнең өчен зур әһәмияткә ия булырга тиеш, чөнки Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм күркәм холыклы кешене мөэминнәрнең хәерлесе дип атаган. Бу сүзләргә дәлил булып, әлеге хәдис тора. Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Берьюлы мин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында булганда аның янына әнсарлардан булган бер кеше килде һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне сәламләп: «Йә, Расүлуллаһ, мөэминнәрнең иң хәерлесе

кем?» – дип сорады. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Холкы күркәм булганы», – дип әйтте.

Сүз дә юк, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әхлак үрнәге, кимчелекләрдән пакь булган гаҗәеп кеше иде. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакында:

وَإِنَّكَ لَعَلَىٰ خُلُقٍ عَظِيمٍ ﴿٤﴾

**«Һәм син, һичшиксез, югары әхлак иясе»,** – дип әйтә.

«Әл-Каләм», 68:4

Үзе югары әхлак иясе булган Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә холкыбызны күркәм итү, әдәп-әхлаклы булуның мөһимлеген гел әйтеп торган. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Дөреслектә, аш серкәсе балны бозган кебек, начар сыйфатлар да гамәлләрне боза», – дигән хәдисендә безгә уйланыр өчен җирлек бар.

Кызганычка, булган хата-кимчелекләребез безнең гамәлләрне бер дә бизәми. Бүген киң таралган гайбәт сөйләү, сүз йөртү, бер-берләреннән көнләшү сәбәпле кешеләр арасында үзара аңлашылмаучанлык, хәтта күралмау хисләре барлыкка килүен күзәтәбез. Бу гамәлләр мөселманнар арасында да киң таралган булуы аеруча да күңелне төшерә. Әдәп-әхлак булмаганга күрә, бер-берләребезне хөрмәт итү, олыларны олы, кечеләрне кече итеп карый алмау очраклары да күп. Бу да олы бер кимчелектер.

Олы кимчелекләребезнең берсе – бер-берләребез хакында яхшы фикердә булырга теләмәү, бераз хатабыз булса, аны олы итеп күрү, «күпертү», кардәшебез хакында начар уйда булу. Бу гамәлнең гаеп эш булуы хакында Коръәндә болай диелгән:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اجْتَنِبُوا كَثِيرًا مِّنَ الظَّنِّ إِنَّ بَعْضَ الظَّنِّ إِثْمٌ ۖ وَلَا تَجَسَّسُوا وَلَا يَغْتَب بَّعْضُكُم بَعْضًا ۚ

**«Ий иман китерүчеләр! Фаразларның бик күбеннән сак булыгыз, чөнки, һичшиксез, кайбер фаразлар – гөнаһ. Янә [бер-берегездән] гаеп эзләмәгез, берәүләрегез икенчеләрегезнең гайбәтен сатмасын».**

«Әл-Хуҗҗурат / Бүлмәләр», 49:12

Моннан тыш, холкы начар булучы кешенең үзенә күп авырлык китерүен исәпкә алырга кирәк. Әбү Һөрайрадан тапшырылган хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сә сәлләм: «Холкы начар булучы кеше үз-үзен газапка тарткан», – дип әйткән. Ничек була икән соң бу, диярбез. Уйлап карыйк әле. Әйтик, холкы начар булучы кеше кемгә дә булса ачуланып йөреп, борчуга төшә, күңел тынычлыгын югалта. Шул сәбәпле саулыгына зыян сала. Юкка гына бәхетнең күңел тынычлыгы дигән мөһим төшенчәдә булуын әйтмиләр. Холкы күркәм булган кеше Расүлебезнең: «Иң көчле кеше – ачуы чыкканда үзен тыя белүче кеше ул» , – дигән хәдисен истә тотып, башкаларны гафу итә, тормыштагы төрле хәлләрне зурга җибәрмичә үткәрә белә. Мондый кешеләр аз, әмма алар зур ихтирамга һәм соклануга лаек.

Динебездә һәрнәрсәгә җавап бар. Беркайчан да күңелебезне төшермик. Олылар, белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп, дип әйтә торган иде. Бу очракта кимчелекләребез булу гаеп түгел, ә аларны күрергә теләмәү, танымау – гаеп, диярга кирәк. Кешенең үз гаебен таный, күрә алуы, аларны төзәтергә теләве, алар өчен борчылуы бик мөһим адым булып тора. Динебез Исламга мөрәҗәгать итсәк, Коръән уку, һәрдаим Аллаһыны искә алу, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватлар әйтү һәм күркәм әхлаклы кешеләр белән аралашу безгә бу эштә ярдәм итәчәк. Һәм, әлбәттә, Раббыбызның Расүле өйрәткән күркәм доганы истән чыгармыйк. Ул дога

болай яңгырый: «Аллааһүммә әнтә хәссәнтә халькый фәхәссин хулүкый».

Мәгънәсе: «Йә Аллаһы! Сурәтемне күркәм кылган кебек, холкымны да күркәм әйлә».

Йә, Раббым, һәрберебезне дә Үзеңнең Пәйгамбәрең салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәерле холкы белән холыкландырсаң, әдәп-әхлак бирсәң иде. Бу дөньяда хакыйкый мөэмин-мөселманнар булып, киләчәктә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергәләшеп, мәҗлестәш булып, җәннәтләреңдә күрешүләребезне насыйп ит.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*«Хозур» редакциясе*

*16 нчы июнь вәгазе,*

*зөлкагъдә аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Кеше ни әйтер?

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи раббил-гааләмиин, вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн, әмма бәгъде. Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Аллаһы Тәгаләнең сәламе, рәхмәте, олуг бәрәкәте ирешсен, насыйп вә мәяссәр әйләсен. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә якыныйган бәндәләр арасында булсак иде.

Аллаһы Тәгалә кодси хәдисендә мондый хәбәр бирә: «Берәү Миңа якын, тугры булган, Миңа адым-адым белән килүче, даими рәвештә якынайган бәндәмә начарлык кылса, аңа дошманлык күрсәтсә, Мин ул бәндәмне ялгызын гына калдырмам, аны саклармын, ул бәндәмә ярдәм итәрмен һәм дошманнардан коткарырмын», – диелә.

Аллаһы Тәгаләнең дусты кем соң ул, дигән сорауга Раббыбыз Үзе җавап кайтара. «Аллаһы Тәгалә яраткан һәм Ул кушкан гамәлләрне үтәп, даими рәвештә нәфел гамәлләре, изгелекләре белән Аллаһы Тәгаләгә якынайгач, Аллаһы Тәгалә ул бәндәне яратыр, якын итәр. Һәм әгәр Аллаһы Тәгалә аны яратса, Ул әлеге бәндәсен болай гына калдырмас. Аллаһы Тәгалә: «Мин ул кешенең күрә торган күзләре, ишетә торган колаклары булырмын», – ди. Һәм ул кеше Аллаһы Тәгаләдән башканы күрмәс, Аллаһы Тәгаләдән башканы ишетмәс».

Шушы хәдистә үк болай дип әйтелә: «Әгәр әлеге кеше ни дә булса сайлаган вакытта кеше ни әйтер яки Аллаһы Тәгалә ни әйтер дигән сорауга Раббыбыз өчен хакыйкый дус булып, Аны якын күреп, Аллаһы Тәгаләне сайласа, ул вакытта бу бәндәгә Аллаһы Тәгалә зур дәрәҗә бирер. Һәм Раббыбыз: «Әгәр ул бәндә Миннән сораса, Мин, һичшиксез, аның догасын, изге теләген

кабул итәрмен. Әгәр берәр нәрсәдә ярдәм сораса, Миннән ярдәм көтеп, Миңа ялварса, аны ярдәмсез калдырмам», – дип вәгъдә бирә.

Кеше күп очракта башкалар ни әйтер икән дип яши. Күбесенә аның кылган гамәле хакында башка кешенең фикере нинди булу мөһим. Бер баланы балалар бакчасына илткәндә аңа яңа аяк киеме алып биргәннәр. Әнисе аңа аяк киемен кияргә куша. Бу бала куанып, бүлмәдә күпме олы кеше бар, шуларның барысына да яңа аяк киемен күрсәтеп: «Күрдегезме, миңа яңа аяк киеме алдылар, матур булганмы?» – дип, һәрберсен йөреп чыга. Барысы да: «Сөбеханәллаһ, бик матур булган икән», – дип үз фикерләрен белдергәч, мактагач кына, шатланып аяк киемен киеп куя.

Кечкенә бала – ул олы кешенең эчкерсез, саф халәте. Олы кеше алдарга, оялырга мөмкин, ә бала күңелендә нәрсә бар, шуны белдерә. Мөселман кешесе буларак, безгә кешенең фикере түгел, ә «шушы мәсьәлә, шушы эш буенча Аллаһы Тәгалә ни әйтер икән, Ул бу халәтебезне сөярме икән, яки, киресенчә, яратмасмы», дип уйлавыбыз мөһим. Билгеле бер җиргә баруыбыз савап булып язылырмы яки гөнаһлы гамәлдән китәрме, дип уйласак иде.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу дөньядан китеп, Раббыбыз хозурына күчкәч, сәхабәләр берәр гамәл кылыра теләсә, үз-үзләреннән: «Ә хәзер Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән булып, янәшәбездә булса, бу гамәлдән риза булыр идеме, аны хуплар идеме?» – дип сорый торган булган. Һәм бу сорауларына уңай җавап бирсәләр, шул гамәлне үтәгәндә үзләрен Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән янәшә итеп хис итәләр иде. Мәсәлән, «Бисмилләһи» сүзләрен әйтеп, берәр ризыкны ашарга утыргач, Аллаһының Расүле бу ризыкны ашар идеме, әллә юкмы, дип уйлыйлар иде.

Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе хәлифә булган, хәлифәт бай, зур дәүләт булып саналган вакытта аңа татлы ширбәт китергәннәр. Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе бер йотым ясады да, елый башлады. Калган сәхабәләр, ярдәмчеләр

ни булганын аңлый алмыйча, аптырап калды. Моның сәбәбе: Әбү Бәкер радыяллаһу ганһенең бу ширбәтне эчкәндә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне искә алуы иде. Көннәрдән-бер көнне ул Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә утырган вакытта Аллаһының расүле кулы белән нәрсәнедер эткән кебек ишарә ясады, ләкин аның янында берәү дә юк иде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Йә, Расүлуллаһ, ни булды?» – дип соралгач, ул: «Минем яныма үз ләззәтләре, матур бизәкләре, вәсвәсәләре белән дөнья килде, «Ал, мин синеке», дип әйтте, әмма мин ваз кичтем һәм: «Миңа дөнья кирәкми, Ахирәт кирәк дип әйттем», – диде. Моны искә төшереп, Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе тагы да катырак елап җибәрде. Ул: «Миңа ширбәт китерделәр, мин Ахирәтне сайламадым бит, дөньяны сайладым. Беренче йотымын ясауга ук, карале, ничек тәмле бит, дигән фикер барлыкка килде, дөньяның ләззәтенә бирелеп, аннан соң гына әлхәмдүлилләһ, дип сөенеп, Пәйгамбәребезне искә алдым», – ди.

Кайвакыт без кеше фикерен өстен куйгач, аларның мактавын алгач, бу кешенең данына, безгә карата яхшы мөнәсәбәтенә ия була алабыз. Шул рәвешле бу дөньяның рәхәтен татый алабыз. Әмма Аллаһы Тәгалә нәрсә әйтер икән, бу гамәлне хуплармы икән дип күзалласак, ике дөньяда да бәхетле була алырбыз.

Шундый бер очрак булган: мәдрәсәдә укыган бер кыз хәзрәт янына килгән һәм: «Хәзрәт, өченче курска кадәр яулыксыз йөрдем, җәй көне намаз укый башладым һәм уку елы башыннан яулык бәйләдем. Шунда дус кызларым мине кире какты, минем белән аралашырга теләмәде. Алай гына да түгел, бер татар укытучысы: «Син нәрсә, картайдыңмы әллә, яулыгыңны лаеклы ялга чыккач бәйләрсең», – дип, мине яулыгымны салырга үгетли башлады. Мин өемә елап кайтып һәм: «Йә, Раббым, иманымны куәтлә. Шушы вәсвәсәләргә, шайтани фикерләргә карата иманым пәрдә булсын! Йә, Раббым, көч-куәт бир», – дип сорый идем», – дигән.

Ә бер көнне бу мөселман кызына бик каты бәйләнә торган бу татар апасы чәченә химия ясатып, озаграк тоту сәбәпле, чәчләренә зыян килгән. Һәм, күз алдына китерәсезме, әлеге укытучы икенче көнне эшкә яулыктан килгән. Барысы да кичә генә мөселман кызына «яулыгыңны сал» дип торган дәрәҗәле укытучының яулыктан килүенә гаҗәп калганнар. Бу кыз: «Нәкъ менә шул мизгелдән миңа берсе дә сүз тидермәде, ә бу апаның күңеле йомшарды, хәтта ул догалар өйрәнә башлады, яныма килеп, миннән гафу үтенде», – ди.

Бу Аллаһының рәхмәте булып тора. Әгәр без Аллаһы Тәгалә ни әйтер икән дип, Ул кушканны сайласак, Аны өстен куйсак, иншәАллаһ, Аллаһы Тәгалә безгә ике дөнья бәхетен насыйп итәр. Хакыйкатьтә, мондый мисаллар бихисап. Шуңа берәр гамәл эшләр алдыннан Аллаһы Тәгалә хакында уйлыйк, Аның сүзен өстен куйыйк.

Кодси хәдистә Раббыбыз: «Әгәр Миңа бер адым ясасагыз, Мин сезгә йөгереп барырмын», – дип әйткән. Аллаһы Тәгалә барыбызга да Үзенә изгелекләребез белән баручылардан итсә иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулыксәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Солтан хәзрәт Морадимов,*

*«Рамазан» мәчетенең имам-хатыйбы*

*23 нче июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Зөлхиҗҗә ае фазыйләтләре

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез, барча мактауларыбыз ирешсен. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез булсын.

Раббыбыз яраткан колларын, изге гамәлләрен арттыра алсын өчен, үзенчәлекле көннәр белән бүләкли. Зөлхиҗҗә аеның ун көне дә үзенчәлекле көннәр булып тора. Пәйгамбәребез, изге гамәлләргә өндәп, әлеге көннәрнең бу дөньядагы иң хәерле көннәр булуын әйткән. Аллаһы бу ун көн белән ант иткән, димәк, бу көннәр бик олуг. Югарыда искә алынганнар, Ахирәт тормышыбызны тиешле дәрәҗәдә каршы алып, изге гамәлләр туплау өчен, тырышлык күрсәтүгә чакыра.

Бу көннәрне ни рәвешле каршы алырга соң? Беренчесе – ихластан тәүбә кылу. Мөэмин кеше ихластан тәүбә кылырга һәм Аллаһы Тәгаләгә кайтуына ныклап ниятләр кылырга тиеш. Тәүбә кылу – мөэминнең бу дөньядагы һәм Ахирәт тормышындагы котылуы ул. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَتُوبُوا إِلَى اللَّهِ جَمِيعًا أَيُّهَ الْمُؤْمِنُونَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ

**«Ий мөэминнәр! Барчагыз бергә Аллаһыга тәүбә итегез! Бәлки, сез [ике җиһан бәхетенә ия булып] уңышка ирешерсез».**

«Ән-Нур», 24:31

Икенчесе – бу көннәрне заяга үткәрмәү. Мөселман кешесе бу көннәрне изге гамәлләр һәм сүзләр белән бизәргә омтыла. Берәр кеше шулай ниятләсә, аңа Аллаһы Тәгалә ярдәм итәр һәм изге гамәлләр юлын җиңеләйтер. Аллаһы Тәгалә Үзенә карата ихласлы булганнарга карата вәгъдәсендә тора:

وَالَّذِينَ جَاهَدُوا فِينَا لَنَهْدِيَنَّهُمْ سُبُلَنَا ۚ

**«Безнең өчен тырышлык күрсәткән кешеләрне без [җәннәткә илтәчәк] юлларыбызга һидаять итәчәкбез»,** – дип әйтә.

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:69

Өченчесе – гөнаһлардан ерагаерга тырышу. Гыйбадәт кылу – Раббыбызга якынайта, ә гөнаһлар Аннан ерагайта, Рәхмәтеннән мәхрүм итә. Әгәр гөнаһларыбызның гафу ителүен һәм җәһәннәмнән котылуыбызны телибез икән, зөлхиҗҗә аенда һәм калган вакытта да гөнаһлар кылудан ерак булыйк. Үзенең нәрсә теләгәнен белүче кеше, максатына ирешер өчен, бар көчен кулланачак.

Зөлхиҗҗә аеның фазыйләтләре:

1. Аллаһы Тәгалә бу көннәр белән ант итте. Әгәр Раббыбыз нәрсә белән дә булса ант итә икән, әлеге нәрсәләр олуг була, чөнки Раббыбыз бары тик бөек нәрсәләр белән генә ант итә. Раббыбыз:

وَالْفَجْرِ ﴿١﴾ وَلَيَالٍ عَشْرٍ ﴿٢﴾

**«[Иртән агарып килгән] Таң белән ант итәмен! [Зөлхиҗҗәнең башындагы] Ун төн белән дә [ант итәмен]!»,** – дип әйтә.

«Әл-Фәҗр / Таң», 89:1-2

Ун төн – зөлхиҗҗә аеның ун көне ул. Коръәни Кәримне тәфсир кылучы галимнәрнең күбесе шундый фикердә. Моның хаклыгын үзенең тәфсирендә Ибне Кәсир дә раслый.

2. Бу көннәр Аллаһыны зикер итү өчен билгеләнгән. Раббыбыз:

وَيَذْكُرُوا اسْمَ اللَّهِ فِي أَيَّامٍ مَّعْلُومَاتٍ

**«...билгеле көннәрдә Аллаһының исемен искә алсыннар»,** – ди.

«Әл-Хаҗ», 22:28

Галимнәрнең күбесе (алар арасында Ибне Гомәр һәм Ибне Габбас радыяллаһу ганһүмә дә бар) «билгеле көннәрнең» зөлхиҗҗә аеның ун көне булуы хакында әйткән.

3. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әлеге көннәрнең бу дөньяда иң хәерле көннәр булуына шаһитлык китергән. Җәбир радыяллаһу ганһедән тапшырыла, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бу дөньядагы иң хәерле көннәр – ул зөлхиҗҗә аеның ун көне». Аннан: «Бу көннәрдә гыйбадәт кылучыларга тиңнәр бармы?» – дип сораганнар. Ул: «Аллаһы юлында мәрхүм булучыдан, ягъни шәһит булып китүчедән тыш, Аллаһы юлында булучылар арасында аларга тиңнәр юк», – дип әйткән.[1]

4. Бу көннәр арасында Гарәфә көне дә бар. Гарәфә көне – олы хаҗның иң бөек көне ул. Ул – гөнаһлардан, ут газабыннан котылу көне. Зөлхиҗҗә аеның ун көне олуг булып саналсын өчен, Гарәфә көне генә дә җитәр иде.

5. Бу көннәрдә корбан чалына. Галимнәр әйтүенчә, корбан чалу көне – Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенең иң хәерле көне. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы алдында иң хәерле көн – ул корбан чалу көне «Йәүм Нәхер» һәм аннан соң килгән «Йәүм әл-Карр» көне»[2]. «Йәүм әл-Карр» – бу Кәгъбәтуллаһны тәваф кылганнан һәм корбан чалганнан соң, хаҗиларның Мина үзәнлегендә тукталган көннәре ул.

6. Бу көннәрдә гыйбадәтнең иң мөһим төрләре башкарыла. Әл-Хафиз бине Хәҗәр «Әл-Фәтх» китабында болай дип язган: «Зөлхиҗҗә аеның аерылып торуының сәбәбе: иң әһәмиятле гыйбадәтләрнең: намаз, ураза, садака, хаҗның бергә җыелуында. Башка көннәрдә мондый хәлне күзәтеп булмый».

Зөлхиҗҗә ае ункөнлеге гамәлләренең фазыйләте: Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять кылына, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы өчен зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнендә

---

[1] Әл-Бәззар, Ибне Хиббән.

[2] Имам Әбү Давыд һәм имам Ән-Нәсаи тапшыра.

кылган гамәлләрдән дә сөеклерәк гамәл юк (һәм олуграк әҗер-савап юк)». Аннан: «Хәтта Аллаһы юлында тырышлык күрсәтүдән дә сөеклерәкме?» – дип сораганнар. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хәтта Аллаһы юлында тырышлык күрсәтүдән дә сөеклерәк. Үзенең гомерен һәм малын куркыныч астына куеп, моннан бернәрсәсез кайткан кешедән кала», – дип җавап кайтарган.[1]

Габдулла бине Гомәр радыяллаһу ганһедән риваять ителә: «Мин Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында идем һәм аннан гамәлләр турында сорадым. Ул: «Аллаһы Тәгалә өчен бу ун көндә кылган изге гамәлләрдән дә сөеклерәк гамәлләр юк», – дип әйтте. Сәхабәләр: «Хәтта Аллаһы юлында тырышлык куюдан да сөеклерәкме?» – дип сорадылар. Ул: «Хәтта Аллаһы юлында тырышлык куюдан да. Аллаһы юлына чыгып, гомерен биргән кешене санамаган очракта», – дип әйтте.[2]

Бу ике хәдис, калганнары кебек, әлеге айларда кылган гамәлләрнең фазыйләтен ассызыклый. Бу көннәрдә изге гамәлләр кылучының Аллаһы юлында тырышлык куеп кайтучыдан да хәерлерәк булуы аңлашыла.

Зөлхиҗҗә аеның ун көнендә мөстәхәб булган гамәлләр:

Зөлхиҗҗә аеның беренче probunкөнлеге Аллаһының рәхмәте, бүләге һәм изге гамәлләр кылу өчен мөмкинлек булып тора. Гыйбадәтләрне арттырыр өчен, булдыра алганча ныграк тырышлык күрсәтергә кирәк. Элеккеге тәкъва ияләре өч ункөнлекне бөекли торган булган: Рамазан аеның соңгы ун көнен, зөлхиҗҗә аеның беренче ун көнен һәм мөхәррам аеның беренче ун көнен.

Нәрсәгә игътибар бирергә кирәк соң?

1. Хаҗ һәм гомрә йолаларын башкаруга. Болар бу көннәрдә башкарырга мөмкин булган иң хәерле гамәлләр. Раббыбыз тарафыннан Үзенең Йортына килү һәм гомрә кылу мөмкинлеге бирелгән кешенең бүләге җәннәт булыр.

[1] Имамнар Әл-Бохари, Әбү Давыд, Әт-Тирмизи хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гомрә кылу моңа кадәр кылынган гомрәдән соң булган гөнаһларны юк итә. Ә дөрес итеп кылынган хаҗ өчен җәннәткә керү насыйп булачак», – дип әйткән.[1] Кабул кылынган хаҗ – риядан, гөнаһлардан, начар сүзләрдән, абруй казану теләгеннән ерак булып, олуг нигъмәтләр һәм әҗер-саваплар белән тулы булган хаҗ ул.

2. Ураза. Ураза – бу көннәрдәге иң хәерле гамәлләрнең берсе ул. Раббыбыз аны Үзе белән бәйләп, болай дип әйткән: «Адәм баласының барлык гамәлләре дә, ураза тотудан кала, аның үзе өчен. Уразаны ул Минем өчен тота һәм аның әҗерен Мин бирәчәкмен».[2] Пәйгамбәрбез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы ризалыгы өчен тотылган Гарәфә көне уразасын Раббыбыз үткән һәм киләсе елның гөнаһларының гафу ителүе өчен кылачак»[3].

Имам Ән-Нәвави рахимәһуллаһи үзенең китабында зөлхиҗҗә аеның ун көнендәге уразаны гаять кирәкле эш дип тәкъдим иткән һәм: «Бу көннәрдәге ураза мөстәхәб гамәл булып тора», – дигән.

3. Намаз. Намаз – иң олуг гамәл. Бу көннәрдә җәмәгать намазларын вакытында укырга тырышыгыз. Мөселман кешесе Аллаһыга якынайта торган әлеге һәм мөстәхәб булган намазларының санын арттырыр. Кодси хәдистә: «Минем колым, Мин аны ярата башлаганчыга кадәр, мөстәхәб булган гамәлләрне кылып, Миңа якынаюдан туктамый»[4], – диелгән.

4. Тәкбир, тәһлил, тәхмид сүзләрен күпләп әйтү. Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе Расүлебезнең әлеге сүзләрен риваять иткән: «Аллаһы Тәгалә өчен зөлхиҗҗә аеның ун көнендә кылган изге гамәлләрдән дә сөеклерәк гамәлләр юк. Бу көннәрдә күбрәк тәкбир, тәһлил һәм тәхмид әйтегез»[5].

[1] Имамнар Әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Имамнар Әл-Бохари, Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[3] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

[4] Әл-Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

[5] Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

Имам Әл-Бохари тапшыра: Ибне Гомәр һәм Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһүмә зөлхиҗҗә аеның ункөнлегендә «Аллаһү әкбәр» сүзләре белән базарга чыга торган булганнар һәм кешеләр дә алар артыннан кабатлаган. Бу көннәрнең барысында да Ибне Гомәр радыяллаһу ганһе Мина җирлегендә намаздан соң, йокы алдыннан, үзенең чатырында, җыелыш һәм йөреш вакытында тәкбир әйткән.

5. Садака. Бу хәерле гамәлне дә әлеге көннәрдә ешрак башкарырга кирәк. Раббыбыз садака таратуга чакыра. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Садака байлыкны киметми», – дип әйткән.[1]

Гомумән, Коръән уку, әти-әнигә яхшылык кылу, туганлык җепләрен саклау, кунакларны сыйлау, кешеләрне дуслаштыру, изге гамәлләр кылуга чакыру, начар гамәлләр кылудан тыю кебек изге гамәлләрне кылырга кирәк. Аллаһы зөлхиҗҗә аенда кылган изге гамәлләребезне кабул итсен.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Мөхәммәд хәзрәт Хөсәенов,*

*Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы имамы*

[1] Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

*28 нче июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Корбан гаете вәгазе

Галәмнәрне юктан бар итүче, Яратучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмед-сәналәребез, барча мактауларыбыз булсын. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән шытып чыккан барча салават-шәрифләребез ирешсен.

Тәннәребезне, киемнәребезне пакьләп, Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхмәтен, бәрәкәтен өмет итеп гает намазына җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Корбан бәйрәме – җир шарының барлык почмакларында зурлап билгеләп үтелә торган мөселман бәйрәме ул. Корбан – Аллаһы безгә насыйп иткән зур гыйбадәт, Раббыбыз биргән чиксез нигъмәтләр өчен рәхмәтебезне белдереп, буйсынуыбызны күрсәтү.

Раббыбыз Коръәни Кәримдә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ ﴿٢﴾

**«Шулай булгач] Раббың өчен намаз укы һәм [Аның исеме белән] корбан чал [да, корбан итләрен юксылларга тарат]»,** – дигән.

«Әл-Кәүсәр / Муллык», 108:2

Корбан – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әмер иткән әҗер-саваплы, Раббыбыздан бүләк буларак иңгән олуг гыйбадәт ул. Әлеге гыйбадәт вәҗиб (тиешле) гамәл булып санала. Бу – чиксез нигъмәтләре белән куандырган Раббыбызга шөкераналар кылып, итагать итү билгесе.

Матди яктан тиешле нисабы булган теләсә кайсы мөселман кешесе корбан чалу йоласын үтәргә тиеш. Ул – Корбан бәйрәме көннәрендә (10, 11, 12 нче зөлхиҗҗә көннәрендә) хайван чалу белән башкарыла. Белүебезчә,

аңа хәтле чалынган корбан гади ит булып саналыр.

Хөрмәтле җәмәгать, шуны белсәк иде: корбан чалуның асыл мәгънәсе – Раббыбызга итагатьлелек күрсәтү, тәкъвалыкка омтылу ул. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَـٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ ۚ كَذَٰلِكَ سَخَّرَهَا لَكُمْ لِتُكَبِّرُوا اللَّهَ عَلَىٰ مَا هَدَاكُمْ ۗ وَبَشِّرِ الْمُحْسِنِينَ ﴿٣٧﴾

**«Аларның итләре дә, каннары да Аллаһыга ирешәчәк түгел. Аңа сездән бары тәкъвалыгыгыз гына ирешә. Сезне һидаятькә ирештерде дип [«Аллаһү әкбәр» дип] Аллаһыга тәкбир әйтүегез өчен Ул аларны сезгә буйсындырды. [Расүлем!] Күркәм гамәл ияләрен сөендер»,** – дип әйтә.

«Әл-Хаҗ», 22:37

Корбан гаете мөселманнарның иң зур бәйрәме булып санала. Аның тарихы бик гыйбрәтле. Аллаһы Тәгалә ике олуг пәйгамбәребезне зур сынау белән сыный. Ибраһим галәйһиссәлам төшендә улы Исмәгыйль галәйһиссәламне корбан итүен күрә. Ибраһим галәйһиссәлам моның мәгънәсен аңлаганнан соң, никадәр генә авыр булса да, итагатьлелек күрсәтеп, бердәнбер улы Исмәгыйль галәйһиссәламне корбан итеп китерергә алып китә. Бу вакытта Аллаһының рәхмәтеннән сөрелгән шайтан Исмәгыйль галәйһиссәламгә килеп вәсвәсә кыла: «Сине әтиең үтерергә алып бара. Кач тизрәк», – ди. Сөекле әти-әнисенең һәм Раббысының сүзеннән чыгарга теләмәгән бала: «Мин Аллаһы әмеренә каршы килмим. Әтием барын да белеп эшли», – дип мәлгунне ташлар атып куып җибәрә.

Колларынының итагатьләренә күрә, Аллаһы Тәгалә Үзенең киң рәхмәте итеп, Исмәгыйль галәйһиссәламне саклап кала. Ата кешенең кулындагы пычагы үтми һәм күктән корбан итәргә дип, Аллаһы тарафыннан бәрән төшерелә.

Шул көннәрдән бирле изге бер йола итеп Корбан гаете билгеләп үтелә. Бу тарихи вакыйга барыбыз өчен дә бик мөһим һәм гыйбрәтле. Шул ук вакытта без бу кыйссадан Аллаһының киң кодрәтен күрәбез.

Корбан бәйрәме, гадәттәгечә, Мәккәгә хаҗ кылу белән туры килә. Бәйрәм ир кешеләр өчен госел алып, чиста-пакь киемнәрне киеп, мәчеткә гает намазын уку өчен бару белән башлана. Гадәт буенча, мәчеткә барганда тәкбир – «Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр, ләә иләәһә илләллааһү Аллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр вәлил-ләәһил-хәмд» – сүзләре әйтелә һәм Гает намазыннан соң корбан чалына. Аннан соң туганнарны, кардәшләрне зиярат кылу, табыннар әзерләү, бүләкләр тарату кабул ителгән.

Корбан чалу хөкемнәре һәм кешегә бу гамәл мәҗбүри булсын өчен үтәлергә тиешле шартлар бар. Байлыгы һәм мөмкинлеге булган һәрбер мөселман кешесе өчен корбан чалу вәҗиб гамәл булып санала.

Шулай ук бу эшкә тотынган кешенең акыллы, балигъ яшендә булуы, сәфәрдә булмавы шарт. Әгәр дә инде кешенең корбан чалырга мөмкинлеге булмаса, аңа гөнаһы юк. Шулай да бу изгелекле эшнең әҗере бик бөек икәнлеген онытырга ярамый, чөнки корбан чалганда хайванның беренче тамчы каны җиргә тамганчы ук, суючының гөнаһлары кичерелә.

Корбан ителәсе хайванның кимчелекләре булырга тиеш түгел. Әмма әгәр дә хайванның кайбер кимчелекләре булса, аны корбан итәргә була әле. Алар түбәндәгеләр:

- хайванның күз күреме начар булу, кылыйлык;
- бер аягы аксау, әгәр бу аксаклык хайванның йөрүенә комачау итмәсә;
- тумыштан мөгезләре яисә мөгезенең бер өлеше булмау;
- колаклары тишелгән булу;
- берничә теше булмау;
- койрыгының яки колагының зур әһәмияткә ия булмаган өлеше булмау.

Ләкин иң яхшысы хайванның бу кимчелекләрдән пакь булуы.

Ә кайбер җитдирәк кимчелекләр аркасында хайваннар корбанга чалынырга лаек түгел. Алар түбәндәгеләр:

- бер күзе яки ике күзе дә дөм сукыр булса;
- аксаклыгы берәр урынга барып җитәр өчен комачау итсә;
- бер яки ике колагы да тулысынча киселгән булса;
- күпчелек тешләре булмаса;
- бер яки ике мөгезе төптән сынган булса;
- койрыкның яртысына яки аннан да күбрәгенә зыян килгән булса;
- имчәкләре булмаса;
- бик талчыккан хәлдә яки хәлсез хайван булса;
- тумыштан колаксыз яки койрыксыз булса;
- көтүдәге калган хайваннарга кушыла алмаслык дәрәҗәдә котырынган булса;
- нәҗес (чиста булмаган ризык) белән тукланса.

Корбанга суелырга лаеклы хайваннар булып сарык, кәҗә, сыер, үгез, буйвол, дөя тора.

Ә калган хайваннарны корбанга тотарга ярамый. Югарыда әйтелгән хайваннар ата җенесеннән дә, ана җенесеннән дә булса ярый. Нигездә, сарык яисә кәҗә сую хуплана. Алар бер еллык булырга тиеш. Әгәр дә хайван ярты еллык, әмма көр һәм таза, бер еллык кебек булса, андый да ярый. Ә эре мөгезле хайваннар ике яшьлек, ә дөя биш яшьлек булырга тиеш. Эре мөгезле хайван белән дөя бер кешедән дә, җиде кешедән дә чалына ала. Ләкин бергәләп эре хайванны чалырга теләгән кешеләрнең нияте Аллаһы ризалыгы өчен генә булырга тиеш. Әгәр дә инде араларыннан берсе ит алырга теләгәннән генә чалса, берсенең дә корбаны кабул ителми.

Корбан чалу рәвешен искә төшереп китик. Башта тыныч кына итеп корбанны чалынасы урынга илтеп җиткерергә кирәк. Аннары газап кылмыйча, сул ягына яткырасы һәм башын кыйблага борып куясы. Вак мөгезле хайванның арткы уң аягыннан кала өч аягы да бәйләнә. Суясы кеше ниятен

әйтә, янәшәдәгеләр тәкбир әйтә. Шуннан «Әл-Әнгам» сүрәсенең аятьләре укыла:

قُلْ إِنَّ صَلَاتِي وَنُسُكِي وَمَحْيَايَ وَمَمَاتِي لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ﴿١٦٢﴾ لَا شَرِيكَ لَهُ ۖ وَبِذَٰلِكَ أُمِرْتُ وَأَنَا أَوَّلُ الْمُسْلِمِينَ ﴿١٦٣﴾

**[Расүлем!] Әйт: «Һичшиксез, минем намазым, [хаҗ һәм корбан кебек бөтен] гыйбадәтләрем, яшәвем һәм үлемем – барча галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы өчен. Аның һичбер тиңдәше юк. Миңа бу [ихлас] әмер ителде һәм мин – [өммәтемә карата] мөселманнарның беренчесемен».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:162-163

Моннан соң «Бисмилләәһи Аллааһү әкбәр», дип хайван чалына. Һәм дога кылына. Өстәмә рәвештә ике рәкәгать нәфел намазын укырга була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Корбан чалган кеше пычагын куйгач та, ике рәкәгать намаз укыса, Аллаһы аңа ни теләсә, шуны бирер», – дип әйткән.

Корбан, нигездә, фәкыйрь, мохтаҗ, мескен, ятим, кимчелекле кешеләргә, тол хатыннарга, сәфәрдә булучыларга өләшенә. Әгәр дә корбан чалган кешенең үз әнисе тол хатын була икән, аңа да бирелергә тиеш. Корбанлык итен ике төрле юл белән корбан әһелләренә ирештерәләр. Берәүләр кисәкләргә бүлеп, итне тарата, икенчеләр, табын ясап, мохтаҗ кешеләрне чакырып, Коръән мәҗлесе үткәрә. Икесе дә күркәм гамәл санала. Һәм ничек эшләсәң дә, дөрес була.

Итне өч өлешкә бүлү яхшы. Бер өлеше күршеләргә һәм туганнарга таратыла, икенчесе ярлыларга һәм мескеннәргә, ә өченче өлеше чалучының гаиләсенә кала.

Корбан чалу, беренчедән, Аллаһыга һәм Аның ризалыгына якынайта. Раббыбыз ул корбанга мохтаҗ түгел, тик Ул моның белән безнең Үзенә якын-

лык дәрәҗәсен тикшерә. Шулай ук корбан Исмәгыйль галәйһиссәләм кыйссасын искә төшерә. Мөселманнарның корбан чалуы аларның Аллаһы юлында малларын кызганмавын күрсәтә. Бу канун мескеннәрне һәм ятимнәрне шатландыруга китерә.

Аллаһы Тәгалә бу көндә без рухи шатлык һәм аның шәфкатьлелеген күрергә чын күңелдән намаз укырга рөхсәт бирсә иде. Аллаһы Тәгаләдән безнең корбаннарыбызны кабул итүен, үсеп килүче яшь буынның гыйлемле, әхлаклы, намуслы, җөмһүриятебез өчен файда китерә торган булуын сорыйк. Раббыбыз чалган корбаннарыбызны, бергән садакаларыбызны, ихлас күңелләребездән кылган догаларыбызны кабул итеп, ил-көннәребезгә тынычлык, иминлек, татулык насыйп әйләсә иде. Бүгенге көндә чит җирләрдә йөрүче, Ватаныбызны саклаучы ир-атларыбызга саулык, рух ныклыгы бирсә иде. Дөньяларыбызда булган төрле бәла-казаларның, хәвеф-хәтәрләрнең артлары хәерле булып, зыян күргән кешеләребезгә Раббыбыз Аллаһы күркәм сабырлыклар, иминлекләр, саулык сәламәтлекләр насыйп итсен. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безләрне рәхмәтеннән аермыйча, ике дөнья бәхете, иман ныклыгы, гаиләләр тынычлыгы, саулык, хәерле, сәгадәтле тормышлар насыйп әйләсен.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин җитәкче өчен дога кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең, телебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

# خُطْبَةُ عِيدِ الاَضْحَى

## الْخُطْبَةُ الْاُولَى

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَقَدَّسَ ذَاتُهُ عَنِ الشِّرْكِ وَالزَّوَالِ وَنَطَقَتِ الْاَدِلَّةُ بِاَوْصَافِهِ الْجَلاَلِ وَالْجَمَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَحَيَّرَ فِي كُنْهِ ذَاتِهِ الْعُقُولُ وَالْاَفْهَامُ وَعَجَزَ عَنْ اِدْرَاكِ صِفَاتِهِ الرَّاسِخُونَ الْاَعْلاَمُ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ اَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِالشُّهُورِ وَالْاَيَّامِ فِصَالِ. وَاَوْجَبَ فِي هَذِهِ الْاَيَّامِ عَلَى الْاَغْنِيَآءِ الْحَجَّ وَالطَّوَافَ بِالْبَيْتِ الْمُكَرَّمِ عِنْدَ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لآَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. نَحْمَدُ اللَّهَ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ صَاحِبَةً وَلاَ وَلَدًا وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ وَلِيٌّ مِّنَ الذُّلِّ وَكَبِّرْهُ تَكْبِيرًا وَاَشْهَدُ اَنْ لَّا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ

وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَفِيعُ الْعُصَاةِ فِي يَوْمِ الْجَزَاءِ بِاَمْرِ اللَّهِ الْكَرِيمِ الْمُتَعَالِ.

صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى وَسَلَّمَ عَلَيْهِ وَعَلَى ءَالِهِ وَاَصْحَابِهِ الْمَوْصُوفِينَ بِاَحْسَنِ الْاَخْلَاقِ وَاَطْيَبِ الْاَحْوَالِ.

يَا اَيُّهَ النَّاسُ. اِعْلَمُوا اَنَّ يَوْمَكُمْ هَذَا يَوْمٌ شَرِيفٌ وَعِيدٌ لَّطِيفٌ لِّلْخَوَاصِّ وَالْعَوَامِّ يَوْمٌ عَظِيمٌ قَدَرُهُ لِلْاَنَامِ، عَظِّمُوا هَذَا الْيَوْمَ بِالْاِنْعَامِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيْصَالِ الْاَرْحَامِ. اِنَّ اللَّهَ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا النَّحْرَ بِقَوْلِهِ وَانْحَرْ، وَاَمَرَ خَلِيلَهُ بِذَبْحِ وَلَدِهِ الْاَشْهَرِ وَاُفْدِيَ بِكَبَشٍ مِّنَ الْجَنَّةِ بِوَاسِطَةِ الْمَلَكِ الْمُقَرَّبِ وَلاَ يَجِبُ عَلَى الْفَقِيرِ عَلَى الْقَوْلِ الْمُعْتَبَرِ الْبُدْنَةُ عَنْ سَبْعَةٍ وَالضَّأْنُ وَالْمَعْزُ عَنْ وَاحِدٍ مُجْزِأَةٌ وَلاَ يَجُوزُ الْعَجْفَآءُ وَالْعَرْجَآءُ وَمَقْطُوعَةُ الْاُذُنِ وَالْاِلْيَةِ وَالَّذِي لاَ يَمْشِي عَلَى الْمَنْسَكِ عِنْدَ الْمَذْهَبِ الْمُعْتَبَرِ.

ضَحُّوا عَنْ اَطْيَبِ اَمْوَالِكُمْ وَعَظِّمُوهَا امْتِثَالاً لِّاَمْرِ رَسُولِ اللَّهِ الْمُقَرَّرِ كَمَا قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: عَظِّمُوا ضَحَايَاكُمْ فَاِنَّهَا عَلَى الصِّرَاطِ مَطَايَاكُمْ. وَاِنَّ اللَّهَ تَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا تَكْبِيرَ التَّشْرِيقِ عَقِبَ الْفَرْضِ مِنْ فَجْرِ يَوْمِ عَرَفَةَ اِلَى اخِرِ اَيَّامِ التَّشْرِيقِ بِقَوْلِهِ تَعَالَى: وَاذْكُرُوا اللَّهَ فِي اَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ. اَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ

الرَّحِيمِ: يَآ اَيُّهَ الَّذِينَ ءَامَنُوا اتَّقُوا اللّٰـهَ وَلْتَنْظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ وَاتَّقُوا اللّٰـهَ اِنَّ اللّٰـهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ.

بَارَكَ اللّٰهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرْءَانِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَاِيَّاكُمْ بِالْاٰيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ وَاَسْتَغْفِرُ اللّٰـهَ الْغَفَّارَ لِي وَلَكُمْ وَلِسَائِرِ جَمَاعَةِ الْمُسْلِمِينَ الْحَاضِرِينَ اَجْمَعِينَ اِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ.

## الْخُطْبَةُ الثَّانِيَةُ

اَلْحَمْدُ لِلّٰـهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللّٰـهِ مِنْ شُرُورِ اَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ اَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللّٰـهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ. وَاَشْهَدُ اَنْ لَا اِلَهَ اِلاَّ اللّٰـهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ.

اِنَّ اللّٰـهَ وَمَلاَئِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ. يَآ اَيُّهَا الَّذِينَ ءَامَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا.

اَللّٰـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ صَلَّى وَصَامَ.

اَللّٰـهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ قَعَدَ وَقَامَ.

صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ وَعَلَى جَمِيعِ الْاَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلَائِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى اَهْلِ طَاعَتِكَ اَجْمَعِينَ مِنْ اَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْاَرَضِينَ. وَارْحَمْنَا وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ الْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْاَمْوَاتِ اِنَّكَ اَنْتَ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ وَمُنْزِلُ الْبَرَكَاتِ وَرَافِعُ الدَّرَجَاتِ وَقَاضِيُ الْحَاجَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللَّهُمَّ ارْحَمِ الْخُلَفَاءَ الرَّاشِدِينَ وَالْاُمَرَاءَ الْمَاضِينَ الَّذِينَ قَضَوْا بِالْحَقِّ وَكَانُوا يَعْدِلُونَ.

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ وَاهْدِ مَنْ خَذَلَ الدِّينَ.

عِبَادَ اللَّهِ، اِنَّ اللَّهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ.

اُذْكُرُوا اللَّهُ الْعَلِيَّ الْعَظِيمَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ يَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوهُ يَزِدْكُمْ وَاسْتَغْفِرُوهُ يَغْفِرْ لَكُمْ وَلَذِكْرُ اللَّهِ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَعْلَى وَاَوْلَى وَاَعَزُّ وَاَجَلُّ وَاَعْظَمُ وَاَتَمُّ وَاَكْبَرُ.

## Корбан гаете хотбәсенең татарча укылышы

## Беренче хотбә

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән тәкаддәсә ҙәәтүһү ганиш-ширки вәззәүәәл. Вә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиһил-җәләәли вәлҗәмәәл.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр, вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мәң тәхәййәра фии күнһи ҙәәтиһил-гукуулү вәл-әфһәәм, вә гаҗәзә ган идрааки сыфәәтиһир-раасихуунәл-әгъләәм.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән әкрамә гыйбәәдәһүл-мүэминиинә бишшүһүүри вәл-әййәәмил-фисааль. Вә әүҗәбә фии һәәҙиһил-әййәәми галәл-әгънийәәил-хәҗҗә вәт-таүәәфә бил-бәйтил-мүкәррами гыйндәл-кәбиирил-мүтәгааль.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Нәхмәдүллааһәл-ләҙии ләм йәттәхыйҙ саахибәтәү-үә ләә вәләдә, вә ләм йәкүнләһү шәриикүң фил-мүлки, вә ләм йәкүнләһү вәлиййүн-минәҙ-ҙүлли вә кәббирһү тәкбииraa. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Вә әшһәдү әннә сәййидәнәә Мүхәммәдән габдүһүү вә расүүлүһү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәә'и би әмрилләәһил-кәриимил-мүтәгааль. Салләллааһү тәгааләә вә сәлләмә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһил-мәүсууфиинә би әхсәнил-әхъләәкый вә әтъйәбил-әхүәәл.

Йә әййүһән-нәәс! Игъләмүү әннә йәүмәкүм һәәҙәә йәүмүн шәриифүн вә гыйидүн ләтыйифүн лил-хаүәәссый вәл-гаүәәмм. Йәүмүн гаҙыймүң кадәруһү лил-әнәәм. Гаҙҙыймүү һәәҙәл йәүмә бил-ингаами вәл-ихсәәни вә иисаалил-әрхәәм. Вә иннәллааһә тәбәәракә вә тәгәәлә әүҗәбә галәйнән-

нәхра би каулиһи вәнхәр. Вә әмәра халииләһүү би ҙәбхи вәләдиһил-әшһәри вә үфдийә би кәбәшин минәл җәннәти би вәәситатил-мәләкил-мукарраб, вә ләә йәҗибү галәл-фәкыйри галәл-каулил-мүгьтәбәр. Әл-бүднәтү ган сәбгәтин вәд-да’нү вәл-мәгзү гән вәәхидин мүҗзиәтү вә ләә йәҗүүзүл-гәҗфәәә’ү вәл-гарҗәәә’ү вә мәкътуугәтүл-үҙүни вәл-илйьәти вәлләзии ләә йәмшии галәл-мәнсәки гиндәл-мәҙһәбил-мүгътәбәр.

Даххүү ган әтъйәби әмүәәликүн вә гаҙҙыймүүһәәмтиҫәәлән лиәмри расүүлилләәһил-мүкаррар. Кәмәә каалә расүүлүллааһи салләллаһү галәйһи вә сәлләм: «Гәҙҙыймүү дахәәйәәкүм фәиннәһәә гәләс-сыйраати мәтаайәәкүм». Вә иннәллааһә тәгәәләә әүҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәшриикый гәкыйбәл-фәръды мин фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһи тәгалә: «үәҙкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт». Әгүүҙү билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим: Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүт-тәкуллааһә вәлтәңзур нәфсүм-мәә каддәмәт ли-гаад. Вәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимәә тәгъмәлүн.

Бәракә Ллаһу ләнә вә ләкум фил-Куръәнил-гаҙыйм, вә нәфәганәә вә ийәкүм бил-әәйәәти вәҙ-ҙикрилхәкиими вә әстәгъфируллаһәл-гаффәәра лии вә ләкүм вә лисәә’ири җәмәәгәтил-мүслимиинәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүс-сәмиигуль-гәлиим.

## Икенче хотбә

Әлхәмдү лилләәһи нәхмәдүһү вә нәстәгинүһү вә нәстәгъфируһү вә нү’минү биһи үә нәтәүәккәлү гәләйһи вә нәгүүҙү билләәһи мин шүруури әңфүсинәә вә мин сәййиәәти әгмәәлинәә мән-йәһдиһил-Лләәһү фәләә мүдыйллә ләһү вә мән-йүдълилһү фәләә һәәдийә ләһ. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһү вә эшһәдү әннә Мүхәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһ.

Иннәллаһә вә мәләәикәтәһүү йүсаллүүнә галән-нәбий. Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә

салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән салләә вә саам. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән кагәдә вә каам.

Саллии вә сәллим гәләйһи вә гәләә җәмиигиль-әнбийәә’и вәл-мүрсәлиин. Вә галәә мәләәикәтикәл-мүкаррабиинә вә галәә әһли таагәтикә әҗмәгиин мин әһлис-сәмәәүәәти вәл-әрадыыйн. Вәрхәмнәә вәхшүрнәә мәгәһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин.

Аллаһүммә-гъфир лилмү’миниинә вәл-мү’минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәә’и минһүм вәл-әмьүәәт, иннәкә әнтә мүҗиибүд-дәгәүәәт вә мүнзилүл-бәракәәт, вә раафигуд-дәраҗәәт, вә каадыйүл-хәәҗәәт, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

Аллаһүммәр-хәмил хуләфәә’әр-раашидиинә вәл-үмәрааа’әл-мәдыйнәл-ләзиинә кадау билхәккы вә кәәнүү йәгъдилүүн. Аллаһүммән-сурмән нәсараддиинә вәһди мән хаҙәләддиин. Гибәәдәллааһ, иннәллааһә йәъ’мүрү бил-гадли вәл-ихсәәни вә ийтәәәи ҙил-курбәә вә йәнһәә ганил-фәхшәәәи вәл-мүнкәри вәл-бәгъйи йәгыйиҙукум ләгәлләкүм тәҙәккәрүүн. Үҙкүруллааһәл-галиййәл-гаҙыымәл-хәййәл-каййүүм, йәҙкүрүкүм вәш-күрүүһү йәзидкүм, вәстәгъфирууһүү йәгъфир ләкүм вә ләҙикруллааһи тәбәәракә вә тәгәәләә әгләә вә әүләә вә әгәззү вә әҗәллү вә әгҙамү вә әтәммү вә әкбәр.

## Корбан гаете хотбәсенең тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһының Заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһының матурлыгына һәм олуглыгына барлык мәхлүкълар дәлил булып тора.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Аллаһының үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле Зат булганына) акыл ияләре хәйран калды.

Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә байларга хаҗны, Олуг Аллаһы каршында изге йорт булган Кәгъбәтуллаһны тәваф кылырга йөкләгән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында тиңдәше булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһыны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһыдан башка бернинди илаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул — бердәнбер, Аның тиңдәше юк, пәйгамбәребез Мөхәммәд – Аның колы һәм расүледер. Ул (Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм) – җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм Олуг Аллаһының әмере белән шәфәгать кылучыдыр.

Аллаһы Тәгалә аңа, аның гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сәхабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.

Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез — хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә корбанны: «Корбан чал!» – дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһим галәйһиссәламгә) иң танылган баласын корбан

итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһиссәлам) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек – җиде кешедән, сарык вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.

Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз, һәм Аллаһы Расүленең әмеренә буйсынып, корбаннарыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһының Расүле (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дип әйткән: «Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дисәгез, алар – Сират күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр». Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир тәшрикъне Гарәфә көненең иртәнге намазыннан алып, Тәшрикъ көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: «Саналган көннәрдә Аллаһыны искә алыгыз», – дигән. Таш белән атылган шәйтаннан Аллаһыга сыенам. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ ۚ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ ﴿١٨﴾

**«Әй иман китергән кешеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә эшләрегездән хәбәрдар».**

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:18

Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһы каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм).

Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) — Гафу итүче, Рәхимле, Данлы, Юмартлык иясе, Ишетүче һәм Белүче.

## Икенче хотбә

Аллаһыга мактау булсын, Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһыга сыенабыз. Кемгә Аллаһы һидаять бирсә — аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса — аңа беркем дә һидаять бирә алмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд Аның колы һәм хак Расүле булуына гуаһлык бирәм.

«Шик юктыр ки: Аллаһы да, фәрештәләр дә Пәйгамбәргә күп салаватлар әйтә. Әй, иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез».

Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәр салават ирештер.

Аллаһым, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәр салават ирештер.

Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (расүлләргә), якын булган фәрештәләреңә, шулай ук күкләрдә һәм җирләрдә яшәүче Сиңа итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә Мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син – догаларны кабул итүче, бәрәкәт иңдерүче,

дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә, рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.

Аллаһым, кем дингә ярдәм итә, шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә, шуңа һидаять бир.

Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.

Бөек, Олуг, Тере, Уяу булган Аллаһыны зикер итегез – Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез – Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз – Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләне зикер итү – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәләләтле, иң камил, иң зур гамәл.

*30 нчы июнь вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 12 нче көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Исраф кылмаучы фәкыйрьләнмәс

Безләрне юктан бар кылып, Үзенең чиксез нигъмәтләрендә яшәтүче Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә чиксез мактау, шөкерләребез булсын. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават, сәламнәребез ирешсә иде. Хөрмәтле мөселман кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Кеше үзенең яшәеш дәверендә матди керемгә, малга, байлыкка мохтаҗ, чөнки Адәм баласына тормышын камил итеп алып барыр өчен, ризык, кием, торак һәм күп кенә тормыш хаҗәтләре, матди чыгымнар таләп ителә. Ислам дине матди байлыкка, акчага карата нинди мөнәсәбәттә соң? Шушы мәсьәләдә без – мөселманнар нәрсәләрне исәптә тотырга тиеш? Бүгенге вәгазебез шуның хакта булыр.

Аллаһы Үзенең гыйлеме һәм хикмәте белән бәндәләре арасында байлык һәм дәрәҗәне бүлеп биргән. Әйе, мөселман кардәшләрем, байлык – ул Аллаһыдан, моның хакта күп кенә Коръән аятьләрендә әйтелә:

إِنَّ رَبَّكَ يَبْسُطُ الرِّزْقَ لِمَن يَشَاءُ وَيَقْدِرُ ۚ إِنَّهُ كَانَ بِعِبَادِهِ خَبِيرًا بَصِيرًا ﴿٣٠﴾

**«Һичшиксез, синең Раббың теләгән кешегә [кайчак] ризыкны мул итәр һәм тарайтыр. Һичшиксез, Ул – колларыннан хәбәрдар һәм күрүче».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:30

Аллаһы Тәгалә кешеләргә малларының, байлыкларының күләмен билгеләгән һәм шул байлыкка ирешү юлларын да күрсәткән. Әмма шуны да онытмыйк: бу дөньяда сәбәп кылу кирәк, Ислам дине безне кәсеп итәргә чакыра. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Дөньяда

мәңге яшим дип кәсеп ит, дөнья эшләреңне алып бар, иртәгәсен үләм дип Ахирәтеңне кайгырт, гамәл-гыйбадәтеңне кыл», – дигән.

Шул ук вакытта тапкан малга сакчыл карарга, аны исраф итүдән сакланырга да кирәк, чөнки байлыкны Аллаһы Тәгалә биргән икән, бу – әманәт, аның өчен Кыямәт көнендә җавап та тотасы булачак. Бер хәдистә: «Кыямәт көнендә, дүрт нәрсә турында җавап тотканчы, бәндәнең бер аягы икенчесеннән узмас», – дип әйтелә. Шуларның икесе: байлыгыңны нинди юллар белән таптың һәм шул байлыгыңны нинди юлларга сарыф иттең, дип соралачак икән. Коръәни Кәримдә:

كُلُوا وَاشْرَبُوا وَلَا تُسْرِفُوا ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ ﴿٣١﴾

**«Ашагыз, эчегез, әмма [хәләлне харам итеп, яки харамга катышып, яки туклык чиген узып] исраф итмәгез. Һичшиксез, Ул [Раббыгыз] исрафчы кешеләрне сөйми»,** – дип әйтелгән.

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:31

Аллаһының Расүле Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә: «Ашагыз, эчегез, садака бирегез, киенегез, ләкин исрафтан һәм тәкәбберлектән сакланыгыз»[1], – дигән.

Әйе, мөселман кардәшләрем, бу аять һәм хәдисләр безне акчаны, байлыгыбызны кулланганда чамадан чыкмыйча, сакчыллык күрсәтеп кулланырга чакыра. Безгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән килеп ирешкән: «Исраф кылмаучы фәкыйрьләнмәс», – дигән хәдис нинди яхшы киңәш! Шул ук вакытта исрафтан сакланыйм, малымны сакчыл тотыйм әле дип, саранлыкка кереп китүдән дә сакланырга кирәк, чөнки мал, байлык мәсьәләсендә гаиләбезнең дә, күршеләребезнең дә, мескен-фәкыйрьләрнең дә хаклары бар. Ислам дине дөнья куып малга, байлыкка ирешүне төп максат итеп куймый, әмма шушы мал белән Аллаһы

[1] Имамнар Әл-Бохари, Әхмәд, Әбү Давыд.

Тәгаләнең ризалыгын алу, шул байлык белән изгелекләр эшләүне максат итеп куя. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَلَا تَجْعَلْ يَدَكَ مَغْلُولَةً إِلَىٰ عُنُقِكَ وَلَا تَبْسُطْهَا كُلَّ الْبَسْطِ فَتَقْعُدَ مَلُومًا مَّحْسُورًا ﴿٢٩﴾

**«[Чамасыз саранлык аркасында] Кулыңны муеныңа бәйләгән [кебек каты] итмә, [кулыңа кергән бернәрсәне таратып] аны бар киңлегенә дә җәймә, юкса соңыннан [Аллаһы хозурында – исрафта, кешеләр алдында дуамаллыкта гаепләнеп] кимсетелгән һәм үкенечле бер хәлдә калырсың».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:29

Бу аять безне садака биргәндә уртача булырга чакыра, саранлык күрсәтеп садака бирмәү яки әз бирү дә, шулай ук барлык малыңны садака итеп таратып, үзеңне авыр хәлдә калдыру да ярамый. Һәркем садакасын үзенең матди хәленә карап бирергә тиеш. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Садака ул иманга дәлил», – дип әйткән. Шулай ук садака малга бәрәкәт китерә, икенче бер хәдистә: «Садака биреп мал кимемәс», – дип әйтелә.

Ислам диненең биш нигезен искә төшерсәк, шуның икесе: зәкят түләү һәм хаҗ кылу өчен матди байлык булу таләп ителә. Ягъни әгәр кешенең акчасы, байлыгы булмаса, ул шушы фарызларны үти алмаячак.

Гаиләләрен матди яктан тәэмин итүче буларак, Аллаһы Тәгалә ирләрне хатыннарыннан өстен кылды. Аллаһы Тәгалә Коръәндә:

الرِّجَالُ قَوَّامُونَ عَلَى النِّسَاءِ بِمَا فَضَّلَ اللَّهُ بَعْضَهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ وَبِمَا أَنفَقُوا مِنْ أَمْوَالِهِمْ ۚ

**«Аллаһының [тирән акыл, оста җитәкчелек, көч, ныклык кебек сыйфатлар белән] берәүләрне икенчеләрдән өстен кылганы өчен**

**һәм малларыннан сарыф иткәннәре сәбәпле, ирләр [гаилә эчендә әмер бирү һәм тыюлар мәсьәләсендә] хатыннардан өстен торалар»,** – дип әйтелгән.

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:34

Гаиләсен матди яктан тәэмин итүне Аллаһы Тәгалә ирләр өстенә йөкләгән. Гаилә кору да, балалар тәрбияләү дә күп чыгымнар таләп итә. Хәдисләрдә: «Гаиләгә тотылган мал – сарыф ителгән иң хәерле мал була», – дип әйтелә.

Аллаһы Тәгалә ил-көннәребезгә тынычлык, иминлек насыйп итсен, тормышларыбызга муллык, куаныч, кәсепләребезгә бәрәкәт бирсен, безне түбән хәлгә төшерә торган фәкыйрьлектән һәм тәкәбберлеккә илтә торган байлыктан сакласын.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Илһам хәзрәт Мохтаров,*
*Кукмара мәдрәсәсе мөгаллиме,*
*Кукмара районы Аш-Бужи авылы,*
*имам ярдәмчесе*

*7 нче июль вәгазе,*

*зөлхиҗҗә аеның 19 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1444 ел*

# Милли тәрбиянең мөһимлеге

Галәмнәрнең Тәрбиячесе булган Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез булсын, җир йөзенә рәхмәт өчен җибәрелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде. Әссәләмү галәйкүм, хөрмәтле мөселман кардәшләрем!

Ислам галимнәре халык яшәсен өчен, дүрт әйбер кирәк дип тапкан. Әгәр шуларны сакламасак, халык яшәүдән туктый, юкка чыга, дигән.

Халыкны саклар өчен, иң беренче динне сакларга кирәк.

Безнең халык бик тырыш. Йортлар төзибез, булдырабыз, әмма кем өчен соң?! Бер кеше: «Йорт зур булгач, хатын белән бер-беребезне кесә телефоны аша шылтыратып табабыз», – ди. Бу йортларны нәрсә дип төзедек? Зур йорт салыр өчен урладык, ялганладык, намаз укымадык, ураза тотмадык, әмма кем өчен төзелде ул? Шуңа да иң беренче дин булырга тиеш. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дин кануннары буенча яшәгән кешене кояшка карап барган кеше кебек, дип әйткән. Кояшка карап барсак, күләгә артыбыздан бара, беркая китми. Кеше тормышын Аллаһы кушканча көйли икән, дөнья да беркая китми, чөнки ана карынында 4 айда, 10 көн булганда барысы да язылган инде. Шул язганны хәләл юл белән дә, харам юл белән дә табып була. Мәсьәлә шунда гына. Ә инде динне ташлап дөнья кусак, кояшка арканы куеп барган кебек булабыз. Кояшка арканы куеп барсак, күләгәбез алдан бара, аны куып җитеп булмый.

Локман Хәким: «Кеше – көймә, акча – су», – дип әйткән. Көймә сусыз йөзә алмаган кебек, акчасы да кирәк. Әмма шул су көймә эченә керсә, ни булыр? Әлбәттә, көймә батар. Сүз дә юк, эшләргә, кәсеп итәргә кирәк,

әмма акча күңелдә түгел, ә кесәдә булырга тиеш. Әгәр кешенең күңелен дөнья тулысынча биләп алган икән, аның укыганы өч тиенгә дә тормый.

Диннән башка нәфесне җиңеп булмый. Нәфесне җиңә торган бердәнбер корал – ул дин. Нәфесне рәткә китермичә, без дә тәртипкә килә алмыйбыз.

Шиһабетдин Мәрҗани: «Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый: ул милли тел, милли кием, милли гореф-гадәт», – дип әйткән. Бүгенге көндә кайберәүләр моны инкяр итә, тел нәрсәгә ул, диләр. Ана телен югалткан кеше Төркиягә барса, кайсы телдә сөйләшә? Әйе, кайсы милләт кешесе булуга карамастан, төрекчә сөйләшә. Гарәбстанга барса да шулай ук. Ә бездә кеше телен югалтса, кайсы телдә сөйләшәчәк? Аның ничә проценты мөселман булачак?

Милли кием мәсьәләсе дә шулай ук. Рус милләте арасында яшәгәч, әбиләребез яулыгын да үзенчә бәйләгән, бабайларыбыз түбәтәйдән йөргән. Элек татар әбисен, бабасын урамда очраткач, аның татар милләтеннән булуын аңлап булган, кызганычка, хәзер алай түгел. Бер язучы кеше дә бу хакта язган иде: элек Казан урамы буйлап татар карчыгы барса, ул икенче бер татар карчыгын танып алып, исәнләшеп, сөйләшә башларлар иде. Татар карты да үз милләт кешесен танып алыр иде. Бүген яшьләр арасында да бер-берсен күрү, танышу өчен бу мәсьәләдә аерма юк, шуңа да катнаш никахлар да күп. Кызганычка, милләтебезнең 40%тан артыгы катнаш никахта. Бүген ашауда да, киемдә дә, гадәттә дә аерма юк. Бу да безнең фаҗигабез, болар динне, милләтне алга җибәрә торган гамәлләр түгел.

Милли гореф. Бүген кайбер яшьләр: «Зиратка барып Коръән укымагыз, 3, 7, 40 ын үткәрмәгез», – дип әйтә. Минем бер табынга туры килгәнем бар, болар хәмер эчеп утыра. Нишлисез, дигән соравыма: «Нурулланың 40ын искә алабыз», – диделәр. Әгәр без мәҗлес ашларын тыеп, аны үткәрмәсәк, халык аны шул рәвешле үзләренчә үткәрә башлый. Безнең

балалар да барысын да телевизордан күреп үсә бит. Әгәр без аларны: «Зиратта Коръән укымагыз», – дип үстерсәк, бала зиратка баргач, башка җирдә күргәнен эшли: йә чыбыкка-чыбык бәйләп, бастырып куя, йә ризык, йә ясалма чәчәк куеп китә. Ә без аны, Коръән укы, дип өйрәтсәк, ул зиратта берничә аять укыр иде. Каш ясыйк дип, күз чыгармыйк. Шушы нечкәлекләрне исәптә тотып, хикмәт белән эш итик.

Динне саклый торган икенче әйбер – ул җан.

Бүген без җанны саклыйбызмы? Никах укыганда барыбыз да Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Никахланыгыз, күбәегез, Кыямәт көнендә башка өммәтләр каршында өммәтемнең күплеге белән горурланырмын», – дигән хәдисен сөйлибез. Күз алдына китерегез, Россиядә көн саен 11 000 баланың җаны кыела икән. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә үтерелгән кешеләрне үтерүчеләр янына китерер һәм терүчеләрдән: «Ник үтердең?» – дип соралгач, алар: «Ул миңа янады, мине куркытты», – кебек сүзләр белән җавап бирер. Шул вакытта дөньяга туарга тиеш булып та, тумый калган сабыйлар китерелер һәм Аллаһы Тәгалә: «Боларның гаебе нинди иде?» – дип сорар икән. Бу сорауларга күп кешенең җавап тотасы бар бит.

Кызганычка, кешенең күңелендә Аллаһы Тәгаләгә карата мәхәббәт булмаса, ул корыган агач кебек була. Ул агач көн үткән саен череп юка чыга бара. Безнең дә күңелләрдә Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт булмаса, әти-әнине түгел, хәтта баланы да ярата алмыйбыз. Баланы мәшәкать дип күрәбез, безнең эшләребезгә, үсешебезгә комачаулый, дип уйлыйбыз. Ничек кенә яшәсәк тә, бу дөньяны калдырып китәсе була, ул байлыкны кемгә дип җыйган булабыз соң?!

Хатын-кызларны күлмәкләре матур булган өчен генә гүзәл затлар дип йөртмиләр. Дөньяда иң матуры – ул яшь бала. Бишектәге сабыйны яратып туеп булмый. Шушы матурлыкны кем дөньяга китерә?! Нәкъ менә хатын-кыз шул гүзәл сабыйны дөньяга китергәнгә күрә, алар гүзәл зат

дип йөртелә дә инде. Әмма, кызганычка, бүген гүзәл затларыбыз шушы матурлыкны дөньяга тудыру белән шөгыльләнми.

Җанны саклау дигәндә, беренчесе, бала алып кайту булса, икенчесе, харам ризыктан тыелырга кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Бер сум харамнан тыелу, мең сум садака бирүдән хәерлерәк», – дигән. Харам ризык кешенең калебен каралта, ихтыяр көчен бетерә. Баланың хәләл ризыкны «Бисмилләһи» сүзләре әйтеп, уң кул белән ашавы кирәк. Әйе, бала сул кул белән эш эшләргә дә, язарга да мөмкин, әмма ашарга уң кулы белән генә тиеш.

Дин булсын, алга барсын өчен, өммәт һәм тынычлык кирәк. Бүгенге көндә динне алга җибәрәбез дип, әллә нинди хикмәтле китаплар, программалар әзерләнә, әмма аны укытырга кешесе юк. Телевизордан авылның бер имамын күрсәтәләр, аннан сорау алалар, менә мәчеткә йөрүче балалар саны кимегән, диләр. Әмма, җәмәгать, авылда балалар бакчалары, мәктәпләр ябыла, чөнки йөрергә, укырга балалар юк. Мәктәпкә йөрергә балалар булмагач, ничек мәчеткә йөрүче бала булсын инде?! Хатын-кызлар бәби алып кайтмагач, мәчеткә йөрүче балалар саны кими инде, билгеле. Балалар бакчалары, мәктәпләр ябыла дип, хөкүмәтне сүгәбез. Әмма авылда 50-60 бала булса, ул балалар бакчалары, мәктәпләр ябылмас иде. Шуңа да милләт булсын өчен, динне, җанны сакларга кирәк. Әгәр уйлап карасак, харам ашау да, җан кыелу да, катнаш никах та динсезлек бәласе ул.

Өченчесе, нәселне сакларга кирәк.

Без үзебезнең нәсел шәҗәрәсен, аның казанышларын, күренекле шәхесләрен белергә, балаларыбызны да үз нәселе белән горурланырга өйрәтергә тиешбез. Нәселең белән горурланыр өчен тарихыңны өйрәнергә, милләтеңнең үткәнен белергә, үзеңнең милли каһарманнарыңны белергә кирәк.

Милли хәзинәбезне саклап йөртүче, милләт аналары буласы кызларыбызның юкка чыгуы – ягъни башка кавемне тәрбияләве –

бүгенге чорыбызның иң зур фаҗигасе. Дөрес нәтиҗә ясыйк, алга таба бу фаҗигале юлдан баруыбызны туктатыйк. Туган телебездә фикерлик, татарча сөйләшик, үзебезчә сөйләшә торган балалар үстереп калдырыйк. Шулай булганда гына милләтебезнең киләчәге өметле булыр.

Кайсы гына милләт вәкиленнән: «Нәселеңдә иң беренче кеше кем булган?» – дип сорасак, ул Адәм галәйһиссәламне атар. Гарәпчә язылыштагы «адәм» сүзенең беренче хәрефе – намазда басып торучы, икенче хәрефе – рөкүгъта торучы, өченче хәрефе сәҗдә кылучы булып күренә. Бу хәрәкәтләр – намазда, димәк, без – намаз укучылар нәселеннән.

Нәселне кайгырту, саклау дигән сүз – матди яктан тәэмин итү генә түгел ул. Намаз укучылар нәселеннән булгач, үзебездән соң намаз укучылар калдыру да. Уңны сулдан аера башлагач, баланы намазга өйрәтә башлау лязем (тиешле). Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Балаларыгызга җиде яшьтән үк намазга басарга боерыгыз, 10 яшьтә әлеге боерыгыгызны үтәмәсәләр, аларны җәзага тартыгыз һәм 10 яшьтә намаз өйрәнмәсә, тәрбия камчысы өстен булсын»,1 – дигән.

Дүртенчесе, малны саклау.

Малны таба да, саклый да белергә тиешбез. Бүген без, кызганычка, балаларыбызны һөнәр, хезмәт сөя торган итеп үстермибез. Барысына да укып, эшләмичә генә акча ала торган урын эзлибез. Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне җәннәттән җиргә төшергәч, иң беренче итеп, игенчелек һөнәрен өйрәтә, чөнки өстәмә продукция бирә торган бердәнбер әйбер – ул җир. Иң яхшы заводка бер килограмм тимер керсә, ничә килограмм кадак чыга? Бер килограммнан да азрак кадак чыга, әмма җиргә ярты бәрәңге салсаң, иң начар уңдырышлы елны да ике-өч бәрәңге үсеп чыга. Шуңа да гомер буе кеше җир дип тырышкан. Бүген безнең илдә җирнең кадере бармы? Кызганычка, юк! Без әнине дә, җирне дә кадерләргә өйрәтмибез.

[1] Имам Әбү Давыдның хәдисләр җыентыгыннан.

Коръәни Кәримдә:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ فِي كَبَدٍ ﴿٤﴾

**«Һичшиксез, Без кешене михнәт эчендә яраттык»,** – диелгән.

«Әл-Бәләд / Шәһәр», 90:4

Без бүгенге көндә балаларыбызны эшләтмичә, уңайлы шартларда яшәтергә тырышабыз, аларны шәһәргә куабыз, без күргәнне күрмәсеннәр, михнәт чикмәсеннәр дибез. Әгәр тимерне утка тыгып, суга салып чыныктырмасаң, аннан эш коралы ясап булмый. Без дә бүген балаларыбызны тормышка әзерләмибез, намазга, уразага уятырга да, эш эшләтергә дә жәллибез. Без малны таба да, тота да белергә тиеш.

Кыздан: «Нигә бу егеткә чыгасың?» – дип сорасаң: «Мин аны яратам, аның белән бәхетле булырмын кебек», – дип әйтә. Егет кеше дә шулай ук. Өйләнешәләр, ә бәхет юк. Әмма дөрес җавап мондый булырга тиеш: «Мин аны яратам һәм бәхетле итә алырмын, дип уйлыйм». Без «бәхетле булам», дип өйләнәбез, әмма без, «бәхетле итәм», дип өйләнергә тиеш. Ярату – үзең турында оныту инде ул. Яраткан кешеңне бәхетле итү – үзе бәхет. Әти-әни баласы бәхетле булса, үзе дә бәхетле, чөнки ул баласын ярата. Хатын-кыз яратып чыккан икән, ирен бәхетле итәргә тырышырга тиеш, ир-ат та шулай ук. Яшьләр өйләнешә дә, ир – хатыннан, хатын ирдән бәхет эзли, әмма берсе дә икенчесен бәхетле итәм дип тырышмый. Димәк, нигез дөрес түгел. Нәселне, гаиләне саклау дигәндә, балаларыбызны боларга төшендереп үстерү кирәк.

Никахка кадәр сайлаган парыңның нәселен тикшерергә, аның турында дусларыннан, хезмәттәшләреннән сораштырырга да була, әмма өйләнгәнсең икән, күзеңне йомарга кирәк, чөнки Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хатын-кыз кәкре кабырга, син аны турайта алмассың», – дигән. Яшь парлар өйләнешкәч, бер-берсенең кимчелекләрен күрә башлый. Берәүләр шуны төзәтмәкче була һәм тавыш чыга, гаилә тар-

кала. Икенчеләре сабыр итә дә, Аллаһы Тәгалә алар арасына шушы сабырлык өчен мәхәббәт сала. Димәк, Аллаһы Тәгалә мәхәббәтне шул сабырлык күрсәткәнебез өчен сала икән. Ә егет белән кыз арасында нәфес теләү ул, әле бу мәхәббәт түгел.

Коръәндә Аллаһы Тәгалә:

لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً ۚ

**«...арагызда сөю белән бер шәфкать бирүе дә – Аның билгеләреннән»,** – дип әйтә.

«Әр-Рум / Румлылар», 30:21

Шуңа да элек егетнең әти-әниләре нәселенә карап кызны сайлаган, егет белән кыз никах укытканнар да, матур итеп торып киткәннәр, гаилә таркалмаган.

Димәк, нәсел дәвам итсен, нигезебез нык, балаларыбыз тәрбияле булсын, халык буларак югалмыйк дисәк, менә шушы дүрт әйбергә игътибар итәргә кирәк: динне саклауга – йортыбызда дин булырга тиеш; җанны саклауга – бала җаны кыелмаска, харам кермәскә тиеш; нәселне саклауга – бала нәселен белеп, горурланып үсәргә тиеш; малны саклауга – балаларыбыз һөнәрле булып үсәргә тиеш, чөнки һөнәрле кеше беркайда да югалмый.

Хуҗаәхмәт Ясәвигә әүлиялык килгәч, өенә кайта да, атасының бакчада чүп утаганын күрә. Һәм, әтине кызык итим әле, дип уйлап, качып кына дога кыла. Аллаһы Тәгалә аңа кәрамәт биргән була, бөтен чүпләр ызанга чыгып тезелә. Әмма атасы бакча уртасына утырып, дога кыла да, бөтен чүпләр яңадан бакчага кереп утыра. Шуннан соң улына: «Улым, без бу дөньяга мәшәкать чигәр өчен килгән. Син мине мәшәкатьтән коткарам, дисеңме? Менә бу чүп урынына икенче мәшәкать килеп чыгачак. Шуңа да башка мәшәкать чыкканчы, бакчамдагы чүбемне утыйм», – ди.

Мәшәкать – ул табигый хәл, аннан башка тормыш итеп, тормышның ямен, тәмен тоеп булмый.

Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга хәерле гомерләр, саулык-сәламәтлекләр бирсә иде. Раббыбыз кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә, балаларыбызның, оныкларыбызның кайгы-хәсрәтен күрмичә, Раббыбызның җәннәтләрендә очрашырга насыйп булса иде.

***

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән.

Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә президентыбыз – Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Җәлил хәзрәт Фазлыев,*
*Балтач районы имам-мөхтәсибе,*
*ТР баш казые*

# «Нәрсә? Кайда? Кайчан?»

# ГЫЙНВАР-МАРТ

## Җиддәдә 2023 елда хаҗны оештыру буенча карарлар игълан ителде

Гыйнвар башында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Татарстандагы «ДУМ РТ Хадж» рәсми хаҗ операторы директоры Ранис хәзрәт Вахитов Россия хаҗ миссиясе составында Согуд Гарәбстаны Хаҗ министрлыгы конференциясендә катнашты. Конференция барышында Россия һәм Согуд Гарәбстаны арасында Россия мөселманнары өчен 2023 елгы хаҗ сезонын оештыру турында килешү имзаланды. Килешүдә 2023 елда Россия мөселманнарына хаҗ кылу өчен 25 мең квота бүлеп биреләчәге билгеләнде. Шулай итеп, хаҗ кылу өчен квоталар саны пандемиягә кадәрге дәрәҗәгә кайтарылды. Шунысы игътибар лаек: Россия квоталары вакытыннан алда билгеләнгән бердәнбер ил булды. Моннан тыш, хаҗилар өчен 2021 елда дөньяда санитар-эпидемиологик вәзгыять уңаеннан кертелгән барлык яшь чикләүләре бетерелде, һәм Россиягә беренче тапкыр муассасны – Согуд Гарәбстаны Корольлегендә булганда хаҗиларга хезмәт күрсәтү компанияләрен сайлап алу хокукы бирелде. Бу хаҗилар өчен хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирә.

## «Зәкят» һәм «Ярдәм» фондлары Татарстан солдатлары ихтыяҗлары өчен машина алырга ярдәм итте

Диния Нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды һәм «Ярдәм-Помощь» гомуммилли хәйрия фонды Татарстаннан мобилизацияләнгән солдатлар ихтыяҗлары өчен автомобиль сатып алуда матди ярдәм күрсәтте. Җыелган садака хисабына, махсус хәрби операция кырларындагы шарт-

ларны истә тотып, юлсыз җирлекләрдә йөрү өчен Россиядә җитештерелгән «Нива» сатып алынды. Транспорт ачкычлары махсус хәрби операция кырларына имам булып киткән Руслан хәзрәт Әгъмәловка тапшырылды. «Зәкят» хәйрия фонды «Нива»га республика сугышчыларына төрле кирәк-яраклар – хәләл сыер итеннән 200 банка тушенка, бер тәүлеклек коры паек җыелмалары, беренче медицина ярдәме күрсәтү һәм шәхси гигиена өчен кирәк-яраклар, көнкүреш химиясе, 20 килограмм бал да төяп җибәрде.

## Россия ислам институтында уникаль басма – «Россиядә ислам тарихы» хезмәте тәкъдим ителде

Җөмәдәл-ахыр аеның 19 нчы көнендә (12 нче гыйнварда), Россия ислам институтында «Россиядә ислам тарихы» дип аталган уникаль басма тәкъдим ителде. Әлеге тема буенча бу – беренче коллектив монография, анда югары фәнни дәрәҗәдә Россия мөселман халыкларының ислам цивилизациясен үстерүгә керткән өлеше күрсәтелә. Китапта Россиядә мөселман берләшмәләренең барлыкка килүе һәм эшчәнлеге, Россия мөселман өммәтенең рухи яңарыш барышы һәм интеллектуаль үсеше анализлана, хәзерге шартларда Ислам дине күтәрелешенең төп тенденцияләре яктыртыла. Фундаменталь басма 5 бүлектән тора: «Россиядә Исламның таралуы»; «Россия мөселман өммәтенең рухи яңарышы һәм интеллектуаль үсеше проблемасы: тарихи контекст һәм заманчалык»; «Россия мөселманнарында дини оешмаларның барлыкка килүе һәм үсеше»; «Хәзерге Россиядә Ислам», «Ислам һәм рухи мәдәният».

Китап Россия ислам институтында рус, инглиз һәм гарәп телләрендә әзерләнгән. Аны язуда күпләгән чыганак һәм әдәбият файдаланылган (алар 1000-нән артык), Ислам тарихы өлкәсендә әйдәп баручы Россия белгечләре җәлеп ителгән. Татарстан авторлары арасында – Искәндәр

Измайлов, Айдар Ногманов, Айдар Хабетдинов, Радик Салихов, Илдус Заһидуллин, Илшат Зарипов, Сәид Шәһабиев, Резеда Сафиуллина-Ибраһимова һәм башкалар бар.

## Әтнә районы Яңа Шашы авылында яңа мәчет ачылды

Җөмәдәл-ахыр аеның 21 нче көнендә (14 нче гыйнварда) Әтнә районы Яңа Шашы авылында яңа мәчет ачылу тантанасы узды. Мәчет бер катлы, кирпечтән төзелгән, 70 кеше сыйдырышлы, 60 кв.метрлы зур намаз залы, гардеробы һәм тәһарәтханәсе бар. Бинага ут кертелгән һәм җылыту системасы тоташтырылган. Әлеге күркәм чараны хөрмәтләп кунаклар кайтты, районның дин һәм җәмәгать эшлеклеләре, авыл халкы җыелды.

## Дөньяда татарлар бастырган иң танылган китап – «Казан басмасы» беренче тапкыр заманча мосхаф рәвешендә чыкты

Татар өммәтенең иң зур рухи ядкәре – 1803 елда Казан типографиясендә басылган Коръәннең «Казан басмасы», хәзерге заман фәнни һәм басма стандартларга туры китереп яңартылганнан соң, компьютерда җыелган яңа шрифт белән дөнья күрде. Күптән көтеп алынган татар-мөселман Коръәнен «Хозур» нәшрияты «Казан басмасы»ның 220 еллыгы, Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы һәм Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм итү фонды белән берлектә бастырды. Югары сыйфатлы, заманча мосхаф уңайлы форматта (А5+), дизайнлы кәгазьдә, сәнгати бизәлеш белән 3 000 данәдә чыкты.

Яңартылган «Казан басмасы» мосхафы Татарстан мөфтиятенең Коръәнне бастыру өлкәсендә татар традицияләрен торгызу эшчәнлегендә

соңгы этап булды. Моның өчен 2021 елда «Казан басмасы»ның тарихи типографик оттискысыннан шул ук исемдәге уникаль компьютер шрифты эшләнде. Хәзерге компьютер символлары, Казан Коръәне шрифтының чын тарихи йөзен саклап кына калмыйча, Коръән һәм китап бастыру өчен яңа заманча техник мөмкинлекләр дә ачты. 2022 елда Нәзарәт белгечләре «Казан басмасы» дип исемләнгән татар милли компьютер шрифты белән Коръән текстын яңадан җыйды һәм, күренекле татар галимнәре Шиһабетдин Мәрҗанинең «Фәваид Әл-Мүхиммә» китабындагы һәм Муса Бигиевның «Тасхих расми хат» китабындагы искәрмәләрен исәпкә алып, заманча халыкара стандартларга туры китереп басмага әзерләде.

## Россиядә рус телендә онлайн-мәдрәсә эшли башлады

«Хозур» нәшрият йорты яңа проектны – рус телендә онлайн-мәдрәсәне эшләтеп җибәрде. Шул рәвешле, планетаның төрле почмакларында яшәүче рус телле мөселманнарның Ислам нигезләре буенча бушлай белем алу мөмкинлеге барлыкка килде. Раҗәб аеның 2 нче көнендә (24 нче гыйнварда) Нәзарәттә әлеге проект рәсми рәвештә журналистларга тәкъдим ителде.

Уникаль белем бирү мәйданчыгы Россиядә Ислам мәгарифенең беренче баскычын – мәчет каршындагы курсларны яңа дәрәҗәгә күтәрде: онлайн-мәдрәсә мәчетләрдән ерак яшәүчеләргә яки төрле сәбәпләр аркасында мәчетләргә барып җитә алмаучыларга башлангыч дини белемне тиз арада һәм җиңел генә алырга ярдәм итә. Моннан тыш, ресурсның эчтәлеге Диния нәзарәте тарафыннан Хәнәфи мәзһәбе һәм Матуриди гакыйдәсе кысаларында эшләнгән уку-укыту программасына нигезләнгән. Ресурста 7 төп ислам дисциплинасын база дәрәҗәсендә үзләштерергә тәкъдим ителә: ислам хокукы (фикһ), гакыйдә, Коръән һәм тәфсир, әхлак, гарәп теле һәм тәҗвид, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы һәм Россиядә Ислам тарихы. Курс шулай ук фарыз,

сөннәт һәм гает намазларын укырга өйрәтүче тәфсилле видеопрактикумны да үз эченә ала. Онлайн-мәдрәсәсендәге дәресләрне тәүлекнең теләсә кайсы вакытында һәм Интернет челтәренә тоташтырылган теләсә кайсы җайланмадан (компьютер, планшет, смартфон һ.б.) өйрәнергә мөмкин.

Онлайн мәдрәсә проекты 2021 елда төзелгән беренче татар онлайн-мәдрәсәсе платформасы базасында эшләнгән.

Җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителгәннән соң, бер ай эчендә әлеге белем бирү платформасында белем алу өчен 3500 «шәкерт» теркәлде.

## Гыйнварда һәм февральдә егетләр һәм кызлар өчен Мөселман яшьләре форумы кышкы мәктәбе эшләде

Казанда гыйнвар һәм февраль айларында егетләр һәм кызлар өчен Мөселман яшьләре форумы кышкы мәктәбе эшләде. Егетләр сменасы, 25 нче гыйнварда башланып, 29 нчы гыйнварга кадәр дәвам итте, ә кызлар 1-5 нче февральдә җыелды. Җыеннарда 18 яшьтән 30 яшькәчә булган мөселман егетләре һәм мөслимәләр катнашты. Форум – өммәт язмышына битараф булмаган актив мөселман яшьләрен берләштерү, аларның үсеше өчен шартлар тудыра торган иҗади мохит – быел яңа форматта «Эшлә!» шигаре белән оештырылды.

Мөселман яшьләре форумына килүчеләр Soft-skills буенча 5 көнлек тренингта катнашты, тормышның теләсә кайсы өлкәсе өчен кирәк булган конкрет белемнәрне һәм мөмкинлекләрен үстерде. План төзү алымнарын һәм планнарны үзгәртү тәртипләрен үзләштерде. Форумда катнашучылар шулай ук дини белем алды, мастер-классларда, TED һәм диспутларда, квестларда катнашты, кинозалда һәм китап клубында булды.

## Рамазан ае алдыннан Казан мәчетләрендә Коръән укырга өйрәнү курслары узды

Рамазан ае җитәргә төгәл 2 ай кала – раҗәб һәм шәгъбан айлары дәвамында Казан мәчетләрендә Коръән укырга өйрәтү курслары ачылды. Дәресләр Татарстан мөфтияте һәм КИУның Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәге тарафыннан әзерләнгән махсус программа нигезендә оештырылды. Казанның «Рәшидә», «Әниләр», «Казан нуры», «Нурислам», «Иман нуры», «Гаилә», Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллин исемендәге, «Әмәт» мәчетләрендә әзерлекле мөгаллимнәр ике ай дәвамында гарәп алфавитын һәм Коръән уку кагыйдәләрен өйрәтте.

## Нәзарәтнең Аксакаллар шурасы Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына бурычлар билгеләде

Раҗәб аеның 10 нчы көнендә (1 нче февральдә) Алексеевск эшчеләр бистәсендә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Аксакаллар шурасының республикакүләм җыелышы үтте. Утырыш 2022 елдагы эшчәнлеккә хисап ясау һәм 2023 елга эш планын билгеләүгә багышланды. 2022 елда Аксакаллар шурасы тарафыннан башкарылган эш нәтиҗәләренә уңай бәя бирелде. Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына исә аксакаллар үз алларына Хәтер көнен уздыру, мәктәп һәм балалар бакчаларында хәләл туклану мәсьәләләрен хәл итүне, югары уку йортларында татар телле белгечләр әзерләү, мөхтәсибәтләрдә эшләнгән татар-мөселман туристик маршрутларын актив эшләтү, мөселман зиратларын тәртиптә тоту кебек бурычлар куйды.

## Татарстанда «Рухи моң» бәйге-фестивале игълан ителде

Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаеннан республикада «Рухи моң» татар рухи мәдәниятне үстерү фестиваль-бәйгесе игълан ителде. Бәйгене «Рухи моң» иҗат берләшмәсе, Татарстан мөфтияте, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәсе оештыра. Мәгълүмати партнер – «Тәртип» радиосы.

Быел дүртенче тапкыр уздырыла торган бәйге татар мәкаме һәм традицион мелодика калыпларын кайтаруны, татар халкының нигез кыйммәтләрен үз эченә алган рухи җыр жанрын баетуны, татар мәкаме белән азан әйтү культурасын булдыруны, татар теленең кулланылыш даирәсен арттыруны максат итеп куя. Шулай ук күңелгә чын рухи азык бирердәй, эчтәлекле текст, милли аһәң белән баетылган үзебезнең җырларны, иман нурын тарата, әби-бабаларыбыздан мирас булып калган динне куәтли торган җыр җанрын үстерү; сәхнәдә үз-үзеңне тоту, зәвык һәм милли модалы киенү буенча да өлге булдыру; Татарстан мәчетләреннән яңгырый торган азаннарның сыйфатын үстерү, милли мәкамле азан традицияләрен торгызу; татар телендә вәгазь сөйләү сыйфатын яхшырту максатлары да бар. Конкурс 4 номинациядә үткәрелә: «Дини җыр», «Мөнәҗәт», «Милли мәкам белән азан әйтү» һәм «Вәгазь сөйләү».

## «Таян Аллаһка» әдәби бәйгесе игълан ителде

Февраль ае башында Татарстан мөфтияте Россия ислам институты һәм «Идел» журналы белән берлектә «Таян Аллаһка» бөтенроссия әдәби бәйгесен үткәрү турында хәбәр итте. Әлеге конкурс Россиядә яшәүче татарлар арасында талантларны барлау һәм берләштерү, аларның иҗади эшчәнлекләрен үстерү максатыннан уздырыла. Бәйге өч номинациядә үтә: шигърият, чәчмә әсәр һәм публицистик язма. Бәйгедә Россиядә яшәүче

10 яшьтән алып 60 яшькә кадәр иҗат эше белән профессиональ рәвештә шөгыльләнмәгән һәр кеше катнаша ала. 2010 елдан бирле үткәрелә торган «Таян Аллаһка» әдәби бәйгесен танылган татар мәгърифәтчесе, галим һәм дин эшлеклесе Вәлиулла хәзрәт Якупов башлап җибәргән иде.

## Казанда Бөтендөнья хиҗаб көне уңаеннан мөслимәләр очрашуы узды

Раҗәб аеның 13 нче көнендә (4 нче февральдә), Казанда Бөтендөнья хиҗаб көне уңаеннан тантаналы чара – танылган мөселман хатын-кызлары, хатын-кызлар оешмалары җитәкчеләре, остазлар, мөгаллимәләр һәм җәмәгать эшлеклеләре, күпбалалы һәм аз керемле әниләр очрашуы узды. Очрашуда шулай ук Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Россиядә мөселманнарның юридик хокукларын яклау өлкәсендә эш тәҗрибәсе булган танылган адвокат Руслан Нагиев катнашты. Алар хиҗаб белән бәйле мәсьәләләрне дини һәм юридик яктан аңлатып бирде. Камил хәзрәт милләтебез Ислам динендә булганга күрә сакланып калуын искәртеп, яулык бәйләүнең мода гына түгел, Раббыбызның әмере булуын искәртте. «Яулык – ул хатын-кызларыбызның таҗы. Горурланып киегез, Раббыбыз сездән разый булсын! – дип, изге теләкләрен җиткерде ул. Руслан Нагиев 2000 еллар башында массакүләм мәгълүмат чараларында, интернетта хиҗабка карата тискәре стереотип барлыкка килүен һәм хәзер шуны бетерү өчен аңлату эшләре алып барырга кирәклеген ассызыклап әйтте.

## Нәзарәт Пленумында 2022 елга нәтиҗәләр ясалды һәм Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына яңа бурычлар билгеләнде

Раҗәб аеның 18 нче көнендә (9 нче февральдә) Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Пленумы узды. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә үткән утырышта аның урынбасарла-

ры, казыйлар, шулай ук бөтен республикадан имам-мөхтәсибләр, мөфтият эшчәнлегенең барлык юнәлешләре һәм оешмалары җитәкчеләре катнашты. Анда, көн тәртибендәге төп мәсьәлә буларак, Татарстан мөфтиятенең һәм аның карамагындагы оешмаларның 2022 елдагы эшчәнлегенә нәтиҗәләр чыгарылды, 2023 елга планнар төзелде.

Камил хәзрәт, 2022 елга йомгак ясап, беренче чиратта, аның Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу белән истәлекле булуын искә төшерде һәм, ел узуга да карамастан, кайбер проектларны аның канаты астында тормышка ашыруны дәвам итү, юбилейга чит илләрдә кызыксыну зур булу турында әйтте. 1100-еллык уңаеннан мөфтиятнең иң мөһим казанышларыннан Камил хәзрәт түбәндәгеләрне билгеләп үтте: Коръәнне бастыруның татар традицияләрен тулысынча торгызу, «Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмын төшерү, мөселман инфраструктурасы киңәю (14 мәчет һәм 3 мәгърифәт үзәге, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе өчен ике яңа бина, намаз уку бүлмәләре, хәләл банк продуктлары), 2 мәгариф проекты – рус телендә онлайн-мәдрәсә һәм татар телен өйрәнү өчен эшләнгән «Без – татарлар» онлайн-платформасы һ.б. Мөфти үз чыгышында шулай ук өлешчә мобилизация кысаларында Нәзарәтнең гуманитар эшчәнлегенә тукталды, 2022 елда «Зәкят» фонды мохтаҗларга 24 млн сумлык хәйрия ярдәме күрсәтте, «Хозур» нәшрияты 80 гә якын исемдәге китап бастырды, «Хозур ТВ» 10 төбәктә күрсәтә башлады, «ДУМ РТ Хадж» операторы 810 кешегә – хаҗ һәм 1000 гә якын кешегә гомрә оештырды, республикада 15 Коръән бәйгесе үткәрелде, 10 фәнни чара һәм 10 иҗади бәйге уздырылды, студентлар арасында 2 олимпиада һәм башка чаралар оештырылды, дип хәбәр итте.

Пленум кысаларында барлык имам-мөхтәсибләр, казыйлар һәм Голәмәләр шулай ук «ТР мөселманнары Диния нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә»гә өстәмәләр кертү турында киңәште.

## Татарстан мөхтәсибәтләре Сүриядә һәм Төркиядә җир тетрәүдә зыян күрүчеләргә ярдәм итте

Татарстан мөхтәсибәтләре, Сүриядә һәм Төркиядә җир тетрәү фаҗигасе хәсрәтен бүлешеп, дин кардәшләргә ярдәм итте. Республиканың Буа, Лаеш, Чистай, Алабуга, Әлмәт мөхтәсибәтләре, шулай ук «Ярдәм» хәйрия фонды акча һәм кирәк-яраклар җыю акцияләрен оештырды. Аерым алганда, Буа мөхтәсибәте каршындагы «От сердца к сердцу» хәйрия фонды, бер атна эчендә 90 мең сумга якын акча җыеп, җир тетрәүдә яраланганнарга җибәрде. Лаеш мөхтәсибәте район халкы һәм авыл мәхәлләләре ярдәме белән барлыгы 1 237 777 сумлык гуманитар ярдәм туплады. Әлеге акчага фаҗигадә зыян күрүчеләргә беренче чиратта кирәкле әйберләр (йокы капчыклары, термослар, җылыткычлар, подгузниклар, портатив телефон зарядкалары, балалар ризыгы һ.б.) сатып алынды. Фаҗигадә зыян күрүчеләргә ярдәм итү эшенә шулай ук Чистай (Чистай районы хакимияте белән берлектә), Алабуга һәм Әлмәт мөхтәсибәтләре дә кушылды. «Ярдәм» хәйрия фонды Төркия Республикасының Казандагы консуллыгына кием-салым илтеп тапшырды.

## Татарстанда ачык телевизион татар вәгазе бәйгесе башланды

Февраль уртасында Татарстанда ачык телевизион «Вәгазь» бәйгесе игълан ителде. Конкурс Татарстан дәүләт телерадиокомпаниясе һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан уздырыла. Төп максат – татар телендә оста вәгазьчеләрне ачыклау һәм халыкка таныту, үтемле итеп сөйләү үрнәкләрен күрсәтү. Бәйгедә 15 яше тулган һәркем (нинди һөнәр иясе булуга карамастан) катнаша ала. Вәгазь татар телендә булырга, яттан сөйләнергә һәм 7 минуттан артмаска тиеш. Бәйге ике этапта уздырыла һәм йомгаклау тантанасы белән төгәлләнәчәк.

## Буада мохтаҗларны бушлай ашату ноктасы ачылды

Раҗәб аеның 27 нче көнендә (18 нче февральдә) Буада мохтаҗларны бушлай кайнар аш белән ашату пункты ачылды. Бу төбәктә аз керемлеләр өчен махсус урын булдыру идеясен шушы районнан чыккан меценат, «Ханский дом» төзелеш компаниясе җитәкчесе Ильяс Гыймадов җиткерде. Әлеге проектны Казан шәһәре эшмәкәре Азат Гайнетдинов Буа муниципаль районы башлыгы Ранис Камәртдинов, район имам-мөхтәсибе Илмир хәзрәт Хәсәнов ярдәме белән тормышка ашыра. Буа шәһәренең «Хаҗилар» мәчете имамы Фәһим хәзрәт Сөләйманов ярдәме белән көн саен көндезге сәгать унбердән бергә кадәр 60 тан артык кеше кайнар ризык белән тәэмин ителә. Менюда – ашлар, ит ризыклары, боткалар, пылау. Диния нәзарәте мөхтәсибәтләре тырышлыгы белән шундый ук пунктлар Казан, Яшел Үзән, Чистай һәм Нурлат шәһәрләрендә дә эшли.

## Нәзарәт Татарстан солдатларына гуманитар йөк илтеп тапшырды

Шәгъбан аеның 2 нче көнендә (22 нче февральдә) Татарстан мөфтияте республикабыз мөселманнарыннан җыелган гуманитар йөкне махсус хәрби операция кырларында хезмәт итүче Татарстан солдатларына җибәрде. Нәзарәт вәкилләре 2 тоннага якын авырлыктагы ярдәмне, ике машинага төяп, Луганск өлкәсендә урнашкан частьләрнең берсенә илтеп тапшырды. Солдатлар 1 тонна күләмендә 3 мең данә банка хәләл тушенка, иминлекне саклауның югары классына ия бронежилетлар, 45 пар резин итек, 10 данә маскировка челтәре, медикаментлар, куертылган сөт һәм туристик келәмнәр белән тәэмин ителде. Нәзарәт хәзрәтләре, моннан тыш, сугышчыларга шәригать мәсьәләләре буенча киңәшләрен дә бирде.

2022 елның сентябрь аеннан бирле солдатларга ярдәм йөзеннән Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фондына Татарстан мөхтәсибәтләре ярдәме белән 8,7 млн сум акча җыелды. Җыелган акчага хәрби шартларда кирәк булган әйберләр сатып алынды. Шул исәптә: 14 000 данә хәләл тушенка, 40 комплект хәрби обмундирование (шлемнар, бронежилетлар, бронеплитәләр, кан агуны туктата торган жгут-турникетлар), 14 комплект хәрби кием (кышкы аяк киемнәре, эчке термокием, балаклава, перчатка, оекбашлар, хәрби керләмнәр), медикаментлар һәм шәхси гигиена әйберләреннән торган 14 җыелма. Мөхтәсибәтләр, акчалата өлеш кертүдән тыш, солдатларга җибәрү өчен, «Зәкят» фондына азык-төлек, җылы кием һәм башка файдалы кирәк-яраклар дә китерде. 30 декабрьдә «Зәкят» фонды Татарстан солдатларына генератор җибәрде.

## Яңа Чишмә районында төзекләндерүдән соң борынгы мәчет ачылды

Шәгъбан аеның 4 нче көнендә (24 нче февральдә), изге җомга көнендә, Яңа Чишмә районы Зирекле авылында тантаналы рәвештә борынгы мәчет ачылды. Бу уңайдан оештырылган тантанада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Әлеге гыйбадәт йорты 1903-1905 елларда төзелгән. Аның таш һәм кирпечтән салынган диварларына – 117 ел. Мәчетнең эчке төзекләндерү эшләре узган елда башланды. Төзекләндерү барышында мәчетнең эчке өлеше элекке рәвешенә кайтты, дивар һәм түшәмнәр яңартылды, идән җылытылды. Киләсе елга мәчетнең тышкы ягын да төзекләндерү көтелә. Әлеге эшләр район башлыгы Вячеслав Козлов, иганәчеләр һәм авыл халкы ярдәме белән башкарыла.

Хәзерге вакытта Яңа Чишмә районында 12 мәчет эшли.

## Нәзарәттә «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең 11 нче сезоны ачылды

Шәгъбан аеның 5 нче көнендә (25 нче февральдә) Нәзарәттә «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең 11 нче сезоны ачылды. Халыкны намаз укырга һәм Ислам нигезләренә өйрәтү өчен уздырыла торган әлеге кыска вакытлы курсларга 17 дән алып 80 яшькә кадәр 150 гә якын кеше килде, аларның күпчелеге гадәттәгечә – хатын-кызлар. «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбе якынлашып килә торган Рамазан ае алдыннан махсус оештырылды, ул изге ай тәмамланганчы намаз укырга өйрәнергә мөмкинлек бирә. Курслар 8 апрельдә, Рамазанның 17 нче көнендә, ифтар белән тәмамланачак. Белем алырга теләүче дин кардәшләр белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин аралашып, үзенең нәсыйхәтләрен җиткерде. «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбендәге лекцияләр хатын-кызлар һәм ир-атлар өчен – аерым, татар һәм рус телләрендә уза. Дәресләр Казанның Галиев мәчетендә, һәр шимбәдә иртәнге сәгать сигездән (8:00) алып төшке сәгать уникегә (12:00) кадәр оештырыла. Җиде атна дәвамында берәр тапкыр уза торган дәресләр тәһарәт алу, намаз уку, гакыйдә, ураза тоту һәм башка гыйбадәтләргә багышлана.

«Ислам. Беренче адымнар» мәктәбе 5 ел буе мәчет каршындагы курсларга йөрергә мөмкинлеге һәм вакыты булмаган, шул ук вакытта мөселман кешесенә йөкләнгән гыйбадәтләрне үтәп яшәргә омтылган дин кардәшләр өчен оештырыла. Проект Татарстан мөфтияте тарафыннан 2018 елда тормышка ашырыла башлады. Ун сезон дәвамында әлеге курсларда 940 ка якын кеше белем алды һәм намазга басты.

## Нәзарәт биналарның тышкы бизәлеше буенча «Нурлы Рамазан» республика бәйгесен игълан итте

Татарстан мөфтияте якынлашып килә торган изге Рамазан ае уңаеннан җәмәгать урыннары арасында иң матур бизәлештә ярышу буенча «Нурлы Рамазан» бәйгесен игълан итте. Республикада изге ай мохитен тудыру һәм бәйгедә катнашу өчен иҗтимагый, коммерцияле, шәхси, дәүләт, дини һ.б. оешмалар чакырылды. Моның өчен алар халыкка хезмәт күрсәтү урыннарында – кафе һәм рестораннар, кибетләр һәм сәүдә үзәкләре, салоннар, мәчетләр, уку йортлары кебек теләсә кайсы биналарның керү өлешен бәйрәмчә итеп бизәргә тиеш. Иң матур бизәлешне башкаручыга «ДУМ РТ Хаҗ» рәсми операторыннан хаҗга юллама бүләк ителә. Иң яхшы тышкы бизәлеш Ислам һәм Рамазан ае символикасын куллану; гадәти булмау һәм яңалык өстәү; эстетик күркәмлек; бизәүгә мәгънәви төсмер өстәү; ут-яктырту бизәлешендә хәзерге заман технологияләрен файдалану кебек күрсәткечләр буенча сайлап алына.

## Казанда «Затлы мәҗлес» узды

Шәгъбан аеның 10 нчы көнендә (2 нче март), ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә «Затлы мәҗлес» проектында катнашучыларның – мөслимәләрнең һәм исламны өйрәнүчеләрнең – 2023 елдагы беренче очрашуы узды. Мөслимәләрнең һәр очрашуы үзенең кызыклы булуы белән аерылып тора. Ул мәҗлес тә истә калырлык булды: 70 кызга «Вакыт кадере» дигән фәлсәфи спектакль күрсәтелде. Спектакльдә вакыт кадере һәм аның максатка ирешү өчен мөмкинлекләр бирүенә кагылышлы тема күтәрелде. Мөслимәләр теге яки бу геройның эчке дөньясын аңлый алсын өчен, спектакль интерактив формада куелды: төп геройлар тамашачылар белән «күзгә күз карап» аралашты.

## «Ибн Фадлан» фильмы киң прокатка чыкты

«Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмы киң прокатка чыкты – хәзер аны кинотеатр экраннарыннан тамаша кылырга мөмкин. Кинотасма 2023 елның 2 мартыннан Казан, Түбән Кама, Уфа, Чаллы шәһәрләренең «Синема 5» кинотеатрларында күрсәтелә башлады. Фильм Багдад илчелеге составында Идел буе Болгар дәүләтенә килгән гарәп дипломаты Әхмәд ибн Фадланның юл язмаларына нигезләнгән. Илчелекнең килүе Идел Болгарстанында 922нче елда ислам дине рәсми дин буларак кабул ителү белән бәйле. «Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмы – «Россия – ислам дөньясы» Стратегик караш төркеме заказы буенча Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифе фонды ярдәме белән Татарстан мөфтиятенең «Хозур» нәшрият йорты тарафыннан Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан төшерелде. Кинотасма 2022 елда узган Казан халыкара мөселман киносы фестиваленең ачышы булды һәм тамашачылар арасында зур кызыксыну уятты. Исегезгә төшерәбез, фестиваль вакытында «Ибн Фадлан» фильмы 4 тапкыр күрсәтелде һәм алар барысы да аншлаг белән узды.

## Казанда Рамазан ае алдыннан «Чиста мәчет» акциясе узды

Казанда Рамазан ае алдыннан «Чиста мәчет» акциясе узды. Гадәттәгечә, изге Рамазан ае алдыннан битараф булмаган мөселманнар Казан мәчетләрен җыештырды. Мәчетләрдә өмә вакытында алар тәһарәт алу бүлмәләрен, намаз һәм уку залларын тәртипкә китерде, тузан сөртте, келәмнәрне чистартты, идәннәрне һәм җиһазларны сөртеп чыкты, пәрдәләрне юып элде, ә ир-атлар мәчеткә керү юлларын чистартты, җиһазлар күчерде. Мөфтият волонтерлары, быел акция башланганнан бирле, «Миргазиян», «Тәүфикъ», «Мәдинә» һәм «Апанай», «Рөстәм», «Әниләр» һ.б. мәчетләрне тәртипкә китерде.

## Мөфти Мәскәүдә Катар дәүләтенең Россиядәге Илчесе белән очрашты

Шәгъбан аеның 14 нче көнендә (6 нчы мартта) Татарстан мөфтие Мәскәүдә эш сәфәрендә булды. Илчелек бинасында Камил хәзрәт Сәмигуллин Катар дәүләтенең Россиядәге Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе Шәйх Әхмәд бин Нассер бин Җасим Әл Тани белән очрашты. Хәзрәт Илчелеккә мөфтиятнең мәгариф, белем бирү, социаль проектларын тормышка ашыруда ярдәм иткәне, Катар иленнән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе өчен җибәрелгән бай китапханә өчен рәхмәт әйтте. Илче үз чиратында мөфтигә чын, хакыйкый Ислам кыйммәтләрен таратуда, Хәнәфи мәзһәбен өйрәнүдә зур тырышлык куйган өчен ихтирамын белдерде. Ул Татарстан мөфтиенең зур казанышы – Россиянең дәүләт һәм хөкүмәт структуралары белән уңышлы багланышларны гамәлгә ашыру булуын әйтте.

## «Хозур ТВ» Пенза өлкәсендә күрсәтә башлады

Нәзарәтнең «Хозур ТВ» мөселман телеканалы Пенза шәһәре һәм Пенза өлкәсе авылларында – төбәкнең 12 торак пунктында күрсәтә башлады. Дин кардәшләр аның тапшыруларын март башыннан «Дом.ру» цифрлы телевидениесе аша 32 нче каналда карый ала. «Хозур ТВ» телеканалын Пензада карау мөмкинлегенә «Хозур» Нәшрият йорты һәм «Дом.ру» кабельле оператор белән килешү төзү нәтиҗәсендә ирешелде. Шул рәвешле, канал Россиянең 11 төбәгендә эфирга чыга башлады.

«Хозур ТВ» – Россиядәге беренче мөселман телеканалы. Проект, җәмгыятьтә традицион Ислам кыйммәтләрен тарату максатыннан, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин башлангычы һәм Таттелеком» ААҖ ярдәме белән тормышка ашырыла. Телеканал тапшыруларны кабель аша 11 төбәктә күрсәтә. Кабельле операторлардан тыш, «Хозур ТВ» мөселман каналын App Store, Playmarketтагы мобиль кушым-

талар ярдәмендә һәм www.huzurtv.ru рәсми сайтында карарга мөмкин. Телеканалның YouTube каналына язылучылар саны – 1,2 млн артык кеше. 2022 елда аның контентын караучылар саны 15 000 000 га җитте.

## Егетләр өчен беренче «I’MAN» тренингы узды

Шәгъбан аеның 15 нче көнендә (7 нче мартта), Казанда «I’MAN» ир-атлар проектының 2023 нче елдагы беренче очрашуы узды. Моңа кадәр егетләр вәгазь кичәләрендә яисә дискуссияләрдә катнашкан булса, бу юлы КИУның гарәп теле һәм гуманитар фәннәр кафедрасы җитәкчесе, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының баш фәнни хезмәткәре Габдулла хәзрәт Әдһәмов очрашуны тренинг форматында үткәрде. Башкала мәчетләренә йөрүче яшьләр катнашында узган очрашу бүгенге заманда-гы көнүзәк мәсьәләләрнең берсенә – «Намазны ничек хошугълы рәвештә (ихласлы) укырга?» дигән темага багышланды. Тренингка җыелган 30 дан артык егет шушы мәсьәләне хәл итү буенча куелган сорауларга гамәли яктан чишелеш эзләде. Ике сәгать дәвам иткән очрашуда Габдулла хәзрәт шәгъбан аеның фазыйләтләренә дә тукталды.

Ел дәвамында «I’MAN» проекты кысаларында ир-атлар өчен очрашулар, спорт күнекмәләре һәм лекцияләр уздырылачак. Тулырак мәгълүматлар Телеграмда MUSLIMMOL аккаунтында биреләчәк. Очрашулар барышында күренекле хәзрәтләр проектта катнашучыларга көндәлек тормышны җайга сала торган шәригать нормалары, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте турындагы белемнәрне арттыру, чын мөселманга хас әхлакый сыйфатларны үстерү, шулай ук рухи авырулардан котылу ысуллары турында сөйләячәк.